Академия наук Республики Татарстан
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ҺӘМ XX–XXI ГАСЫРЛАР ТАТАР БЕЛЕМЕ

ХАЛЫКАРА ФӘННИ-ГАМӘЛИ СЕМИНАР МАТЕРИАЛЛАРЫ

2022 елның 25–26 апреле. Казан

# ГАЛИМДЖАН ИБРАГИМОВ И ТАТАРОВЕДЕНИЕ XX–XXI ВЕКОВ

МАТЕРИАЛЫ
МЕЖДУНАРОДНОГО НАУЧНО-ПРАКТИЧЕСКОГО СЕМИНАРА

25–26 апреля 2022 года. Казань

# GALIMJAN IBRAGIMOV AND TATAR STUDIES IN THE XX–XXI CENTURIES

PROCEEDINGS OF THE INTERNATIONAL SEMINAR

April 25–26, 2022. City of Kazan

КАЗАНЬ
2022

УДК 82.09
ББК 83.3
Г 12

*Печатается решением Ученого совета
Института языка, литературы и искусства
им. Г. Ибрагимова АН РТ*

Издается в рамках реализации
государственной программы Республики Татарстан
«Сохранение национальной идентичности татарского народа
(2020–2024 годы)»

**Составители:**
***А.Ф. Ганиева, Л.Ш. Галиева***

**Г 12 Галимджан Ибрагимов и татароведение XX–XXI веков:** материалы международного научно-практического семинара, посвященного 135-летию со дня рождения классика татарской литературы Г. Ибрагимова / сост.: А.Ф. Ганиева, Л.Ш. Галиева. – Казань: ИЯЛИ, 2022. – 300 с.
ISBN 978-5-93091-408-5

В сборнике представлены материалы международного научно-практического семинара «Галимджан Ибрагимов и татароведение XX–XXI веков», приуроченного к 135-летию со дня рождения классика татарской литературы, ученого, политического и общественного деятеля Галимджана Ибрагимова.

Издание адресовано ученым-гуманитариям, занимающимся исследованиями в области татароведения, читателям, интересующимся историей, фольклором, литературой татар в России и за рубежом.

**ISBN 978-5-93091-408-5**

© Оформление. Институт языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2022

# КЕРЕШ СҮЗ

«Парадигмалар алмашыну шартларында татар белеме: теория, методология, практика» дип исемләнгән икенче халыкара семинар татар әдәбияты классигы, галим, сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 135 ел тулуга багышлана. Аның 1938 елның 21 гыйнварында НКВД төрмәсе хастаханәсендә фаҗигалы төстә өзелгән гомере, әйтерсең лә, дәверләр сынаган вакытта үз халкы мәнфәгатен кайгырткан татар зыялыларының язмышын тагын бер кат искә төшерә.

Уфаның атаклы «Галия» мәдрәсәсендә белем туплаган Галимҗан Ибраһимов – революциягә кадәр татарларның әдәби һәм иҗтимагый тормышында кайнаган фикер иясе, татар теле һәм әдәбиятын, мәдәниятен үстерүгә юнәлтелгән җитди хезмәтләр авторы. Революция елларында – эсерлар партиясе лидерларының берсе, ул үзен бу чорда тулысынча сәяси эшчәнлеккә багышлый, Татар-башкорт республикасын төзү уен-планын тормышка ашыру белән шөгыльләнә, Сталин җитәкләгән РСФСРның Милләтләр эшләре буенча халык комиссариатында Мулланур Вахитов белән бергәләп төбәк халкы ихтыяҗларын кайгырта, татар газеталары оештырып, катлаулы вазгыятьне кавемдәшләренә аңлата. 1920 елларда Г. Ибраһимов Татар мәгариф халык комиссариаты каршындагы Гыйльми (Академик) үзәкне җитәкли, үзен талантлы фән оештыручысы итеп таныта. 1927 елны милләтнең киләчәге өчен борчылып, «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак» дигән хезмәт бастыруы язучы тормышында тамырдан борылыш китереп чыгара: ул партия һәм әдәби җитәкчелек тарафыннан читкә кагыла. Туберкулезның авыр формасы белән авырган Г. Ибраһимов аннан соңгы 10 ел гомерен Ялтада уздыра, 1937 ел ахырында кулга алына һәм Казанга озатыла.

1950 еллар уртасыннан (1955 елны, язучының эш-гамәлләрендә җинаять составы булмау сәбәпле, тикшерү эшен туктату турында карар чыгарыла) Г. Ибраһимовның күпкырлы эшчәнлеге белән әдәбиятны өйрәнүчеләр, лингвистлар, тарихчылар, мәдәният-сәнгать белгечләре кызыксына һәм җитди шөгыльләнә башлый. Шушы вакыттан бүгенге көнгә кадәр аның тормышына һәм иҗатына багышланган күп кенә фәнни тикшеренүләр дөнья күрде, язучы әсәрләренең һәм хезмәтләренең күп томлы җыентыклары басылып чыкты. Соңгысы – унбиш томлык – юбилей датасын каршылап, 2021 елны дөнья күрде.

Г. Ибраһимовның иҗатын татар әдәбияты һәм мәдәнияте тарихына кайтаруда күренекле татар язучылары һәм галимнәре Ә. Еники, Г. Халит, М. Хәсәнов, А. Шамов, С. Алишев, Н. Юзиев, Ф. Ибраһимова һ.б.ның өлеше зур.

Хәзерге галимнәр хезмәтләрендә Г. Ибраһимов шәхесе төрле яклап ачыла-ачыклана. Берәүләр өчен ул – XX гасыр башында татарларның милли үзтәңгәллеген яклап, аларның милләт дип аталу хокукын еракларга яңгыраткан татар әйдаманы; кемдер аның эш-

гамәлләрендә 1920 еллар уртасында, Академик үзәк биргән мөмкинлекләрне файдаланып, татар телен институцияләү өчен күп көч куйган фән оештыручысын күрә; аның революциядән соң татарларның милли дәүләтчелеген коруга керткән өлешен югарырак санаучылар да бар. Бәяләр күптөрле булса да, бер нәтиҗә бәхәссез: Г. Ибраһимов эшчәнлегенең барлык чорларында да милли тел, әдәбият, мәдәният, тарих мәсьәләләрен алга, беренче урынга куйган. Үзенең күпчелек хезмәтләрендә, чыгышларында Г. Ибраһимов милли (беренче чиратта, төрки) телләр, әдәбиятлар, мәдәниятләр төрлелеге өчен җан атучы булып күзаллана («Без – татарлар», «Телләре башка булса да, күңелләр бер»). 1926 елны Бакуда узган I Тюркология съездында чыгыш ясап, Татарстан делегациясен җитәкләгән Г. Ибраһимов төрки телле халыкларның үз алфавитлары булырга тиешлекне, аларның үз язуын мөстәкыйль сайлау хокукы барлыкны ассызыклый, ачыктан-ачык яңгырата. Язучы, галимнең иҗатына карата төрки дөнья галимнәренең кызыксынуы сүрелмәү аның әлеге позициясе белән дә бәйле иде.

Г. Ибраһимовның фәнни һәм фәнни-оештыру эшчәнлеге 1920 елларда татар телен дәүләт теле дәрәҗәсендә беркетүдә зур роль уйный: нәкъ менә ул Академик үзәк белән җитәкчелек иткән чорда Татар гыйлеме фәнни җәмгыяте оештырыла, аның «Хәбәрләр» басмасы чыгарыла башлый, татар тарихы, татар теле, әдәбиятыннан күп санлы хезмәтләр дөнья күрә. Татар теленең орфографиясе, морфологиясе, синтаксисы, аны укыту методикасы, әдәбият теориясе һәм тарихы, татар тарихы буенча төрле елларда аның тарафыннан язылган хезмәтләр күп очракта XX гасырның беренче чирегендә фәнни юнәлеш-юлларны билгеләгән.

Татар милләтенең әйдаманнарыннан булган Г. Ибраһимов, хәтта милли телләрне һәм мәдәниятләрне унификацияләү шартларында да, аларның үзтәңгәллеген һәм үз асылын саклау, туган телне укыту өчен шартлар тудыру турындагы мәсьәләләрне күтәрә («Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак», 1927).

Россия (Казан, Уфа, Ижевски, Якутски, Нальчик, Чабаксар, Симферополь, Мәскәү һ.б. шәһәрләр) һәм чит илләрдән (Казакъстан, Кыргызстан, Азәрбайҗан, Төркия) галимнәрне җыйнап, семинар татар гыйлеменең актуаль проблемалары белән бәйле үзара аралашу мәйданчыгы булдырырга омтыла. Семинарга нисбәтле төзелгән җыентыктагы фәнни мәкаләләр, бер яктан, тикшеренүчеләрнең татар теле, әдәбияты, тарих, мәдәният һәм Г. Ибраһимов шәхесе белән кызыксынуларын күрсәтә, икенче яктан – булачак дискуссияләрнең юнәлешләрен билгели. Аерым алганда, түгәрәк өстәл үзәгенә чыга торган, милли мәдәнияттә әйдаман-лидерларның роле турындагы мәсьәлә дә шундыйлардан.

«Парадигмалар алмашыну шартларында татар белеме:<br>теория, методология, практика» проекты җитәкчесе,<br>филология фәннәре кандидаты<br>Марсель Ибраһимов

# ПРЕДИСЛОВИЕ

Второй международный семинар «Татароведение в ситуации смены парадигм: теория, методология, практика» приурочен к 135-летию со дня рождения классика татарской литературы, ученого, политического и общественного деятеля Галимджана Ибрагимова. Его жизнь, трагически оборвавшаяся в тюремной больнице НКВД 21 января 1938 года – пример жизни татарского интеллигента на сломе эпох. Выпускник знаменитого уфимского медресе «Галия», Галимджан Ибрагимов до революции – активный участник литературной и общественной жизни татар, автор трудов по татарскому языку и литературе. В годы революции – один из лидеров партии эсеров, он с головой уходит в политическую деятельность, выступает за создание Татаро-башкирской республики, вместе с Муллануром Вахитовым работает в возглавляемом Сталиным Наркомнаце, создает татарские газеты. В 1920-е гг. Галимджан Ибрагимов руководит Академцентром Татнаркомпроса, проявляет себя как талантливый организатор науки. Поворотным в судьбе писателя стал 1927 год: после публикации брошюры «Каким путем пойдет татарская культура?» он попадает в опалу партийного и литературного руководства. Тяжело больной туберкулезом, последующие 10 лет своей жизни Г. Ибрагимов живет в Ялте, где и подвергается аресту и этапированию в Казань в конце 1937 года.

Многогранная деятельность Г. Ибрагимова начиная с середины 1950-х гг. (в 1955 году было вынесено постановление о прекращении следственного производства по делу писателя за отсутствием в его действиях состава преступления) – предмет широкого научного интереса литературоведов, лингвистов, историков, культурологов. За это время увидело свет множество исследований, посвященных его жизни и творчеству, были опубликованы многотомные собрания сочинений писателя. Последнее – пятнадцатитомное – увидело свет в 2021 году, в канун юбилейной даты.

В возвращении в историю татарской литературы и культуры творчества Г. Ибрагимова велика заслуга известных татарских писателей и ученых: А. Еники, А. Шамова, М. Хасанова, Н. Юзиева, Ф. Ибрагимовой, Р. Мухаметшина и др.

В трудах современных ученых личность Г. Ибрагимова воспринимается по-разному. Для одних он – лидер татаризма, отстаивавший в начале XX века национальную идентичность татар, их право называться самостоятельной нацией; кто-то видит в нем организатора науки, приложившего немало усилий для институционализации академического татароведения в середине 1920-х гг. в рамках руководимого им Академического центра Татнаркопроса; кто-то ценит его вклад в процесс нациестроительства татар в послереволюционный период. Множественность оценок Г. Ибрагимова не исключает одного:

в разные периоды деятельности в числе приоритетных для него были вопросы национального языка, литературы, культуры, истории. Важно и другое: прилагавший большие усилия по развитию татароведения, в большинстве своих трудов и выступлений Г. Ибрагимов предстает как поборник идеи множественности национальных (прежде всего, тюркских) языков, литератур, культур («Мы – татары», «Разные языки, но родственные души»).На состоявшемся в 1926 году в Баку I Тюркологическом съезде, где возглавлявший татарскую делегацию Г. Ибрагимов открыто высказывался за множественность алфавитов у тюркоязычных народов, их право самостоятельно выбирать свой алфавит. Эта позиция писателя и ученого во многом определяет неизменный интерес к его творчеству ученых-тюркологов.

Научная и научно-организаторская деятельность Г. Ибрагимова играла большую роль в институционализации татароведения в 1920-е гг.: именно в период его руководства Академцентром организуется Научное общество татароведения, начинает издаваться его «Вестник», издаются многочисленные труды по истории татар, татарскому языку, литературе. Написанные им в разные годы труды по орфографии, морфологии, синтаксису татарского языка, методике его преподавания, теории и истории литературы, истории татар во многом определяли научные векторы в первой четверти XX века.

Один из лидеров татарской нации, Г. Ибрагимов даже в условиях унификации национальных языков и культур ставил вопрос о необходимости сохранения их идентичности, создании условий для преподавания родного языка («Каким путем пойдет татарская культура», 1927).

Собравший ученых из городов России (Казани, Уфы, Ижевска, Якутска, Москвы, Нальчика, Горно-Алтайска, Симферополя, Чебоксар), из-за рубежа (Казахстана, Кыргызстана, Азербайджана, Турции) семинар ориентирован на создание коммуникативного пространства, связанного с актуальными проблемами татароведения. Научные статьи, включенные в составленный по итогам семинара сборник, с одной стороны, свидетельствуют об интересе исследователей к татарскому языку, литературе, истории, культуре, личности Г. Ибрагимова, с другой – определяют направление будущих дискуссий. К таковым, в частности, относится вопрос о роли лидеров в национальной культуре, ставший предметом дискуссии на круглом столе в рамках семинара.

*Руководитель проекта «Татароведение в ситуации смены парадигм: теория, методология, практика», кандидат филологических наук*
***Марсель Ибрагимов***

# ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ, КУЛЬТУРНО-ПРОСВЕТИТЕЛЬСКАЯ И НАУЧНО-ОРГАНИЗАТОРСКАЯ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ Г. ИБРАГИМОВА в 1900–1920-е гг.

УДК 811.512.145

## ГАЛИМДЖАН ИБРАГИМОВ И ГАЯС МАКСУДОВ: ПЕРЕПЛЕТЕНИЕ СУДЕБ

***В.З. Гарифуллин***
*Казанский (Приволжский) федеральный университет (Казань)*

Статья посвящена изучению взаимоотношений и научно-творческого содружества Галимджана Ибрагимова и Гаяса Максудова. Они стояли у истоков академической науки Татарстана, поочередно возглавляя Академический центр республики, сыграли большую роль в становлении и развитии педагогической журналистики на татарском языке, будучи редакторами журнала «Магариф» в годы его становления. Они также совместно работали над реформированием татарской графики и современного терминообразования на татарском языке. Научное и творческое наследие Гаяса Максудова имеет право на дальнейшее изучение и получение должной оценки. Как верный соратник Г. Ибрагимова, настоящий ученый и талантливый журналист, он является примером подражания для будущих поколений.
**Ключевые слова:** Гаяс Максудов, образование, педагогическая журналистика, язык, реформа.

The article is devoted to the study of the relationship and scientific and creative community of Galimjan Ibragimov and Gayaz Maksudov. They stood at the origins of the academic science of Tatarstan, alternately heading the Academic Center of the republic, played a major role in the formation and development of pedagogical journalism in the Tatar language, being editors of the Magarif magazine during its formation, They also worked together to reform Tatar graphics and modern terminology in the Tatar language. The scientific and creative heritage of Gayaz Maksudov has the right to further study and receive proper evaluation. As a loyal associate of Galimjan Ibragimov, a true scientist and a talented journalist, he is a role model for future generations
**Key words:** Gayas Maksudov, education, pedagogical journalism, language, reform.

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ҺӘМ ГАЯС МАКСУДОВ: ЯЗМЫШЛАР УРТАКЛЫГЫ

***В.З. Гарифуллин***
*Казан (Идел буе) федераль университеты (Казан)*

Галимҗан Ибраһимовның 20–30 еллардагы киңкырлы фәнни-иҗтимагый мирасын шул чор галимнәренең эшчәнлегеннән аерып карау мөмкин түгел. Шундый шәхесләрнең берсе – күренекле галим, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяс Максудов шәхесе аерым игътибарга лаек.

Гаяс Максудов 1891 елда Теләче районының Югары Кибәхуҗа авылында Гыйсаметдин мулла гаиләсендә туа. Ишле гаиләдә унике баланың берсе була ул [7]. Биш-алты яшендә үк әти-әнисеннән хәреф танырга өйрәнә һәм кечкенәдән китап укырга һәвәс булып үсә. 1904 елда аны укуын дәвам итү өчен Югары Кибәхуҗадан кырык чакрымдагы Кышкар мәдрәсәсенә урнаштыралар. Сүз уңаеннан, Кышкар мәдрәсәсе – татар милләте өчен язучы һәм журналистларны күпләп тәрбияләп биргән уку йорты. Биредә Гаясның бертуган энесе, танылган татар язучысы һәм журналисты Мәхмүд Максуд та, тагын бер энесе, авыл хуҗалыгын механикалаштыру өлкәсендә эшләгән беренче татар галиме, техник фәннәр кандидаты, ТАССРның атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы, Казан авыл хуҗалыгы институтында тракторлар һәм автомобильләр кафедрасына нигез салучы, дистәдән артык татарча дәреслек һәм уку кулланмасы авторы Нәҗип Максудов та белем алган.

Белемгә сусаган, дөньяны күбрәк күрергә омтылган Гаяс Кышкарда озак тоткарланмый, Оренбургка юл тота. 1905 елның көзеннән ул биредәге «Хөсәения» мәдрәсәсендә белем ала башлый, тырышлыгы белән таныла, бигрәк тә математика фәнен яхшы үзләштерә. Шуны истә тотып, уку елының икенче яртысында аны интернатта бушлай торучылар исемлегенә кертәләр. 1905 елгы революция тәэсирендә «Хөсәения»дә шәкертләр хәрәкәте шактый көчәеп китә. Шәкертләр мәдрәсә администрациясе алдына байтак таләпләр куялар. Идарә ул таләпләрне тулысынча канәгатьләндермәгәч, шуңа протест йөзеннән, 1907 елда 40 лап шәкерт мәдрәсәне ташлап чыга. Гаяс бу хәрәкәтне башлап йөрүчеләрнең берсе була. Мәдрәсәне ташлап чыккан шәкертләр, оешкан рәвештә, хәзерге Әгерҗе районы Иж-Буби авылындагы мәдрәсәгә барып керәләр. Мәдрәсә, авыл җирендә булуга карамастан, төрле фәннәр, рус теле һәм башка телләр укытылу ягыннан заманына күрә бик алдынгы санала. Нәкъ менә шушында Гаяс шәхес буларак формалаша. Ул инде милләткә хезмәт итеп, зур эшләр башкарырга, моның өчен математика мөгаллиме булырга карар кыла. Моның өчен, әлбәттә, мәдрәсә белеме генә җитми. 1909 елда 18 яшьлек татар егете, Кара

диңгезне кичеп, Төркиягә барып җитә, Истанбул шәһәрендәге лицейларның берсенә укырга керә. Лицейны тәмамлау белән, ул Бельгиянең Льеж университетына барып керә. Ләкин бу уку йортын тәмамлый алмый: Беренче Бөтендөнья сугышы башлана, шәһәрне немецлар оккупацияли. Гаяс Бельгиядән китәргә мәҗбүр була. Ләкин сугыш һәм революция аркасында туган илгә кайта алмый, кире Истанбулга китә һәм анда университет тәмамлап, лицейда һәм укытучылар семинариясендә математика укыта башлый.

Чит илдә зур белемнәр туплаган егет Россиягә 1919 елда гына әйләнеп кайта ала. Әле анда да Одессага кадәр генә. Ул биредәге татар мәктәпләренең берсенә мөдир булып урнаша. 1920 елның июнь аенда Мәскәүгә кайта. Аннан Гаясны Казанга җибәрәләр. Гаяс Максудов, югары белемле математик булу өстенә, күп кенә чит телләр дә белә, киң колачлы, күпкырлы белгеч буларак, үзенә тапшырылган эшләрнең барысына да зур теләк һәм инициатива белән алына. Бу Татарстан Республикасы төзелгән чор була. Нәкъ шушы чорда аның Галимҗан Ибраһимов белән аралаша башлавы мәгълүм. Профессор Хәмит Мөштәри бөек әдип турында язган истәлегендә Г. Ибраһимовның Европа белеме алган галимнәргә игътибарлы мөнәсәбәтен болай дәлилли: «Гыйльми үзәкнең терминология комиссиясе эшләрендә катнаша торган идем. Ул вакытта Гыйльми үзәк башында Г. Ибраһимов иде. Мин физика-математика комиссиясендә эшләдем. Бу комиссиянең җитәкчесе Гаяс Максудов иде. Ул да университет бетергән кеше. Ул вакытта без татарлар арасында физика-математика фәне буенча югары белемле кешеләр аның белән икәү генә идек. Галимҗан ага: Европа белеменен алган һәм татар телендә хезмәт итә торган кешеләр безгә бик кирәк, – диде һәм кабатлап әйтте: – Бик кирәк!» [2: 255–256].

Менә шушы ихтыяҗны тоеп, Г. Ибраһимов яшь галимнәрне фән һәм мәгариф өлкәсендә олы вазифаларга тартып китерә. «1920 елның маенда Татар Республикасы төзелү уңаеннан тикшеренү өлкәләре күпкә киңәя, махсус фәнни-тикшеренү җәмгыятьләре һәм үзәкләре барлыкка килә. Алар арасында 1921 елда Мәгариф халык комиссариаты каршында оештырылган Академик үзәк аерым урын алып тора. Үзәкнең беренче рәисе итеп Г. Максудов (1922–1924) билгеләнә. Аннан соң бу вазифаны Г. Ибраһимов (1927 елга кадәр), Р. Таһиров (1927–1929 еллар), С. Атнаголов (1929–1930 еллар) башкара. Аның хезмәткәрләре арасында Е. Чернышев, Н. Фирсов, М. Худяков, Г. Гобәйдуллин, М. Корбангалиев, Х. Бәдигый, Г. Рәхим, Җ. Вәлиди, Г. Алпаров, М. Фазлуллин кебек атаклы галимнәр булган» [3: 11]. Шулай итеп, бүгенге ТР Фәннәр Академиясенең чишмә башы саналучы Гыйльми үзәк җитәкчесе итеп Гаяс Максудов тәгаенләнә һәм ул фикердәше Галимҗан Ибраһимов белән бергә Казанның төп фәнни һәм мәдәни

көчләрен шушы Үзәк тирәсенә туплауга керешә. Биредә Татарстан халыклары мәдәниятен үстерү белән бәйле теоретик проблемалар һәм практик чаралар әзерләнә, мәктәпләр өчен яңа дәреслекләр һәм методик кулланмалар төзелә [5: 6]. Бер үк вакытта Гаяс Максудов Үзәк мөселман хәрби коллегиясендә матбугат бюросы начальнигы, «Кызыл Армия» газетасының вакытлы редакторы, Шәрык академиясе каршындагы эшчеләр факультетын оештыручы һәм аның мөдире, Татарстан Мәгариф комиссариатында тәрҗемәчеләр секторы начальнигы булып эшли.

Галимҗан Ибраһимов белән бергә ул «Мәгариф» журналын совет чорында яңадан оештырып җибәрүче буларак та күп хезмәт башкара. Журналның башлангыч чорында берничә ел буена аның җаваплы мөхәррире була. Бу вазифаны 1921 елдан 1925 елга кадәр башкара. Бер үк вакытта Г. Максудов мәгариф темасына язылган күп санлы мәкаләләр авторы да. Аның педагогика-методика, мәгариф системасы, әдәби тел, орфография һәм башка темаларга караган күп мәкаләләре популярлык казана.

Журнал, Гыйльми үзәк белән берлектә, татар һәм рус галимнәрен җыеп, мәгариф өлкәсендә ашыгыч хәл ителергә тиешле күп төрле проблемалар өстендә ныклап эшкә керешә. Ә андый проблемалар җитәрлек: революциядән соң киңәеп киткән мәктәпләр челтәрен укытучылар белән тәэмин итү, алар өчен программа һәм дәреслекләр төзү, фәнни терминологияне рәткә салу, күптән үк башланган хәреф, имля мәсьәләләрен хәл итү һ. б. Журнал җитәкчесе булу математика белгече Гаяс Максудовны мәгариф өлкәсенә кагылышлы барлык проблемалар белән дә актив шөгыльләнергә мәҗбүр итә. Мәсәлән, ул Гыйльми үзәктә терминология комиссиясе рәисе вазифасын үз өстенә ала. Әлеге комиссия җитәкчесе буларак, аның иң беренче эше элек бездә кулланып килгән гарәп имлясы цифрларын хәзерге һәм барлык халыклар өчен уртак цифрлар белән, ә математика, физика, химия һәм башка фәннәрдә кулланыла торган тамгаларны латин хәрефләре белән алмаштыру була.

Озакламый терминология комиссиясенең икенче зур хезмәте – математика терминнары эшләнә. Бу уңайдан фикер алышу тамгалар, терминнар мәсьәләсе белән генә чикләнеп калмый, гомумән татар әдәби теле һәм аның компонентлары турында сөйләшү төсен ала. Гаяс Максудов үз чыгышларында иң җитди мәсьәләләрне алга сөрә. Телдә «саф татарчалык» ягында торучылар, мәсәлән, татар әдәби теленә башка телләрдән сүзләр алуга каршы булалар. Алар карашынча, халык телендә йөреп тә моңарчы әдәби телгә кермәгән сүзләр, шулай ук борынгы татар телендә булып та хәзер онытылган сүзләр, (мәсәлән, мөдир урынына – узаман, секретарь урынына – язгын, документ урынына – бөти) гражданлык алырга тиеш. «Мәгариф»нең 1921 елгы 3–4 нче санында Гаяс Максудов, боларга җавап рәвешен-

дә, «Караш аермалары» дигән мәкаләсен урнаштыра. Татар әдәби теле ничек булырга тиешлек мәсьәләсенә тукталып, Гаяс Максудов бер генә культуралы телнең да үз сүзләре белән генә чикләнеп кала алмавын әйтә. Галим киң массага аңлаешлы татар әдәби теле булдыру юлындагы практик чараларга аеруча зур игътибар бирә. Ул әдәби телнең башка телләр йогынтысыннан изоляцияләнгән булуын мөмкин санамый. Телебезгә халыкара сүзләрнең һаман күбрәк керә барачагын ассызыклый. Әмма башка телләрдән сүзләр алуда билгеле принциплардан чыгып эш ителергә, башбаштаклыкка юл куелмаска тиеш, ди [8]. Мәкаләдә фәнни тамгалар мәсьәләсенең гомумән язу, бигрәк тә тел мәсьәләсенә катнашы юклыгы әйтелә, «катгый ихтыяҗ аңлашылып җитсә, язу өчен дә латинча алырбыз, бу киләчәк өчен бер хәзерлек булыр», диелә [Шунда ук].

Күренә ки, әлеге мәкаләдә автор гарәп графикасын латинныкы белән алыштыру идеясен калку итеп куя. Бу юкка гына түгел. Билгеле булганча, яшь Совет дәүләтендә кирилл графикасындагы берничә хәрефне үзгәртү белән бәйле реформадан соң, 1919 елда Мәгариф наркомы А.В. Луначарский патша чорыннан калган архаик графика булып саналучы кириллицаны латин язуына алыштыру идеясе белән чыга. Әлеге идеяне В.И. Ленин да хуплый. Моңа ияреп, гарәп имлясын да латинныкына алыштыру буенча фикер алышулар башлана. Казанда бу мәсьәлә беренче тапкыр 1920 елда мәгариф хезмәткәрләре катнашындагы утырышка куела. Анда төп докладны Гаяс Максудов ясый. Әлеге чыгыш 1921 елда «Мәгариф»нең 1–2 нче санында басылып та чыга [1]. Шулай итеп, Гаяс Максудов тарихка татар графикасын «Яңалиф»кә алыштыруның инициаторы буларак кереп кала. Ул җитәкләгән «Мәгариф» журналы исә шушы зур эшне тормышка ашыруда төп лаборатория ролен үти. Галим бу проблема белән бәйле рәвештә берничә саллы мәкаләсен дә чыгара [9; 10; 11; 12].

1923 ел ахырында Мәскәүдә татар-башкорт мәгариф хезмәткәрләренең Бөтенроссия съезды уза. Анда да фәнни формулалар язу өчен латин алфавитын кабул итү кирәклеге турында карар чыгарыла. Резолюциянең бу өлешен Гаяс Максудов һәм Мөхетдин Корбангалиев яза [16: 284].

Ни өчен Гаяс Максудов латин графикасына күчүнең кискен тарафдары буларак таныла соң? Моңа аның Европада белем алуы да, математик буларак әлеге өлкә терминнарын һәм формулаларны гарәп имлясында язу белән бәйле кыенлыкларга юлыгуы да йогынты ясаган, күрәсең. Ни генә әйтсәң дә, татар мәктәпләре өчен туган телебездә математика дәреслекләре төзүне ул үзенең төп вазифаларыннан берсе итеп санаган. Аның «Кыскача алгебра дәресләре» (1923), «Алгебра дәресләре» (1929), «Туры сызыклы тригонометрия» (1929) дәреслекләре, оригиналь хезмәтләр

буларак, үз вакытында зур популярлык казана һәм Татарстан математика тарихында билгеле урынны алып тора.

Максудовтан аермалы буларак, Галимҗан Ибраһимов латинга күчү мәсьәләсендә ашыкмауны кулайрак күрә. Моның ачык мисалы буларак, аның 1926 елда язылган «Әлифба мәсьәләсенең киләчәге» мәкаләсен китерергә мөмкин. «Латинчыларның интернациональ әлифба турындагы сүзләре тере ялган, әкият икәнен күреп үттек» [4: 75], – дип яза әдип бу мәкаләдә һәм «гарәп хәрефләре безнең мәдәни хаҗәтләрне хәзерге дәвердә үти алачаклар, аларны тик бераз төзәтәсе бар», – дигән нәтиҗәгә килә [Шунда ук: 78]. 1926 елның февраль-март айларында Бакуда узган Беренче тюркология съездында Галимҗан Ибраһимов докладыннан соң башланып киткән зур дискуссия барышында әдип латин графикасына тиз арада күчү идеясен якламаганы өчен ямьсез гаепләүләргә дә дучар ителә [13: 152].

Шулай да Г. Ибраһимов тюркология съездының карарларын, һичшиксез, таный. Съезд нәтиҗәләренә багышлап «Кызыл Татарстан» газетасында бастырган мәкаләсендә ул әлеге чараның Россиядәге тюрколог-галимнәрне берләштерүдәге зур ролен ассызыклый, съездда катнашкан Татарстан галимнәренә югары бәя бирә: «Татарстанның Г. Сәгъди, Н. Хәким, Г. Максуд, Г. Алпаров, Г. Шәрәф кебек гыйльми куәтләре үзләренең гыйльми хәзерлекләре буенча теләсә аерым комиссияләрдә, теләсә пленумда, теләсә доклад яки аңлашларда булсын, рус-Европа дөньясында эшләнеп килгән тюркологияне тәкрар кылучы гына түгел, бәлки ул мәсьәләләрдә яңа материал, үзенә башка метод белән, аерым гыйльми оригиналь тикшерүләр белән байтак нәтиҗәләргә ирешкәнлекләрен күрсәттеләр» [4: 53].

Шулай итеп, яңалифкә күчү сроклары белән бәйле үзара каршылык булса да, телгә кагылышлы башка барлык мәсьәләләрдә Галимҗан Ибраһимов белән Гаяс Максудовның фикер уртаклыгы бәхәссез, әдип үзе дә һәрдаим Максудовның тирән белемнәренә һәм актив эшчәнлегенә югары бәя биреп килә. Чынлап та, Гаяс Максудовның ул чордагы актив эшчәнлеге таң калырлык. Ул төп эшләреннән аерылмыйча, Казан дәүләт университетының математика факультеты профессоры И. Гагаев җитәкчелегендә аспирантура үтә, «Дифференциаль тигезләмәләрне академик Чаплыгин ысулы белән якынча интеграллаштыру» дигән темага кандидатлык диссертациясен яклый. Бу хезмәт чит ил журналларында да басылып чыга. Фән кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәле Гаяс Шәрык педагогия институтында, Казан төзүче инженерлар институтында, Казан дәүләт университетында математикадан дәресләр бирә. Казан университеты архивында Гаяс Максудовка доцент дәрәҗәсе бирелү турында боерык саклана. Ул 1934 елның 10 июне белән

расланган. Әлеге боерыктагы исемлектә аның исеме Г.Х. Камай, М.Х. Корбангалиев, Н.Г. Четаев кебек олы галимнәр янәшәсендә [6: 388]. Шул ук елның 1 сентябреннән Г. Максудов университетта танылган галим Н.Г. Чеботарев җитәкчелегендә яңа гына оештырылган математика һәм механика фәнни-тикшеренү институтында да эшли башлый [Шунда ук: 390].

Бер үк вакытта Гаяс җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша: ул Казан дәүләт университетында һәм аның физика-математика факультетында Совет әгъзасы, Мәгариф эшчеләре союзының президиум әгъзасы, фән эшчеләре секциясенең рәисе, «Татарстан» газетасында редколлегия әгъзасы, Татарстанны өйрәнү һәм Татар педагогия җәмгыятьләрендә рәис урынбасары, Казан шәһәр Советы әгъзасы... 1926 елның 25 гыйнварында партия өлкә комитетының матбугат бүлеге коллегиясендә «Безнең юл» (хәзерге «Казан утлары») журналының эчтәлеген яхшырту, матди хәлен ныгыту, аны халык арасында күбрәк тарату мәсьәләсе күтәрелә. Карарның беренче пункты болай формалаштырыла: «Журнал әдәби-нәфис журнал булырга һәм анда гыйльми мәсьәләләр бүлеге дә сакланырга тиеш». Моны истә тотып, Г. Ибраһимов тәкъдиме белән журналның редколлегиясе составына язучылар Галимҗан Ибраһимов һәм Гомәр Галиевтан тыш галим Гаяс Максудов та кертелә [2: 236].

Бер үк вакытта Г. Максудов тел белеме өлкәсендәге эшчәнлеген дә дәвам итә. Мәсәлән, орфография мәсьәләләре буенча 1929 елның 19–22 маенда үткәрелгән конференциядә чыгыш ясап, ул Г. Ибраһимов идеяләрен куәтләп, орфографиянең тар лингвистлар өчен генә булмавын, халык куллануы өчен уңайлы орфография эшләнергә тиешлеген ассызыклый, фонетик принцип белән кирәгеннән артык мавыгуны тәнкыйть итеп, күп кенә практик тәкъдимнәр кертә [15].

Шул ук 1929 елда Гаясны педагогия институтында солтангалиевчеләр төркеме оештыруда, контрреволюцион эшчәнлектә гаепләп, партиядән чыгаралар, ул эшсез кала, чөнки 1923 елда күренекле 15 шәхес белән берлектә Мирсәет Солтангалиевне яклап Мәскәүгә хат язган, соңрак язылган хатларга да кул куйган була [14: 18]. Эзәрлекләүләрдән качып, Гаяс Максудов 1936 елда Үзбәкстанга китә, Сәмарканд университетында укыта башлый. Ләкин тиз арада кулга алына һәм 1937 елның 13 ноябрендә 10 елга хөкем ителә. 1942 елда төрмәдә вафат була. Шулай итеп, Галимҗан Ибраһимовның фаҗигале язмышы аның шәкерте, фикердәше һәм көрәштәше Гаяс Максудов биографиясендә дә кабатлана...

«Яңалиф» графикасын гамәлгә куюда башлап йөргән танылган җәмәгать эшлеклесе, «Мәгариф» журналының совет чорындагы күренекле баш мөхәррире, математика өлкәсендә милләттәшләребез арасыннан беренчеләрдән булып гыйльми дәрәҗә алган зур

галим һәм педагог Гаяс Максудовның фәнни һәм иҗади мирасы алга таба да киң өйрәнелергә, тиешле бәясен алырга лаек.

ӘДӘБИЯТ

1. Әдәби тел төзү турында // Мәгариф. – 1921. – № 1–2. – Б. 7–10.
2. Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / Төз. Р. Акъегет. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 544 б.
3. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты. – Казан, 2010. – 232 б.
4. Ибраһимов Г.Г. Милләт. Тел. Әдәбият: Сайланма хезмәтләр. – Казан: Мәгариф, 2007. – 239 б.
5. Латыйпова Г. Егерменче еллар: Гыйльми үзәк тарихы // Түгәрәк уен. – 1920. – № 2. – Б. 6–9.
6. Летопись Казанского государственного университета. В двух томах. – Т. I. – 1804–1945 гг. – Казань, 2004. – 488 с.
7. Лотфи Г. Уникенең берсе // Казан утлары. – 1971. – № 4. – Б. 124–127.
8. Максуди Г. Караш аермалары // Мәгариф. – 1921. – № 3–4.
9. Максуди Г. Латин хәрефләре мәсьәләсе // Мәгариф. – 1923. – № 2. – Б. 8–9.
10. Максуди Г. Латинчамы, гарәпчәме? // Кызыл Татарстан. – 1926. – 24 март.
11. Максуди Г. Тагын бер зур мәдәни агым // Мәгариф. – 1927. – № 6/7. – Б. 61–67.
12. Максуди Г. Тел турында // Мәгариф. – 1924. – № 5. – Б. 330–339.
13. Мөхәммәдева Ө.Д. Олы юл. Документаль повесть. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. – 272 б.
14. Сулима Л. Унбиш татар диссиденты: ялгышмы, язмышмы? // Татарстан. – 1994. – № 1/2. – Б. 13–19.
15. Татар әдәби теленең орфография конференциясе // Кызыл Татарстан. – 1929. – 25 май.
16. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Мәгърифәт йолдызлыгы. – Казан: Мәгариф, 2002. – 287 б.

УДК 821.512.145

## ДВАДЦАТИЛЕТНИЙ ТВОРЧЕСКИЙ ЮБИЛЕЙ Г. ИБРАГИМОВА

***Г.Н. Зайнеева***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье речь идет о праздновании 20-ти летнего творческого юбилея Галимджана Ибрагимова. В архивах сохранены протокол и стенограмма с торжественных мероприятий, посвященных данному юбилею. По причине болезни в это время писатель проживал в городе Ялте и лично присутствовать не мог. Несмотря на это юбилей был проведен торжественно и масштабно в городах Казани и Москве. Этому свидетельствуют документы, которые представлены в статье. Данные материалы позволяют расширить источниковедческую базу о Галимджане Ибрагимове.
**Ключевые слова:** Галимджан Ибрагимов, юбилей, архивные источники, история татарской литературы.

The article deals with the celebration of the 20th anniversary of Galimdzhan Ibragimov. The archives contain a protocol and a transcript from the celebra-

tions dedicated to this anniversary. Due to illness at that time, the writer lived in the city of Yalta and could not personally attend. Despite this, the anniversary was held solemnly and on a large scale in the cities of Kazan and Moscow. This is evidenced by the documents presented in the article. These materials make it possible to expand the source base about Galimdzhan Ibragimov.
**Key words:** Galimjan Ibragimov, anniversary, archival sources, history of Tatar literature.

## Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ЕГЕРМЕ ЕЛЛЫК ИҖАТ ЮБИЛЕЕ

***Г.Н. Зәйниева***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (Казан)*

XX йөз татар әдәбияты тарихында эз калдырган әдипләр исемнәре шактый күп. Аларның тормыш һәм иҗат юллары тарихчылар, әдәбият белгечләре тарафыннан һаман да кызыксыну объекты булып саналалар. Аларның күбесе узган гасырның утызынчы еллар шаукымы корбаны булып, аннары совет заманында күп нәрсәләрне бастырырга ярамаган вакытка туры килүен истә тотсак, архивлардан документлар алдыру кыенлашкан чорларга эләгүе дә моңа киртә булгандыр. Хәзерге вакытта исемнәре дә телгә алынырга ярамаган әдипләрнең исемнәрен әдәбият мәйданына кайтару өстендә эш алып барыла, аларның әдәбият классигы, гыйльми, җәмәгать эшлеклесе буларак башкарган хезмәтләрен күрсәтү, дәрәҗәләрен күтәрү, күбрәк мәгълүмат булдыру өстендә эш дәвам итә. Шулардан берсе булган татар әдәбияты классигы, язучы, публицист, дәүләт эшлеклесе Г. Ибраһимовның (1887–1938) да әдәби, фәнни, иҗтимагый эшчәнлеген өйрәнү өлкәсендә җитди эшләр алып барыла.

Г. Ибраһимовның барлык әдәби әсәрләрен, хезмәтләрен, мәкаләләрен, хатларын, документларын барлау – галимнәр тарафыннан башкарылып 2018–2021 еллар аралыгында әдипнең 15 томлы академик басмасы Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты. Әлеге басмага кадәр язучының төрле елларда күптомлыклары басылган булсалар да, 15 томлык иң тулы санала. Г. Ибраһимовның тормышы һәм эшчәнлеге Татарстан, Башкортстан, Кырым, Петербург, Мәскәү, Украина территорияләре белән бәйле, шул чор газета-журналларында куйган эшчәнлеге дә иңләп бетерә алмаслык. Г. Ибраһимов тормышы һәм иҗатын җентекләп өйрәнүче галимнәр арасында филология фәннәре докторы М. Хәсәнов зур өлеш керткән. Шулай ук Р. Гайнанов, А. Шамов, Х. Гобәйдуллин, Р. Мостафин, Ф. Ибраһимова, З. Рәмиев, Д. Заһидуллина, А. Литвин хезмәтләрендә язучының эшчәнлеге төрле яклап яктыртыла.

Беренче тапкыр 2000 елда Г. Ибраһимов хатларын һәм документларын бергә җыйнап әдәбиятчы, текстолог Фатыйма

Ибраһимова 1974–1987 елларда нәшер ителгән «Әсәрләр» сигезтомлыгына өстәмә 9 нчы том итеп чыгара [1]. Аннан соң 2012 елда Марат Ибраһимовның «Галимджан Ибрагимов. Документы и факты глазами молодых» исемле хезмәтендә репрессия чоры, исемен аклау документларын туплап бастыруы мәгълүм. Шулай ук әдәбиятчы Рәмил Исламовның 2021 елда ике томга туплап «Галимҗан Ибраһимов – документларда» хезмәте басылып чыга. Академик басманың «Документлар һәм хатлар» исемле 15 нче томында язучының үзе тарафыннан язылган хатлар, автобиографияләр, документлар нәшер ителде. Һәрбер хезмәт үзенчә структура, эчтәлек, яңалыгы ягыннан үзенчәлекле, бер-берсен кабатламый.

Г. Ибраһимовның Татар мөселман комиссариатындагы эшчәнлеге, төрле газета-журналларда эшчәнлеге, Татар коммунистик университетында укытуы, Академүзәкнең җитәкчесе булу, гомумән дәрәҗәле урыннарда хезмәт куюы аның язмышында зур роль уйнаган. 1927 елның апрелендә авыруы көчәеп китү сәбәпле, хөкүмәт тарафыннан дәвалану өчен Ялта шәһәренә җибәрелгән булса да, 1928 елда Г. Ибраһимовның егерме еллык иҗат юбилее зурлап үткәрелә. Шул уңай белән «Вестник научного Общества татароведения» журналының 8 нче саны тулысы белән Г. Ибраһимовка багышлап чыгарылган була, журналда рус һәм татар галимнәренең язучы турындагы мәкаләләре басылган була. Анда «Г. Ибрагимов – почетный член Научного общества Татароведения» диелә. Бу вакытта башка газета-журналларда да язучыга багышланган мәкаләләр басыла, 1929 елда «Галимҗан Ибраһимов әсәрләре»нең җиде томын чыгару планлаштырыла: 2, 5, 6 нчы томнары (Казан, «Яңалиф») басылып кала, 1, 3, 4, 7 нче томнары чыкмый кала. Аның юбилее белән бәйле Казанда һәм Ташкентта җыентыклар басылып чыгуы мәгълүм [2].

Әлеге юбилейга бәйле Татарстан Республикасы дәүләт архивында «Галимҗан иптәш Ибраһимовның 20 еллык юбилее уңае белән үткәрелгән тантаналы утырышның беркетмәсе» саклана [5]. Беркетмә 1928 елның 10 март көне белән билгеләнгән, машинкада басылган, татар телендә, гарәп графикасында. Шәхсән үзе чарада катнаша алмаса да, 1928 елның 10 март көнендә тантаналы кичә уңышлы уздырыла.

Тантаналы утырыш Опера театрында уза, зал партия, совет, профсоюз, җәмәгать оешмалары вәкилләре, укымышлылар, укучылар белән тулган була. Утырышны кереш сүзе белән Татарстан мәгариф халык комиссары Исхак Рәхмәтуллин ача: «Иптәшләр, без бу көн Галимҗан аганы, әдәби-иҗади, гыйльми һәм иҗтимагый хезмәтләренең 20 еллыгын бәйрәм итәргә җыендык. Татар әдәбияты, мәдәнияте үсеше юлында Галимҗан ага шул

кадәр зур һәм җимешле хезмәтләр күрсәтте ки, ул хезмәтләр чынлап та бәйрәм итələргə тиеш. Моннан 20 ел элек татарның мәдәни ярлы заманы иде, 20 ел эчендә мәдәни үсеше юлында зур уңышлар казанылган икән, бу эштә Галимҗан ага зур хезмәт каһарманы булып тора». Аннан соң әдипнең 20 еллык әдәби-гыйльми, иҗтимагый хезмәтләре турында чыгышлар һәм төрле адресатлардан котлаулар тыңлана. Әдәбият галиме, тәнкыйтьче һәм педагог Галимҗан Нигъмәти татар телендә ясалган докладында Г. Ибраһимовның нинди мохиттә һәм нинди шартларда иҗат итүенә тукталa: «Ибраһимов иптәшнең әдәби хезмәте икегә: революциягә кадәр һәм революциядән соңгы чорларга бүленә», ди һәм боларга тәфсилле анализ ясый. Әдәби әсәрләренең идеология, мөндәриҗә һәм форма якларына, типларына тукталa. Ибраһимов иптәшнең революция көрәшләренә катнашуы (шәкертләр хәрәкәте, Киевтагы татар студентлары вакыйгасы), революциядән соң коммунист һәм марксист әдип булып әверелүе турында әйтеп уза. «Ибраһимов иптәш үзе таныш булмаган, һәм үзе хис итмәгән тормыш турында язмады. Язган әйберләрне каты тәнкыйть аша үткәрде. Типларны бик нык җентекләде, әсәрләренең зур күпчелеге авыл, күпчелеге яшьләр тормышыннан алынган.

Ләкин Ибраһимовның хезмәте әдәби иҗат белән генә чикләнми, ул зур әдип булу өстенә телче, әдәбият теориячесе, педагог, тарихчы, методист, теория белән практиканы бергә бәйләүче гыйльми эшчедер. Иптәш Ибраһимов кызыл чәчәкләр чәчәргә тырышты һәм чәчте. Ул чәчәкләр яхшы йогынты астында, яхшы җирлектә калып, безгә кирәкле рәвештә өлгерделәр. Яшьләр иптәш Ибраһимовтан үрнәк алдылар. Без аның хезмәтләрен чын күңелебездән тәкъдир итәбез. Тәмам савыгып, хезмәтләрен дәвам иттерүне телибез», – дип сүзен тәмамлый.

Аннан соң әдәбият галиме Г.Ф. Линсцер язучының иҗаты һәм иҗтимагый хезмәтләре хакында рус телендә чыгыш ясый.

Җыелышта Башкортстаннан Төхфәт Янәби чыгыш ясап, башкортларның язучыны ихтирам итүләре хакында ассызыклап әйтеп уза. Татарстан профсоюзлар Советы рәисе иптәш Боярский: «Бу юбилей – Татарстан юбилее гына түгел, бәлки СССРдагы барлык хезмәт халыкларының юбилее. Без Ибраһимов иптәш коммунист булганлыгы өчен түгел, бәлки профессор Коган әйткәнчә, азатлык һәм матурлык шагыйре, зур әдип булганлыгы өчен бәйрәм итәбез», ди. Җыелыш вакытында чит төбәкләрдән, чит илләрдән телеграм-котлаулар укылып китә. Соңгы сүзне Исхак Рәхмәтуллин әйткәндә, язучының Художество фәннәре академиясенең фәхри әгъзасы итеп сайлануы, исемен мәңгеләштерү юлында эшләнәчәк чаралар хакында белдерә. Утырыш ахырында иптәш Ибраһимовка җибәрелә торган телеграмма укылып раслана.

Рәсми бүлектән соң Татар дәүләт академия театры артистлары тарафыннан язучының «Яңа кешеләр» драмасының беренче пәрдәсе сәхнәгә куела, аннан соң зур күләмдә концерт бирелә. Әлеге тантаналы утырышта сөйләнгән чыгышлар, концерт бүлекләре Казан радиостанциясе аша бирелеп барыла.

11 март көнне Г. Ибраһимов исеменнән чараны оештыручыларга, катнашучыларга үзенең рәхмәт сүзләрен җиткереп «Кызыл Татарстан» һәм «Эшче» газеталарына телеграм-хат җибәрелә һәм шунда басыла.

Шуннан соң «Кызыл Татарстан» газетасында (1928 ел, 14 март (№ 62) санында) «Галимҗан иптәш Ибраһимовның 20 еллык юбилее» исемле мәкалә-хәбәр басыла. Мәкалә башында: «Юбилей уңае белән иптәш Ибраһимов хезмәт каһарманы итеп билгеләнде, Татар педагогия җәмгыятенең фәхри әгъзасы итеп сайланды, Көнчыгыш педагогия институты янындагы татар әдәбияты кабинеты аның исеменә багышланды. Бик күп шәһәрләрдән телеграмлар, адреслар алынды, югары уку йортларының берсендә бер стипендия билгеләнде. Юбилей бик тантаналы үтте», диелә.

Шулай ук бу мәҗлескә кадәр Мәскәү шәһәрендә дә әлеге юбилей уңаеннан утырыш форматында чара уздырылган булуы мәгълүм. Аның хакында беренче тапкыр Киселев М.Ю. «Творчество Г.Г. Ибрагимова в документах архива Российской академии наук» мәкаләсендә [3] язучының әдәби һәм фәнни эшчәнлегенең 20 еллыгына багышлап Коммунистик академиядәге әдәбият һәм сәнгать секциясе белән берлектә Көнчыгышны өйрәнү фәнни ассоциациясе уздырган СССР халыклары әдәбиятын өйрәнү буенча комиссия утырышында катнашучыларның чыгышлары турында мәгълүмат китерелә. Чыгышлар Россия фәннәр академиясе архивында саклаучы Коммунистик академиянең Әдәбият һәм сәнгать институты фондында – утырышның 1928 ел 25 февраль көнге стенограммасында теркәлгәннәр [4]. Стенограмма машинкада басылган, рус телендә. Әлеге утырыш хакында «Кызыл Татарстан» газетасының 1928 елгы 2 март санында «Г. Ибраһимовның 20 еллык әдәби гыйльми-иҗтимагый хезмәт юбилее уңае белән Мәскәүдә үткәрелгән кичә хакында» исемле мәкалә басылган була. Утырышта Г.Г. Мансуров, М.Г. Максудов, И.Н. Бороздин, Н.Т. Түрәгулов, А.М. Аршаруни кебек галимнәр, дәүләт эшлеклеләре катнашалар. Утырышны Гасыйм Мансуров ачып җибәреп, Г. Ибраһимовның әдәби, фәнни, иҗтимагый эшчәнлегенә тукталып китә. Аның фикеренчә, язучының алып барган юнәлешендә хаталар юк түгел, шуңа карамастан һәрвакытта да алга ярып баручылардан саналган була. Тарихи белешмәләргә күз салсаң, 1908–1916 еллардагы шымчы донослары арасында Г. Ибраһимов исеме бик еш искә алына, аңа бары тик Октябрь революциясеннән соң гына тулы

көч белән ачылырга мөмкинлек туа. Күбрәк партия, җәмәгать эшләрендә катнаша, әдәби әсәрләр иҗат итә алмаган, ди.

Аннан соң аерым кешеләрнең чыгышлары тыңлана. Максудов үзенең докладында Г. Ибраһимовның әдәби әсәрләренең әһәмияте хакында сүз алып бара. Шәркыятьче-галим И.Н. Бороздин әдипне мәдәният эшлеклесе буларак тасвирлый. Аның чыгышында әдипне бик тә хөрмәт итүе сизелә. Ул Г. Ибраһимов белән шәхсән берничә тапкыр очрашуын, һәр очрашуы истә калып яхшы мөнәсәбәттә булуларын җылы сүзләр белән искә ала (Мәскәүдә «Сания» операсы премьерасында, Ленинградта фәннәр академиясенең 200 еллык бәйрәмендә, Бакуда I тюркологик съездында). Г. Ибраһимовның 1925 елда Академүзәк җитәкчесе буларак бик тә мөһим, файдалы эшләр башкаруы хакында ассызыклап үтә: Төбәкне өйрәнү бюросы оештыру, Татарстан этнографик материаллар туплау өчен экспедицияләр оештыру, китап бастыру эшенә басым ясый. Аңа кадәр нигездә дини китаплар гына басылган булса, бу вакытта политик брошюралар, икътисад буенча хезмәтләр, марксистик рухта әдәбият турында китаплар, В.И. Ленин хезмәтләренең тәрҗемәләре, татар әдәбияты китапханәсе булдыру һәм башка зур эшләрне башлап йөрүчеләрдән Г. Ибраһимов санала.

Алга таба Яңа төрки алфавитының Бөтенроссия үзәк комитеты вәкиле Нәзир Түрәгулов әдипнең «Борынгы ислам мәдәнияте» фәнни хезмәтенә аерым туктала. Аның фикеренчә, әлеге хезмәт «является характерной для общественных взглядов Г.Г. Ибрагимова, для характеристики его воззрений, мировоззрения на прошлое, настоящее и будущее народов Востока». Шунда ук Г. Ибраһимовның I Тюркологик съездында ясаган чыгышына үз фикерен җиткерә. Татар халкы тарихында үткәрелгән иң зур реформаларыннан саналган – ата-бабаларыбызның гарәп язуыннан латинга, ягъни яңа төрки алфавитына күчү проблемасына да туктала.

Профессор А.М. Аршаруни Г. Ибраһимовны танылган татар сәясәт һәм мәдәният эшлеклесе, сүз остасы, сүз рәссамы дип ассызыклый, шуңа да аны марксистлар рәтендә генә карау дөрес булмас, ди. Язучының «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» исемле теоретик хезмәтенә аерым тукталып уза. Бу хезмәт җәмәгатьчелек арасында җитди шау-шу тудырганын да әйтеп китә. Анда язучы М.Н. Покровский хезмәтеннән дә цитаталар китерүе, милләтнең төп билгесе буларак милли тел саналуы хакында әйтә. Монда татар халкы гына түгел, татар халкы белән тугандаш халыклар турында сүз барганлыгы күз алдында тотылуын ассызыклап күрсәтә.

Ахырда Максудов кабат сүз ала. Аның фикеренчә, Г. Ибраһимов киңкырлы шәхес: аның турында һәрьяклап – әдәби сүз остасы буларак, мәдәният эшлеклесе буларак, тарихчы буларак, марксист буларак, тәнкыйтьче буларак сөйләп була. Докладчылар арасында

Г. Ибраһимовны татар әдәбияты тәнкыйтьчесе буларак бәяләүче булмавын ассызыклый. Йомгаклап «Г. Ибраһимов кебек киңкырлы шәхеснең 20 ел буена эшләү, иҗат итү дәверендә төрле өлкәләрдә хезмәт итеп кимчелекләрсез булуы да мөмкин түгел. Мондый шәхесләр сирәк очрый. Аның иҗат юбилеен уздырганда барлык кимчелекле якларын аерып күрсәтмичә генә, аның шәхесен өйрәнсеннәр һәм киләчәк буын аңардан үрнәк алсыннар иде» дигән теләктә калабыз, диеп утырышны тәмамлый.

Мәкаләдә телгә алынган беркетмә һәм стенограмма Г. Ибраһимовның тормышы һәм иҗатына бәйле документ буларак, тагын да аның татар әдәбияты классигы, тел белгече, җәмәгать эшлеклесе буларак эшчәнлеге хакында мәгълүматны баета. Әдипне иҗади бәйрәме белән котлаган күренекле әдипләр, галимнәр чыгышларыннан күренгәнчә, язучының киң масштаблы шәхес булуын тагын бер кат дәлилли.

ӘДӘБИЯТ


1. Галимҗан Ибраһимов: Хатлар һәм документлар / Төзүче Ф. Ибраһимова. – Казан: «Фикер», 2000. – 464 б.

2. Галимҗан Ибраһимов (XX еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт бәйрәменә каратылып чыгарылган гыйльми-тәнкыйди җыентык) / Җыентык Мөхәммәт Таһиров, Габдрахман Сәгъди, Сафа Борһан, Галимҗан Нигъмәти иптәшләрдән гыйбарәт комиссия редакциясендә чыга. – Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты басмасы, 1928 ел. – 196 б.; Галимҗан Ибраһимов (XX еллык әдәби, гыйльми, иҗтимагый хезмәт туена каратылып чыгарылган мәҗмуга) / Нәҗип Җәләлов, Зыя Гыймадиев, Хәйрулла Габидовларның редакциясендә чыга. Ташкент: Татар-башкорт комиссиясе нәшере, 1928 ел. – 36 б.

3. Киселев М.Ю. Творчество Г.Г. Ибрагимова в документах архива Российской академии наук // Из истории и культуры народов Среднего Поволжья. – 2018. – № 8. – Т. 2. – С. 69–75.

4. Россия фәннәр академиясе архивы (Мәскәү), 358 фонд, 2 тасвир, 17 эш, 1–40 кгз.

5. ТР ДА П-15 фонд, 6 тасв., 6367 эштә, 28–28 об. кгз., 29–29 об. кгз. саклана.



УДК 323.1


## БЫЛ ЛИ Г. ИБРАГИМОВ ДАЛЬНОВИДНЫМ ПОЛИТИКОМ?
### (К вопросу о позиции общественно-политического деятеля относительно литературного языка в «Большом Башкортостане»)


***Д.М. Исхаков***

*Тобольская комплексная научная станция УрО РАН,*
*журнал «Туган җир. Родной край» (Казань);*

***И.З. Гарифуллин***

*Журнал «Туган җир. Родной край» (Казань)*


Г. Ибрагимов несомненно являлся одним из татарских левых интеллектуалов, оказавшихся в партии большевиков, но затем репрессирован-

ных. Его трагическая судьба и признанный вклад в татарскую литературу и гуманитарную науку, в советский период, после реабилитации, превратили Г. Ибрагимова в некоторую иконную фигуру, остававшуюся вне критики. Да и сейчас в этом плане мало что изменилось. Между тем, эпоха коммунистического бытия татарского общества осталась уже далеко позади, выглядевшие прежде безупречными его герои вроде бы должны начать рассматриваться с точки зрения современных реалий.
**Ключевые слова:** Большой Башкортостан, социолингвистическая ситуация, татарская коммунистическая элита, литературный язык, государственный язык, критическое переосмысление.

G. Ibragimov was undoubtedly one of the Tatar left-wing intellectuals who found themselves in the Bolshevik party, but then repressed. His tragic fate and recognized contribution to Tatar literature and the humanities, in the Soviet period after rehabilitation, turned G. Ibragimov into some kind of icon figure that remained uncritical. And even now, little has changed in this regard. Meanwhile, the era of the communist existence of Tatar society has already been left far behind, its heroes, who previously looked flawless, seem to have to begin to be considered from the point of view of modern realities.
**Key words:** Big Bashkortostan, sociolinguistic situation, Tatar communistic elite, literature language, state language, critical rethinking.

Галимджан Ибрагимов, являвшийся одним из видных левых татарских интеллектуалов, оказавшись волею судеб в рядах большевиков, с 1920 г. был вовлечен в национально-государственное строительство в рамках Татарской АССР, приняв самое активное участие в формировании в республике национальной гуманитарной науки и татарской советской культуры [10; 11].

Его трагическая судьба, завершенная в ходе «Большого террора» после ареста по делу о «султангалиевщине» в казанской тюремной больнице 21 января 1938 г., в результате постсталинской реабилитации (1955 г.), с учетом его крупного вклада в татарскую литературу и гуманитарную науку, превратили Г. Ибрагимов во второй половине XX в. в позднесоветском Татарстане в своего рода иконную фигуру, долгие десятилетия остававшуюся вне зоны критики. По большому счету и в нынешнее время отношение к его политической деятельности в 1920-х годах, а также к его наследию, у нас остаются еще в состоянии комплиментарности.

Между тем, эпоха социалистического бытия татарского общества осталась уже в прошлом, а выглядевшие прежде безупречными его герои, занятые строительством «нового мира», сейчас вовсе не кажутся таковыми.

Сказанное в полной мере относится и к Г. Ибрагимову, чья политическая деятельность, протекавшая в 1920-х годах в ТАССР,

The article systematizes archival material on the history of contacts between two contemporaries – Galimjan Ibragimov and Naki Isanbet. Articles, memoirs of N. Isanbet, articles of contemporaries, letters of G. Ibragimov constituted the material for the study. Biographical and cultural-historical methods of analysis were used in the work. It is proved that the roots of the conflict are not so much in the field of creativity as in the difference in the political views of these figures of Tatar culture.
**Key words:** Tatar literature, G. Ibragimov, N. Isanbet, literary groupings of the 1920s, Tatar left socialist-revolutionaries, Tolstoyism.

## Введение

В татарской литературе XX в. есть целый ряд историй, которые литературоведы до сих пор предпочитают обходить молчанием ([5] [24]). Мы считаем, что наступило время снять завесу тайны с истории конфликта Галимджана Ибрагимова (1887–1938) и Наки Исанбета (1899–1992), двух выдающихся современников, сыгравших огромную роль в истории татарской культуры XX в.

## Материалы и методы

Материалом для нашего исследования послужили научные, литературно-критические статьи, воспоминания Н. Исанбета, статьи современников, письма Г. Ибрагимова. Татарский ученый-энциклопедист на закате своей жизни постарался максимально объективно объяснить современникам и потомкам суть своих разногласий с Г. Ибрагимовым.

При написании работы использовали биографический и культурно-исторический методы.

## Обсуждение

В неопубликованной статье «Галимжан Ибраһимов һәм аңа минем мөнәсәбәтем мәсьәләсе» («Вопрос об Г. Ибрагимове и моем к нему отношении») Н. Исанбет признается: «Мин Галимҗан Ибраһимов белән белешеп, катышып яшәгән кеше түгел». – «Я не был близко знаком с Галимджаном Ибрагимовым, общих дел с ним не имел» [18: 118]. На основе изучения архивных материалов мы выявили несколько тематических блоков, проливающих свет на истинный характер взаимоотношений между Г. Ибрагимовым и Н. Исанбетом, с которыми хотим познакомить научную общественность.

Первый из них связан с оценкой творчества Г. Тукая. Н. Исанбет считал себя учеником великого поэта. Как известно, после выхода в свет книги Г. Ибрагимова «Татар шагыйрьләре» («Татарские поэты») [8] в обществе вспыхнула жаркая дискуссия (См. подр. об этом [2; 3; 4]). Н. Исанбет оказался в рядах тех, кто воспринял выход этой книги, как «враждебный творческий акт», «террори-

стическое нападение», направленные против смертельно больного Г. Тукая (Г. Карам, Баян, Вафа Бахтияров, Г. Рафики, Г. Рахим, Ф. Бурнаш и др.). В своих воспоминаниях Н. Исанбет с удовлетворением констатирует, что резкая критика Г. Ибрагимова в адрес Г. Тукая [7; 8] не изменила кардинально отношение татарского народа к творчеству Г. Тукая. Для татар он оставался по-прежнему «поэтом № 1»: «халык шагыйре булып калды». – «оставался народным поэтом» [18: 255].

Н. Исанбет признается, что всегда испытывал чисто профессиональный интерес к деятельности современника: «минем аңа мөнәсәбәтем бернинди дә шәхси дуслык яки дошманлык белән бәйләнмәгән, бәлки саф әдәби яктан һәм бары читтән торып кына». – «мое отношение к нему не привязано к личной дружбе или вражде, это скорее всего взгляд со стороны с чисто литературных позиций» (*подстр. пер. здесь и далее наш – М.Х.* ) [18: 118]. В этой статье Н. Исанбет ошибочно датирует единственную личную встречу с Г. Ибрагимовым 1928 г.: на деле они виделись накануне отъезда писателя в Крым, т.е. не позднее 21 апреля 1927 г. (см. подр.: [17]).

Размышляя над характером своих взаимоотношений с известным современником в конце 1960-х гг., Н. Исанбет приходит к выводу, что они с юности на протяжении всей жизни не претерпели каких-либо кардинальных изменений. Н. Исанбет не скрывает, что вначале принял Г. Ибрагимова за ревнивого к чужой славе «интригана»: «Була бит әдәбиятта үзеннән талантлы башка кешеләрдән көнләшүче, интриганнар, бу да шундый кеше, дип уйлый идем» – «В литературе встречаются интриганы, ревнители чужого таланта, я счел, что и он из людей такого плана» [18: 119–120]. Являясь активным участником литературного процесса 1910–1920-х гг., Н. Исанбет признает высокий статус современника в обществе «Г. Ибраһимов – ул чор татар поэзиясенең һәм поэтикасының көчле тәнкыйтьчесе һәм аны алга әйдәүче зур бер теоретигы». – «Г. Ибрагимов – был сильным критиком и крупным теоретиком, стимулирующим поступательное развитие современной татарской поэзии» («Шәйхзадә Бабич») [18: 254]. Н. Исанбет уверен, что труды Г. Ибрагимова о путях развития национальной литературы и инициированные им дискуссии благотворно сказались на формировании его собственного поэтического таланта: «Мәкаләләрендә дә, шигырь һәм поэзиянең асылы ни икәне турында олы бәхәсләр алып барганга, минем дә күзләремне бик күп яктан ачкан, миңа үз шагыйрьлегемне, йөземне билгеләүгә бик нык тәэсир иткән, йогынты ясаган, шулай булгач яхшыгамы, ямангамы, мин аңардан күп кенә нәрсә өйрәндем, миңа да ул остаз кеше иде» [18: 256]. – «Благодаря статьям, горячим дискуссиям о сути стихотворений и

поэзии, он раскрыл мои глаза на многое, благотворно повлиял на процесс моего становления как поэта и обретения своей творческой индивидуальности, поэтому, неизвестно к добру или нет, но я многому у него научился, поэтому отчасти его могу назвать своим наставником» (*Подстр. пер.*).

Н. Исанбет считает, что это выступление Г. Ибрагимова стало рубежным в истории татарской критики. Оно красноречиво продемонстрировало, что статус писателя-классика находится в ведении народа, а не отдельно взятого критика. Критик, прекрасно ориентирующийся в родной культуре, лишь тогда, по мнению Н. Исанбета, добьется единства своей точки зрения с мнением народным, если в своей деятельности будет максимально принципиальным и объективным [18: 256].

Н. Исанбет считает, что труд Г. Ибрагимова «Татар шагыйрьләре» («Татарские поэты», 1913) при всей субъективности заявленных в нем оценок сыграл огромную роль в развитии татарской поэзии. Во-первых, эта работа оказала сильное воздействие на самого Г. Тукая (см. статью «Уянгач беренче эшем» – «Первое дело после того, как проснулся»). Во-вторых, стимулировал современных поэтов к поиску своего стилевого своеобразия, обретению своего творческого лица. В-третьих, продемонстрировал, какую роль играет поэзия и критика в жизни общества. В-четвертых, выявил состоятельность Г. Ибрагимова как теоретика литературы и критика [18: 257].

*Второй блок материалов связан с педагогической деятельностью Н. Исанбета.* В своих воспоминаниях ученый-энциклопедист указывает, что на заре своей педагогической карьеры учил детей в медресе по учебникам Г. Ибрагимова [14; 18: 395]. В конце 1960-х г. А. Шамов при подготовке сборника воспоминаний о Г. Ибрагимове решил переименовать статью Н. Исанбета с «Г. Ибраһимов турында бер истәлек» («Одно воспоминание о Г. Ибрагимове») на «Остазыбыз иде...», что вызвало возмущение автора. В результате возникшей конфликтной ситуации статья не вошла в сборник. В 1987 г. она увидела свет на страницах журнала «Казан утлары» [14]. Вместе с башкирским писателем Давыдом Юлтыем Н. Исанбет стал свидетелем разговора известного писателя с директором татарского театра Заки Баязитским, который принес ему на квартиру подшивку газеты «Урал» (ред. Хусаин Ямашев), выходившей в Оренбурге в 1905 г. Среди качеств, присущих Г. Ибрагимову, Н. Исанбет выделяет самоотверженность и трудолюбие: «Без Галимҗанны шушы авыр хәлендә дә һаман язуын күреп, аның бик тырыш кеше булуына гаҗәпләндек». – «Мы удивились, что Галимжан, даже находясь в столь тяжелом состоянии, продолжал активно писать, что свидетельствовало о том, что

был он очень трудолюбивым человеком» (*Подстр. пер.*) [18: 398]. В своих воспоминаниях Н. Исанбет указывает, что на раннее творчество Г. Ибрагимова благотворное влияние оказало его активное участие в шакирдском движении. В архивной копии этой статьи есть важное авторское примечание, указывающая на суть принципиальных разногласий с мэтром: «Инде Г. Ибраһимовның Г. Тукайга булган мөнәсәбәте һәм дә Г. Ибраһимов фикерләре белән ни өчен килешмәвем турында бу мәкаләдә тукталынмады. Бу хакта башка урында күрсәтеләчәк. *Н. И.*» – «В этой статье нет информации об отношении Г. Ибрагимова к Г. Тукаю и причинах моих расхождений с взглядами Г. Ибрагимова. Об этом я напишу в другом месте. *Н. И.*». (*Подстр. пер.*).

*Третий блок связан с продвижением произведений Н. Исанбета*. В воспоминаниях о Ш. Бабиче писатель признается, что в 1918 г. печатал свои стихотворения в изданиях, которые находились под контролем Г. Ибрагимова [9; 12]. По воспоминаниям супруги писателя Гульсум Исанбет, Наки ага на раннем этапе своего литературного творчества не сильно спешил с изданием своих произведений. Г. Ибрагимов способствовал продвижению трагикомедии «Һиҗрәт» («Переселение»). Как-то из «Академцентра» драматург получил письмо о включении своего произведения в серию книг «Библиотека татарских книг» с резолюцией Г. Ибрагимова *«Бастырырга»* («В печать»). Н. Исанбет опубликовал «Һиҗрәт» («Переселение») только в 1963 г. [18: 416].

*Четвертый блок материалов связан с критической деятельностью Н. Исанбета и последовавшими за публикациями его работ трагическими последствиями.* Перу Н. Исанбета принадлежит несколько работ, посвященных деятельности Г. Ибрагимова. Первая из них датируется 1924 г. Опубликована под псевдонимом *Мәргән*. Это отклик на повесть Г. Ибрагимова «Адәмнәр» («Люди») [16].

В разгар дискуссии о латинице выходит статья Н. Исанбета «Иске батырлар, миссионерлар, динләр, интригалар» («Старые богатыри, миссионеры, религии, интриги») [13]. Известно, что в этот период автор статьи был сторонником введения латинницы, т.к. считал, что эта графика упростит и убыстрит интеграцию татарской культуры в рамки мира. По воспоминаниям Юлдуз Исанбет, позднее Н. Исанбет изменил свою точку зрения по данному вопросу.

В 1928 г. увидела свет научная статья в газете «Яңа авыл» [10], вызвавшая мощный резонанс в татарском обществе [1; 19; 20; 25]. Она была посвящена анализу творчества Г. Ибрагимова за два десятилетия [11].

Корень разногласий Н. Исанбета с Г. Ибрагимовым следует искать в их расхождениях в политических взглядах. Как толстовец, сторонник гуманного преображения общества, Н. Исанбет был резко настроен против татарских левых эсеров. Он пристально наблюдал за их деятельностью в Уфе и был не согласен с методами их работы. В своих воспоминаниях Н. Исанбет называет имена эсеров, лидером которых был Г. Ибрагимов: Фатих Сайфи, Гумер Альмухаметов, Газыйм Касымов, Заки Аминев, Заки Гимранов, Гилемдар Баембитов. В 1920 г. Г. Ибрагимов вступил в ряды Коммунистической партии и с частью соратников переехал в Казань: «ул елларда Галимҗан Ибраһимов Казанда иң зур әдәби һәм сәяси авторитет булып, җитәкче урын тота» – «в эти годы Галимджан Ибрагимов в Казани работал на руководящих должностях, будучи одним из самых влиятельных литературных и политических авторитетов» (*подстр пер.*) («Газыйм Касыймов белән мөнәсәбәт») [18: 459]. Н. Исанбет отмечает, что бывшие эсеры, оказавшись в Казани, всячески поддерживали земляков, но вскоре распались на группировки «латинистов», «арабистов» и др.. Н. Исанбет считал левых эсеров-террористами. По его мнению, их террористические наклонности ярче всего проявились в годы репрессий и вылились в физическое истребление своих противников [18: 470].

Ученый-энциклопедист в конце 1960-х г. признает, что был в известной доле субъективен при написании юбилейной статьи о Г. Ибрагимове в 1928 г., однако в формулировках ключевых положений старался оставаться объективным. Н. Исанбет не скрывает, что хотел отомстить за Г. Тукая. Писатель, выразив в начале статьи сомнение в уместности празднования юбилей Г. Ибрагимова в Казани вообще, призвал казанцев заняться более стоящими делами.

Статья состоит из 6 частей. В первой из них автор убедительно доказывает, что Г. Ибрагимов является романтиком по мироощущению. Н. Исанбет на свой лад сформулировал эстетическое кредо писателя-современника:

1) Настоящее стихотворение – это «плод свободного чувства»;

2) Настоящее стихотворение должно возноситься к божественным мирам;

3) Настоящее стихотворение служит только искусству («искусство для искусства»),

4) Настоящее стихотворение понятно не массам, а избранным,

5) Автор настоящего стихотворения должен быть индивидуалистом, носителем абсолютной свободой, не подчиняющийся земным законам;

6) В настоящем стихотворении не должно быть агитации, дидактики, приземляющих его.

Во второй части Н. Исанбет раскритиковал произведения Г. Ибрагимова: «Зәки шәкерт» (Заки-шакирд), «Татарниләр күрми» («Чего не доводиться увидеть татарам»), «Яшьләр хәятеннән бер ләүхә» («Одно событие из жизни молодежи»), «Яшь йөрәкләр» («Молодые сердца»). Ахиллесовой пятой писателя-романтика является, по мнению автора статьи, слабое знание жизни, что негативно отражается на содержании произведений. Н. Исанбет считает вершинным произведением писателя роман «Казакъ кызы» («Дочь степи»), а не роман «Яшь йөрәкләр» («Молодые сердца»), которому, по его мнению, не хватает цельности, художественности.

Н. Исанбет критикует Г. Ибрагимова за неумение отделить речь персонажа от речи автора в прозе, огрехи в выстраивании диалога в драме. Досталось писателю и за включение «порнографических сцен» в свои произведения («Яшь йөрәкләр» («Молодые сердца»), «Безнең көннәр» («Наши дни»), «Кызыл чәчәкләр» («Красные цветы»)). Н. Исанбет считает, что по степени увлеченности сексуальными сценами Г. Ибрагимов может соперничать только с русским писателем М.П. Арцыбашевым (1878–1927).

Автор статьи указывает на присущее татарскому писателю мастерство в создании сцен природы.

Одной из главных особенностей писательского дарования Г. Ибрагимова Н. Исанбет считает склонность к созданию объемных произведений, среди которых только роман «Казакъ кызы» («Дочь степи») удостоился чести считаться классическим произведением.

В третьей части в фокусе внимания Н. Исанбета оказался «пестрый» язык Г. Ибрагимова. Автор статьи констатирует, что его современник пишет произведения на смеси татарского с казахским. В языке Г. Ибрагимова Н. Исанбет указывает на заимствования из языка тюрки, казахского и русского языков. Автор статьи резко отрицательно реагирует на включение в татарские произведения чуждых татарскому языку конструкций. Н. Исанбет рекомендует Г. Ибрагимову активизировать работу по выработке самобытного писательского языка. В тоже время автор статьи комплиментарно отзывается об огромном вкладе Г. Ибрагимова, внесенном в развитие татарского языкознание (речь идет о создании учебников по татарскому языку).

В 4 части Н. Исанбет анализирует мировоззрение Г. Ибрагимова. Автор статьи подчеркивает, что писатель до революции был идеологом романтизма, по политическим убеждениям – татарским левым эсером, а после революции под давлением обстоятельств превратился в марксиста.

Подводя итоги своему исследованию, Н. Исанбет призывает читателей объективно оценивать творчество Г. Ибрагимова, не превращая его в идола-»кумира», «идеолога» [11].

В прессе развернулась настоящая полемика: с критикой Н. Исанбета выступили Г. Нигмати [19], К. Наджми, Т. Янаби [25], с поддержкой – Г. Габбасов [1]. Вскоре дискуссия превратилась в травлю инакомыслящих. Г. Нигъмати ввел в оборот понятие «исанбетовщины». К. Наджми развернул компанию против «Джидегян». Руководил этой работой против Н. Исанбета лично Г. Ибрагимов. В письме к К. Наджми от 23 января 1931 г. бывший лидер левых эсеров призвал не церемониться с Ф. Бурнашем-султангалиевцем и Н. Исанбетом-»черным контреволюционером», являющимися членами «Джидегян», заткнуть им глотки, чтобы прекратить их «лай» [6]. Однако Н. Исанбет через три месяца после ареста вышел на свободу, т.к. следствие все обвинения, выдвинутые против него, сочло несостоятельными. Пока писатель находился в тюрьме, его семья оказалась без средств к существованию (см. подр. [18: 398–454])

В архиве Н. Исанбета хранится еще одна статья, имеющая отношение к Г. Ибрагимову: «Бер эпиграф турында» («Об одном эпиграфе») [18, 593–607]. В ней Н. Исанбет использует имя классика как ширму для продвижения творчества репрессированного казахского поэта М. Жумабаева. Н. Исанбет исследует историю бытования эпиграфа к роману «Казакъ кызы», дает оценку взглядам Г. Ибрагимова на казахскую культуру, кратко характеризует деятельность литературного кружка шакирдов медресе «Галия» (Уфа) (См. более подр. [15]).

Имя Г. Ибрагимова упоминается и в книге Н. Исанбета «Җәдитчелек турында» («О джадидизме»), где констатируется, что Г. Ибрагимов по своим убеждениям был джадидом-просветителем (См. подр.: [18, 562–592 б.]).

*Пятый блок материалов связан с служебной запиской Н. Исанбета к Генеральному секретарю Союза писателей СССР В.П. Ставскому от 19 ноября 1937 г.* Р. Мустафин обвинил Н. Исанбета в гибели Г. Ибрагимова. Мы доказали несостоятельность этих обвинений в ряде наших работ [21], [22], [23]). Это ложное обвинение родилось в пылу разборок на фоне судебного процесса о нарушении авторских прав при издании сводного текста дастана «Идегей» (см. подр: [18: 676–679, 691–692, 693–709]). Новые доказательства нашей версии мы обрели в результате переписки с родственником великого писателя – Маратом Хаковичем Ибрагимовым из Уфы, который подтвердил, что в личном деле Г. Ибрагимова имя Н. Исанбета не упоминается. Служебная записка к В.П. Ставскому [Ф. 631, оп. 6, ед. хр. 376] была обна-

ружена в литературном архиве, а не в архиве КГБ, что косвенно свидетельствует о том, что она никогда не использовалась в качестве доказательства для вынесения приговоров в годы сталинских репрессий.

Г. Ибрагимов и Н. Исанбет – яркие представители татарской культуры XX в., сыгравшие огромную роль в ее развитии. Непримиримый характер их взаимоотношений в первой трети XX в. объясняется характером развернувшейся в это время классовой борьбы и борьбы литературных группировок в Уфе и Казани. Н. Исанбет посвятил Г. Ибрагимову ряд работ, в которых постарался объективно показать характер их творческих контактов. Ученый-энциклопедист восхищался своим современником как ученым-теоретиком и практиком, но не принимал методов его политической борьбы с оппонентами.

ЛИТЕРАТУРА

1. Габбасов Г. Ике тәнкыйть турында // Яңа авыл. – 1928. – 27 март (№ 36).

2. Гилазов Т. Литературная репутация Тукая в эстетической концепции Г. Ибрагимова // Известия ВГПУ. – 2009. – № 10 (44). – С. 172–174.

3. Гилазов Т. Проблема литературной репутации Г. Тукая в научно-критической мысли первой четверти XX века // Филология и культура. Philology and Culture. 3 (33). – 2013. – С. 181–185.

4. Гыйлаҗев Т.Ш. Ибраһимов Галимҗан Гирфанович // Габдулла Тукай. Энциклопедия. – Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. – 276-277 б.

5. Жизнь и творчество Галимджана Ибрагимова. – Казань: ИЯЛИ, 2017. – 333 с.

6. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр: 8 томда. – 9 т. (өстәмә): хатлар, документлар. – Казан: Фикер, 2001. – 464 б.

7. Ибраһимов Г. Талант трагедиясе // Йолдыз. – 1914. – 2 сентябрь.

8. Ибраһимов Г. Татар шагыйрьләре. – Оренбург, 1913. – 74 б.

9. Исәнбәт Н. Бу минут: [шигырь] // Чулпан. – М., 1918.

10. Исәнбәт Н. Галимҗан Ибраһимов әдәбияты: (20 еллык хезмәте буенча) // Яңа авыл. – Уфа, 1928. – 10 (№ 30), 14 (№ 31) март.

11. Исәнбәт Н. Галимҗан Ибраһимов әдәбияты // Мирас. – 2006. – № 5. – Б. 48–57.

12. Исәнбәт Н. Инкыйлаб: шигырь // Кызыл Армия. – М., 1918. – 20 апр. (№ 1).

13. Исәнбәт Н. Иске батырлар, миссионерлар, динләр, интригалар: (Латин мәсьәләсе) // Яңа авыл. – Уфа, 1926. – 27 май (№ 59). – Б. 3–4.

14. Исәнбәт Н. Остазыбыз иде…: [Г. Ибраһимовның 100 еллыгына] // Казан утлары. – 1987. – № 3. – Б. 19.

15. Машакова А.К., Хәбетдинова М.М. Татар мәдәниятендә Мәгъҗан Җомабаев иҗаты рецепциясе // Tatarica. – 2020. – № 2 (15). – С. 34–53.

16. Мәргән «Адәмнәр»: [Г. Ибраһимов әсәре] // Башкортстан. – 1924. – 16 гыйнв. (№ 7). – (Матбугат дөньясында).

17. Миннуллин К.М. Первые научно-исследовательские центры у татар в первой трети XX в. и деятельность Г. Ибрагимова // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2017. – С. 32–34.

18. Нәкый Исәнбәт: фәнни-популяр җыентык. – Казан: «Җыен» нәшр., 2021. – 736 с.
19. Нигъмәти Г. Бритва // Кызыл Татарстан. – 1928. – № 40.
20. Нигъмәти Г. Матбугат һәм әдәбиятка юлбашчылыкта авыру яклар: [Н. Исәнбәт һәм Г. Габассов мәкаләләренә тәнкыйть] // Кызыл Татарстан. – 1928. – 3 апр. (№ 77).
21. Хабутдинов А., Хабутдинова М. Образ Наки Исанбета в татарской прозе // Филология и культура. Philologie and Culture. – 2019. – № 4(58). – С. 191–201.
22. Хабутдинова М.М. Идейно-художественное своеобразие драматической поэмы Р. Хариса «Идегей» // Филология и культура. Philologie and Culture. – 2021. – № 2(64). – С. 207–213.
23. Хабутдинова М.М. Нет оснований обвинять Н. Исанбета в доносительстве и воровстве // Сетевое издание «Снег». 31 января 2020 г. URL: https://sntat.ru/news/mileusha-habutdinova-net-osnovaniya-obvinyat-naki-isanbeta-v-donositelstve-i-vorovstve-5718358? (дата обращения 21.02.2021).
24. Хасанов М.Х. Галимджан Ибрагимов: монография. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1977. – 432 с.
25. Янәби Т. Казанга барып кайткач // Башкортстан. – 1928. – 28 март. – № 36.

# ЛИТЕРАТУРНОЕ ТВОРЧЕСТВО Г. ИБРАГИМОВА: ХУДОЖЕСТВЕННЫЙ И ТЕОРЕТИЧЕСКИЙ ДИСКУРСЫ

УДК 82.02/.09

## АМИРХАН ЕНИКИ О ЛИЧНОСТИ ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА

***Г.Р. Гайнуллина***
*Казанский (Приволжский) федеральный университет (Казань)*

В статье дается обзор публицистических статей Амирхана Еники, посвященных раскрытию роли личности Г. Ибрагимова в формировании национальной прозы. А. Еники высоко оценивает роль Г. Ибрагимова как общественного деятеля, журналиста, критика. В статьях писатель называет его идейным вдохновителем, проложившим путь в новой литературе, национальном образовании и общественном движении.
**Ключевые слова:** А. Еники, Г. Ибрагимов, публицистика, личность, литература.

The article provides an overview of journalistic articles by Amirkhan Eniki, devoted to the disclosure of the role of G. Ibragimov's personality in the formation of national prose. A. Eniki highly appreciates the role of G. Ibragimov as a public figure, journalist, critic. In his articles, the writer calls him the ideological inspirer who paved the way for new literature, national education, and social movement.
**Key words:** A. Eniki, G. Ibragimov, journalism, personality, literature.

## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ШӘХЕСЕ ТУРЫНДА ӘМИРХАН ЕНИКИ

***Г.Р. Гайнуллина***
*Казан (Идел буе) федераль университеты (Казан)*

Татар әдәбиятының йөзек кашы, күренекле язучы Әмирхан Еники (1909–2000) «Соңгы китап» романында, эсселарында, публицистик иҗатында үзе күргән, белгән шәхесләр турында күп яза. Әдип татарның йөзек кашы булган Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Г. Исхакый, Һ. Такташ, С. Кудаш, Н. Исәнбәт, Б. Урманче, Х. Туфан, С. Сәйдәш кебек шәхесләр хакында бик күп язмаларында искә ала. Мәкаләләр, истәлекләрдә милләтнең зыялы шәхесләре, укымышлы

затлар, классик әдипләр белән очрашулар, бәһаләп бетергесез кыйммәтле сөйләшүләр хакында да сүз бара.

«Таң ата да кич була» язмасында Ә. Еники болай яза: «Мин яшем белән бер-берсенә һич охшамаган ике буын арасына туры килдем: иске буын әле китеп бетмәгән, ә яңасы туып, күтәрелеп кенә килә иде... Искеләре дигәнем гасыр башында мәйданга чыгып, милли мәдәниятебездә күренекле урын тоткан шәхесләр – Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Галиәгар Камал, Җамал Вәлиди, Гали Рәхим, Садри Җәләл һ.б.» [1: 76].

Әле 30 яше тулганчы ук язучы, әдәбият галиме, тәнкыйтьче, журналист, тарихчы, тел белгече һәм педагог, җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче булып танылган Галимҗан Ибраһимов шәхесе [3: 6] әдипнең күп язмаларында төрле яклап ачыла. Язучы буларак Ә. Еники Г. Ибраһимов шәхесе турындагы «Безне ул өйрәтте» дип исемләнгән мәкаләсендә үзен «Галимҗан мәктәбе» вәкиле дип атый [2: 465]. «Соңгы китап» романында язучы үзенең беренче хикәясе басылу уңае белән Г. Ибраһимов исемен болай искә ала: «Гомәр Гали минем шул әйберемне, яртылаш кыскартып, «Озын көй тыңлаганда» дигән исем белән «Безнең юл»да басып та чыгарды (1926 ел, март саны). Һич көтелмәгән гаҗәеп бер эш булды бу минем өчен... Беренче тапкыр дөньяга басылып чыгуым, җитмәсә, «Безнең юл» кебек иң дәрәҗәле, иң күренекле бер журналда!.. Әгәр шул санны ачып карасагыз, сез анда Галимҗан Ибраһимов һәм Габдрахман Сәгъди мәкаләләрен, Такташ, Кутуй, Туфан шигырьләрен, Толымбай, Гомәр Гали хикәяләрен күрерсез – әнә кемнәр арасына килеп кергән бит без фәкыйрегез дә!.. » [2: 182].

Ә. Еники «Соңгы китап» романында бер яктан Г. Ибраһимов иҗаты белән танышудан алган тәэсирләрен яза: «...Һич онытасым юк Галимҗан Ибраһимовның «Безнең көннәр»ен икәү алмашлап укып чыгуыбызны! Сары кәгазь тышлы, соры кәгазьгә басылган, әдипнең креслога утырып төшкән рәсеме дә урнаштырылган бу Коръәннән дә калынрак роман безне тәмам йотты, әсир итте, без аңардан аерыла алмас булдык, тиз генә бетмәвен, уку рәхәтенең бер дә өзелмичә дәвам итүен теләдек. Моңарчы да мин үзем генә яки икәү бергә укыган матур китаплар аз булмады, әмма «Безнең көннәр» кебек бу хәтле дә безгә ошаганы, безне беткәнче биләп алганы булды микән? Моның сәбәбен без ул чакта, бәлки, аңлап та бетермәгәнбездер, ләкин шулай да романның бер ягын сизмичә һәм тоймыйча калмадык: роман үзенең эчтәлеге, ягъни чоры, вакыйгасы, кешеләре белән безнең өчен гаять яңа һәм кызыклы иде. Менә ни өчен аның күп кенә каһарманнары да – Даут Урманов, Хәбиб Мансуров («Сруҗе»), Сәхип шәкерт, Гөлбикә, Баязит карый, морза кызы Рауза, Даутның сөйгәне Нәфисәләр – барысын да атап чыгу мөмкин түгел – хәзергә чаклы онытылмыйча хә-

тердә сакланып килделәр. Мондый хәл сирәк була. Ихтимал, шуңа күрәдер, мин бу романның әдип тарафыннан утызынчы елларның башларында төзәтелгән вариантын шушы көнгә кадәр укырга җөрьәт итә алганым юк, ничектер менә беренче басмасыннан алган тирән тәэссоратны югалтырмын дип куркам» [2: 316].

Икенче яктан, Ә. Еники автобиогафик романда Г. Ибраһимовның язучы буларак кыюлыгына басым ясап үтә: «Егерме беренче ел ачлыгы табигый буларак безнең әдәбиятта да чагылмыйча калмады. Әмма аның иң фаҗигале, иң ачык-шәрә күренешләре Галимҗан Ибраһимовның «Адәмнәр» исемле әсәрендә тасвир ителгән иде. Әнә шул артык «натуральный», артык берьяклы булуы өчен ул әсәр үз вакытында каты гына тәнкыйтькә дә юлыкты» [2: 305].

«Бер сорауга бер җавап» дигән баш астында дөнья күргән әңгәмә жанрындагы язмасында «Татар әдәбияты үсешендә Г. Ибраһимовның роле нинди?» дигән сорауга Әмирхан Еники өч яссылыкта якын килеп җавап бирә: «Галимҗан Ибраһимов – зур шәхес: әдип, галим, җәмәгать эшлеклесе. Сүз билгеле, матур әдәбият һәм аның да проза дигән жанры турында барырга тиештер инде: безнең проза үсешендә Галимҗан Ибраһимовның әдип-художник буларак роле нинди? Бу сорауда игътибарны иң элек үзенә җәлеп иткәне – «үсешендә» дигән сүз... Димәк, проза әдәбиятыбызның Галимҗан Ибраһимовка чаклы хәленә дә күз салырга кирәк була... Һәм күз салу белән ике нәрсәгә хәйран калырга туры килә: бер яктан бик нык артка калу, икенче яктан гаҗәп тиз алга китү... Башта Муса Акъегетнең «Хисаметдин мелла»сы, аның артыннан ук Заһир Бигиевның «Меңнәр яки гүзәл кыз Хәдичә» романы (1887 елда) дөньяга чыкса, алардан соң тиз арада Риза Фәхретдинов, Фатих Кәрими, Закир Һади, Мәҗит Гафури һәм башка язучыларыбызның яңа проза әсәрләре бер-бер артлы чыга башлыйлар. Боларга ялганып ук диярлек иҗатларын барысыннан элек прозага багышлаган Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал, Садри Җәләл, Ярулла Вәли, Шаһит Әхмәдиевләр әдәбиятка килеп керәләр. Исемнәр күп... Кыска гына вакыт эчендә әдәбият, матбугат, нәшрият эшләре искиткеч бер җанлану һәм күтәрелү кичерде. Әмма хикмәт гомуми җанлану, язучылар саны күбәеп китүдә генә түгел иде. Иң мөһиме – сыйфат ягыннан тиз үсү-үзгәрүдә иде. Әдәби телебезне сафландыру һәм камилләштерүдә Галимҗан Ибраһимовның тоткан роле гаять зур. Сыйфат ягыннан үсүнең икенче мисалы итеп, мин прозада жанрларның төрләнүен һәм ачык билгеләнүен әйтер идем. Озак та үтми, романны озын хикәядән (повестьтан), озын хикәяне кыскасыннан аерып була башлый (билгеле, күләм җәһәтеннән генә түгел). Болар жанр буларак формалашу белән бергә, һәркайсының зур осталары да мәйданга чыга. Һәр өч жанрның, бигрәк тә повесть белән

хикәяләрнең, гүзәл үрнәкләрен Фатих Әмирхан белән Шәриф Камал бирәләр. Мәгәр шулай да бу өлкәдә дә Галимҗан Ибраһимов иҗаты ныграк аерылып тора. Киң колачлы романнарны, төгәл, камил язылган хикәя, повестьларны безнең әдәбиятта башлыча ул тудыра. Димәк, әлеге сорауга тагын бер җавап: «татар әдәбиятын прозаның төрле жанрлары белән баетуда Галимҗан Ибраһимовның роле шөбһәсез бик зур... Ахыр килеп, матур әдәбиятыбызның сәнгать булып җитешүендә Галимҗан Ибраһимовның роле шулай ук бик зур» [2: 617].

Г. Ибраһимовның әдәбиятыбызны үсешен яңа югарылыкка күтәрүе хакында Ә. Еники төрле язмаларында аеруча басым ясап кабатлый. «Безне ул өйрәтте» дип исемләнгән мәкаләдә язучы әдәби текстта Г. Ибраһимов кулланган хикәяләү алымнарын нәзари яссылыкта барлый. «Галимҗан Ибраһимовка кадәр безнең яңа проза бик яшь иде әле. …Асылда Европа төшенчәсендәге проза әдәбияты бездә XX йөзгә кергәч кенә күтәрелеп китә. Ләкин ул чактагы роман, повесть, хикәяләрнең теле никадәр чуар, стиле (хикәяләү алымы) никадәр примитив булуын әйтеп тә торасы юк» [2: 465]. Прозага Ф. Әмирхан белән Г. Ибраһимов килеп керүен әдип «проза әдәбиятының яңа биеклеккә күтәрелүе, өр-яңа сыйфатлар белән баюы, рус һәм Европа прозасына охшаш бер кыяфәткә керүе» дип бәяли: «Без чын мәгънәсендәге роман һәм хикәяләр укый башладык. Хәтта чәчмә әдәбиятлары әле туып та өлгермәгән тугандаш халыклар да, татар прозасына игътибар итеп, аңардан өйрәнә, үрнәк ала башладылар» [2: 465].

Ә. Еники карашынча, беренчедән, Г. Ибраһимов «хикәяләү чарасының компонентларын бик нык арттырды: без инде аның әсәрләрендә кешеләрнең тулы портретларын күрәбез, характер үзенчәлекләрен, рухи кичерешләрен ачык сизәбез; безгә инде ул үзенең әсәрләрендә вакыйганы хикәяләү өчен кирәк булган вакыт, хәл-шарт, көнкүреш элементларын әйтеп кенә узмыйча, аларны детальләр ярдәмендә ачык картиналар итеп сурәтләп күрсәтә» [2: 465]. Икенчедән, «әдипнең әсәрләре шигърияткә бай», ягъни табигатьне чагылдыруга аерым игътибар бирә башлый, авторның фикерен көчәйтү өчен символик образ, табигать күренешен файдалана. Өченчедән, Г. Ибраһимов «диалог формаларын төрләндерә, эчке монологларга киң урын бирә, хикәяләүне һәрвакытта да хәрәкәтчән алып бара» [2: 465].

Әдип әсәрләренең теле турында Ә. Еники аерып билгеләп үтә: «Асылда ул безгә проза теленең иң үтемле, саф татарча үрнәген эшләп калдырды. Аның бу үрнәгендә без телебезнең гаҗәеп бай эчке мөмкинлеген, фикерне әйтеп бирә алуда һәм сурәтләп күрсәтүдә зур сәләткә ия булуын күрдек. Галимҗан аркасында безнең телебез, үзенең саф татарча булуын саклаган хәлдә, ничектер

мәдәниләште, камилләште» [2: 465]. Ахыр килеп, әдип Г. Ибраһимовтан соң әдәбият мәйданына аяк баскан әдипләрең «аның көчле йогынтысына бирелүен» табигый дип саный.

Автобиографик романында әдип Г. Ибраһимовны инкыйлабтан соңгы әдәби-мәдәни барышының «бәхәссез лидеры» дип атый: «Бу вакытларда Казанда әдәбият дөньясы, Тукайчарак әйтсәк, шәп кенә кайнамакта иде инде. Революциядән соң гына мәйданга күтәрелеп чыккан яңа, яшь көчләр – Шамил Усманов, Һади Такташ, Кави Нәҗми, Г. Толымбайский, Гомәр Гали, Гадел Кутуй (аз гына соңрак Хәсән Туфан) – менә шулар ул чакта әдәби хәрәкәтнең үзәгендә торалар. Алардан шактый өлкән, революциягә чаклы ук инде яза башлаган Фатих Сәйфи-Казанлы, Фәтхи Бурнаш, Кәрим Тинчурин кебек абыйлар аз гына читтәрәк һәм өстәрәк торалар иде бугай – хәер, мин моны үзем чамалап кына әйтәм. Әдәбиятның танылган бәхәссез лидеры, әлбәттә, Галимҗан Ибраһимов иде. Әмма аны да бары шәһәр күләмендәге зур җыелышларда гына күрә идек [2: 203].

Шул рәвешле, Әмирхан Еники Г. Ибраһимовны язучы буларак әдәбиятыбызны үзгәрткән шәхес буларак олылый.

Г. Ибраһимовның тел белгече, җәмәгать эшлеклесе буларак кыю, хөр фикерле, алдынгы карашлы шәхес буларак бәяләп, Ә. Еники «Чынбарлык һәм туган тел мәкаләсендә болай яза: «Латинга күчәр алдыннан бәхәсләр бик күп булды. Күпчелек күчү ягында иде, бигрәк тә укучы яшьләр. Мәгәр тел галимнәре һәм өлкән буын язучылар күчүне мәгъкуль күрмәделәр. Аеруча Галимҗан Ибраһимов хәреф алыштыруның вакытсыз, кирәксез, хәтта зарарлы икәнен, теше-тырнагы белән дигәндәй, исбат итәргә тырышты. Халыкны уку-язудан гына түгел, гасырлар буенча җыела килгән рухи мирастан да аеру булачагын, моның культура революциясе барган чакта һич ярамаячагын кат-кат әйтеп чыкты. Латинга күчүнең вакытлы гына булачагын, иртәме-соңмы барыбер руска күчәргә туры киләчәген дә ул алдан кисәтеп куйды» [2: 622].

Ә. Еники язмаларында Г. Ибраһимовның сәяси карашларын да билгеләп үтә. «Татар мәсьәләсе» мәкаләсендә болай яза: «Большевиклар партиясе, Россиянең гаять авыр хәленнән файдаланып, артык кан түкмичә генә, властьны үз кулына ала. Яңа власть беренче көннән үк халыкны үз ягына аударырлык бик мөһим «Солых» һәм «Җир» турындагы декретлары белән беррәттән, тиз арада «Милләтләр азатлыгы турындагы» декретын да игълан итә. Бу декретның төп мәгънәсе, Галимҗан Ибраһимов язганча, «һәммә милләтләрнең үз язмышларын үзләренә тапшыру, Русиядән аерылып чыгуга кадәрле милли мохтарият бирү»дән гыйбарәт иде. Менә шуннан соң инде «Татар мәсьәләсен» конкрет рәвештә хәл итү көн тәртибенә куела. Ничек итеп, нинди юллар белән?

Баштарак әле моны чишүдә Октябрь революциясен кабул итүчеләр белән бергә кабул итмәүчеләр дә актив эшлиләр. Эш бик кызу бара, ике як та үзләренең съездларын, мәҗлесләрен, киңәшләрен үткәрәләр. Кискен бәрелешләр күп була, күп карарлар чыгарыла. Нәтиҗәдә татар язмышын хәл итүнең ике төп юлы формалаша. Болар – «милли мәдәни мохтарият» һәм «тупраклы автономия». Галимҗан Ибраһимов аларның беренчесен «унитаризм», икенчесен «федерализм» дип атый. «Унитаризм» дигәне Россиянең теләсә кайсы почмагында яшәүче татарларга бер үзәктән идарә ителә торган «милли-мәдәни мохтарият» бирүдән гыйбарәт... Моның өчен Россия күләмендә аерым мөстәкыйль татар парламенты сайлау күздә тотыла. Татар халкына кагылган бөтен эшләр белән шул парламент идарә итәргә тиеш була. Шуңа күрә аны «унитаризм» дип атаганнар да. Ә «тупраклы автономия» дигәне татарлар тупланып яшәгән территориядә аерым милли җөмһүрият (республика) төзүдән гыйбарәт булырга тиеш. Ләкин бу ике вариант арасындагы кискен көрәш озакка бармый. Чөнки беренче вариант большевикларга бер дә ошамый, гадәтләренчә алар «милли-мәдәни мохтарият»не бары буржуазия максатларына хезмәт итүдә, ә аның тарафдарларын милләтчелектә гаеплиләр. «Унитаризм»ны үткәрү юлында татар уңнарының корган барлык интригалары, провокацияләре юкка чыкты» дип, усал яза Галимҗан Ибраһимов та «Татар-башкорт җөмһүрияте» дигән җыентыкның кереш сүзендә» [2: 654]. «1918 елның язында, штат урынына «Татар-башкорт шуралар җөмһүрияте»н булдыру идеясе туа. Совет хөкүмәте бу идеяне хуплый һәм кабул итә. Озакламый аның проекты да төзелеп, югары партия һәм дәүләт органнарында карала. Карарга Сталин, Мулланур Вахитов, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Манатов кул куйганнар. Датасы 1918 ел, март ае» [2: 656].

Тәнкыйтьче буларак Г. Ибраһимовның хөр фикерле үрнәк шәхес буларак бәяләп, Ш. Бабич шәхесен күтәрүенә, Т. Ченәкәй шәхесен кыю рәвештә яклавына соклануын әдип «Ченәкәй кем ул?» мәкаләсендә язып чыга: «1922 елны Казанда беренче мәртәбә чыккан Бабичның «Шигырьләр мәҗмугасы», асылда, Ченәкәй җыеп тапшырган әсәрләрдән төзелә. Галимҗан Ибраһимов җыентыкка язган зур күләмле кереш мәкаләсендә Ченәкәйнең изге эшен тәкъдирләп, аңа махсус тукталып уза» [2: 820].

Г. Ибраһимов белән очрашу язучының кальбен ныгыткан, иҗади кыйбласын тәрбияләгән, ниһаять, әдипнең исемен телгә дә алырга ярамаган заманда исемен кайтаруны үтенеп партия Үзәк Комитетына хат юлларга көч салган вакыйга буларак искә алына: «1937 елның җәендә Кырымда ике ай чамасы дустым Хәбибрахман карамагында яшәдем. Хәвефле вакыт, җан тыныч түгел, кая барырга, нишләргә белмичә аптыраган чагым... Китәр вакыт жит-

кәч кенә Хәбибрахман мине кыстый-кыстый Ялтага, Галимҗан ага Ибраһимов янына алып барды. Сүз дә юк, авыру әдип белән бу очрашуның миңа тәэсире бик зур булды. Әгәр мин 1955 елны партия Үзәк Комитетына Галимҗан Ибраһимовның эшен яңадан карауны үтенеп хат язганмын икән, әнә шул 1937 елда әдипне үз күзем белән күрү миңа ул хатны тәвәккәлләп язарга, һичшиксез, ярдәм иткәндер дип уйлыйм» [2: 205].

Г. Ибраһимовның исемен кайтару өчен көрәшеп, архивының бер өлеше юкка чыгуы турында Ә. Еники «Санаулы көннәр» исемле язмасында аеруча әрнеп яза: «1987 елны Галимҗан Ибраһимовның 100 еллыгын бәйрәм иткәндә, без, Казан язучылары, Солтанморатка килеп, әдипнең күптән түгел ачылган музеенда булып киткән идек инде. Ләкин ак бүрәнәдән салынган җыйнак йорт кайсыдыр елны янып юкка чыккан. Йорт кызганыч, йорттан да бигрәк, эчендәге берәмләп җыелган нәрсәләре аеруча кызганыч. Репрессия корбаннарының әйберләрен табу гаять читен. Аларның бик күбесе органнар тарафыннан юк ителгән яки югалып беткән. Галимҗанның да Кырымнан кайткан архивы шундый язмышка дучар булды. Инде менә янган йорттан бераз читтәрәк, музей өчен кызыл кирпечтән яңача стильдә бик матур бина салып куйганнар. Без менә шул чибәр бинаның шактый иркен эчен, андагы экспонатларны ашыкмыйча гына карап, танышып чыктык. Музейны караучы ханымның тырышлыгы нәтиҗәсендә күп нәрсә җыелган, ләкин бушлык нык сизелә иде әле. Мәсәлән, мин үзем Г. Ибраһимовның шушы музей өчен җибәргән «Нәхү» исемле китабын һәм әдипнең Газим Касимовка үз кулы белән язган хатын монда күрмәдем. Ахрысы, аларны миннән алып киткән Уфа галиме тапшырырга өлгермәгәндер...» [1: 177].

Ә. Еники мөгаллим Г. Ибраһимовның даны еракларга танылуы хакында да билгеләп үтә: «Петербургтан алып Кырымга чаклы барлык зур вокзаллардагы рестораннарны тотучы Казандагы Максудовлар... гимназист улларын һәм кызларын татарча да укытыр өчен, әдип Галимҗан Ибраһимовны 1912 елны Киевка махсус чакыртып алалар», – дип яза ул «Касыймга сәяхәт» исемле мәкаләсендә [2: 610].

Г. Ибраһимовның исемен, шәхесен кайтаруга бәйле рухи батырлыгына бәйле чордашларының сүзләрен Әмирхан Еники шулай ук язмаларында теркәп калдыра. Түгәрәк юбилеен котлап, Х. Туфан әдипкә соклануын шигъри юллар белән җиткерә:

«Кадерлебез Әмирхан!
Тик без генә түгел, энем,
Безнең белән бергә бүген
Котлый сине, Әмирхан:
– Ялалардан коткарылган
Һәм халыкка кайтарылган

Ибраһимов Галимҗан
Котлый сине, Әмирхан!
Сәлам белән: Х. Туфан. 16.03.1979» [2: 165].

Ә. Еники Г. Тукай һәм Г. Ибраһимов шәхесләрен бер дәрәҗәдә күреп бәяли, публицистик хезмәтләрендә милләт хадимнәренә соклану аша XX йөз яңа милли мәдәниятнең туу шартлары, гасыр дәвамында үсеш-үзгәреше, саклану мөмкинлеге турында кабатлап сөйли.

ӘДӘБИЯТ


1. Еники Ә.Н. Әсәрләр. Биш томда. V т. Публицистик язмалар, мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 479 б.
2. Еники Ә.Н. Сайланма әсәрләр. 3 томда. III т. –Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – 839 б.
3. Галимджан Ибрагимов: «Я жизнь искал, смысла в жизни искал». – Казань: ИЯЛИ, 2017. – 336 с.



УДК 82.091


# ГАЛИМДЖАН ИБРАГИМОВ: ЛИЧНОСТЬ, ПИСАТЕЛЬ И ТВОРЧЕСКИЙ МЕТОД


***Ф.Г. Галимуллин***
*Казанский (Приволжский) федеральный университет (Казань)*



В статье рассматриваются творческие особенности классика татарской литературы Галимджана Ибрагимова, у которого наблюдается большой и разнообразный арсенал стилей и приемов художественного изображения. Все это наблюдается на фоне творчеств видных представителей татарской литературы в первой четверти XX века.


**Ключевые слова:** Галимджан Ибрагимов, стиль, приемы, способ изображения, индивидуальность творчества, методы.



The article deals with the creative features of the classic of Tatar literature Galimzhan Ibragimov, who has a large and varied arsenal of styles and techniques of artistic depiction. All this is observed against the background of the works of prominent representatives of Tatar literature in the first quarter of the twentieth century.


**Key words:** Galimzhan Ibragimov, style, techniques, way of depiction, individuality of creativity, methods.


# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ: ШӘХЕС, ӘДИП ҺӘМ ИҖАТ ЫСУЛЫ


***Ф.Г. Галимуллин***
*Казан (Идел буе) федераль университеты (Казан)*


Әдәби иҗат бик катлаулы күренеш. Аерым каләм әһеленең язу ысулын, бигрәк тә чын сүз рәссамы булган әдипләрнекен, нинди

дә булса кысалар белән чикләп карау мөмкин дә булмый. Сүз дә юк, бу каләм остасы иҗат иткән чорның үзенчәлекләренә, авторның чынбарлыкны күрү һәм бәяләү аерымлыкларына, әдәбиятның гомуми традицияләренә дә бәйле була. Г. Ибраһимов, татар һәм шәрык матур әдәбиятларын тирән белүче, гареб әдәбиятыннан да яхшы хәбәрдар шәхес буларак, иҗат ысуллары мәсьәләсендә дә мәгълүматлы әдип. Әйтергә кирәк, иҗатының буеннан-буена ул әдәбиятның нәзари мәсьәләләренә дә игътибарын киметмәде, бу өлкәдә дә даими язып, хезмәтләрен тәкъдим итә килде. М. Хәсәнов әдипнең сайланма әсәрләренең бишенче томында урнаштырган мәкаләсен «Г. Ибраһимов – тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме» дип атавы нигезле иде. Анда олуг әдибебезнең мондый хезмәтләренә этрафлы гомумиләштерү ясалган.

Бу очракта Г. Ибраһимовның, язучы буларак, үзенең иҗат ысулы мәсьәләләренә игътибар юнәлтәсе килә. Әлбәттә, бу үзе генә дә зур мәсьәлә, мәкаләнең тар мәйданында аны өлешчә генә иңләүне максат итәргә мөмкин.

Сүзне шуннан башлыйсы килә: егерменче-утызынчы еллардагы иҗат методлары турында сүз барганда да иң әүвәл идеология максаты күздә тотылганлыгын искәртергә кирәк. Совет әдәбиятында романтизмны үз итәргәме-юкмы дигән мәсьәләнең үзәккә куелуы да шуннан килә иде. Шунысын да әйтергәк кирәк, романтизмны реализмнан түбәнрәк баскычта торучы иҗат ысулы дип карауга өстенлек бирелде, аларны бәяләүдә вульгар социологизм таләпләрен нигез итеп алу күзәтелде. Әлеге иҗат ысулларын бер-берсенә каршы куйганда, романтизмга карата тискәре караш урнаштыру таләбе куелды. Бу шартларда Г. Ибраһимов иҗатының каршылык уятуына гаҗәпләнергә кирәкме икән? Аның иҗат ысулы хәрәкәтен билгеләгәндә «романтизмнан – реализмга» дигән нәтиҗә ясап, бу күренешне тагын да турырак юл белән аңлатулар да булды. Болай иткәндә, иҗатның үзендә андыйлар күрергә теләгән эзлеклелекнең сакланмавы шәйләнә. Әгәр дә Г. Ибраһимов каләменең 1922 елда «Адәмнәр» әсәрендә яңадан тәнкыйть юнәлешенә әйләнеп кайтканлыгын искә алганда, бу бигрәк тә шулай.

Әдибебезнең иҗат ысулы турында бәхәсләр булгалап торды. Моңа аның әсәрләренең рухы, аларда алынган хәл-әхвәлләрнең үзенчәлеге, кеше күңелен сурәтләү алымнарының төрлелеге азык булып торды. Язучыларның күбесе, иҗат иткәндә мин нинди дә булса нәзари кысалар белән исәпләшмим, күңелем теләгәнчә язам, дип, үзләрен ысул мәсьәләсендә ирекле итеп хис итәргә телиләр. Г. Ибраһимов исә, бер үк вакытта үзе дә әдәбият нәзариясе мәсьәләләре буенча тирән фикер йөртүче буларак, бу юнәлештә максатчан эш иткән, үз каләм көченең үзенчәлегенә сизгер булган. Моның үз табигате белән шартлануын яхшы аңлаган. «Мин –

реалист мөхәррир. Беренче әсәремнән хәзергәчә шул мәсләктә барам. Арада кайбер әсәрләремдә романтизм элементларының бераз куера төшкән урыннары булгалады (реакция чорында), ләкин боларда да төп мөндәриҗә-нигез реализм иде» [1].

Әдип бу сүзләрне 1927 елда Г. Толымбайга язган хатында әйтә. Күрәбез, әле бу вакытта реализмны «тәнкыйди» яки «социалистик» кебек төрләргә аерып карау юк. Реализм белән романтизм, Г. Ибраһимов карашынча, үз эчләрендә тагын да бүлгәләп каралмыйлар. Дөрес, ул үз иҗатында романтизм буяулары куеруын реакция чоры белән аңлатырга омтыла. Ләкин бу әлеге буталыш елларындагы җәмгыятьнең үз асылына ишарә буларак кабул ителә, ягъни андый шартларда сүз сәнгатенең дә чынбарлыкны контраст буяулар белән тасвирлавының шуннан килүен аңлатырга тели. Моннан шул сизелеп кала: Г. Ибраһимов хәтта, үзенең романтизм ысулы белән язуыннан уңайсызланып, акланырга тырыша кебек.

Бу сәнгатьчә сурәтләү өлкәсенә сәяси күзлектән карый башлау нәтиҗәсе дә иде. Шуңа күрә мондый караш Г. Ибраһимовның үз иҗади гамәле белән үк күпмедер каршылыкка керде дияргә урын бар. Дөресендә, романтизм әдәбиятның үсмерлек чагы булмаган кебек, реализм да аның өлгергәнлек чоры түгел. Киресенчә, алар бер-берсенә торышырдай ысуллар, икесе бергә килеп, үрелеп гәүдәләнгәндә җимешләрен мулрак бирүче иҗат юнәлешләре. Сурәтләнергә алынган хәл-әхвәлләрнең, кеше образларының нindiлекләренә карап, романтизм яки реализмның өстенлек алуы мөмкин. Икесе бер чама булу да еш очрый. Мәсьәләгә кирәклек, зарурилык, сәнгатьчә акланганлык таләпләреннән чыгып карарга гына кирәк.

Г. Ибраһимов иҗатындагы ысул һәм өслүб мәсьәләләре хакында сүз алып барганда, Г. Халит тә шуңа якынрак фикерли. «Язучы үзенең иҗаты белән дә реализмга якыная барды. Ләкин бу якынаюны роматизм традицияләреннән баш тарту дип түгел, ә романтизм белән реализм эстетикасының нык керешүе, синтезлаша баруы дип аңлатты. Бу юнәлешне без татар әдәбиятында романтик реализмның барлыкка килүе дип билгеләгән идек» [2]. Димәк, Г. Халит карашынча, бездә романтик реализм XX гасырның унынчы елларында барлыкка килгән. Хәер, алай гынамы икән? Урта гасырлар әсәрләренең кайберләрен дә, XIX йөздәге аерым роман-повестьларны да әнә шулай романтик реализм ачкычы белән аңлау, кабул итү һәм бәяләү дә күпкә отышлырак.

Биредә тагын бер нәрсә игътибарны җәлеп итә: романтизм белән реализмны жанр хасиятләренә туры килү-килмәү ягыннан да караулар да булды. Әйтик, шигъри әсәрләргә – романтизм, прозага исә реализм ысулы кулайрак дип уйлау да бар. И. Нуруллин, мәсәлән, шундыйрак карашны бүлешә. Ул «реализм әдәби

юнәлеш буларак мәйданга килгән дәверләрдә эпик жанрлар алга чыкты», – дип язды [3]. Болай диюдә күпмедер хаклык та бар. Ләкин аны тулаем дөрес дип булмый. Чөнки шигъриятнең чын реалистик (М. Гафуриның «Эшче», Ф. Кәримнең «Җиденче мич» поэмалары), чәчмә әсәрләрнең романтик (Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр», «Табигать балалары») булган мисалларын да китерү мөмкинлеге бар. Әлбәттә, аларны да бусы – саф романтизм, тегеләре – саф реализм ысулы белән иҗат ителгән дип кистереп әйтмибез. Аларда да бу ике ысулның нык керешүе күзәтелә. Сүз бары тик теге яки бу әсәрдә кайсысының өстенлек алуы турында гына бара. Г. Халит тә, Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр», «Яңа кешеләр», «Кызыл чәчәкләр» әсәрләрен реализм үрнәкләре итеп караса да, алардагы романтизм нигезен дә күрми кала алмый, ягъни аларның икесе бергә үрелүен таный. Бу үрелештә галим романтик реализмны күрә. Бу аның менә бу фикерендә раслана: «романтик реализмны иң алдынгы әдәби агымнарның берсе дип, аны критик реализм һәм прогрессив романтизм синтезеның бер формасы итеп санаганда, аның каләме дә, эчтәлеге дә байтак конкретланыр» [4]. Димәк, Г. Халитчә, романтик реализм теләсә кайсы реализмнан түгел, бәлки тәнкыйди реализмнан, теләсә кайсы романтизмнан түгел, ә прогрессив романтизм белән кушылып берлек тәшкил итә икән. Без исә мондый бүленеш тарафдары булудан ерак торабыз. Ник дигәндә, иҗат каләме камилләшкән саен, язучы романтизм белән реализм кушылмасына якынрак килә. Монда прогрессив яки реакцион романтизм белән шартлану мөһим түгел. Без моны җитмешенче-сиксәненче еллар язучыларыбыз Г. Ахунов, Ә. Баянов, Н. Фәттах, М. Мәһдиев, Х. Сарьян һәм башкалар иҗатында да күреп килдек.

Романтик реализмның бик әһәмиятле өстенлеге шунда булырга мөмкин: ул нинди дә булса сәяси нигезгә хезмәт итүне бик үк үз итми, бәлки сәнгатьнең эчке кануннарына таянырга омтыла. Аңлашылганча, мондый ирекле ысул бары тик демократиягә, фикер хөрлегенә нигезләнүче җәмгыятьтә генә үзенең кирәклеген раслый һәм үстерүгә ирешә ала иде. Яки авторның аңлы рәвештә өстенлек итүче идеологияне кире кагуы, яки аңа битарафлыгы кирәк булды.

Социалистик реализм методы басымы астында совет хакимияте чорында язучыны зурлау өчен кулланылган иң көчле эпитетларның берсе – «реалист» сүзе иде. Реалист икән, ул әйбәт язучы дигән караш ныгып урнашты. Чынлыкта социализм идеалларына тугрылыклы язучыны – реалист, ә демократия тарафдарын романтик дип атауларны гамәл расламады. Большевиклар идеологиясенә бөтен барлыгы белән хезмәт иткән, шуның бәрабәренә элек язылган әсәрләрен дә үзгәртеп, тиешле идеология таләпләренә

буйсындырып эшләп чыккан Г. Ибраһимов үзе дә иҗатында романтик ысулны үз итүдән бөтеләй үк читләшә алмады.

Реализм турында сүз барганда, аның бер табигый тармагы сыйфатында натурализм ысулы яшәвен дә онытмаска кирәк. Әгәр реализмны язучының әсәрне гомумиләштерү юлы белән тудыруы дип аңласак, натурализм исә теге яки бу хәлләрне тормышның үзендәгегә якын итеп тасвирлауга кайтып кала. Ләкин болай дигәндә, без шуны да онытмаска тиешбез: тормыш күренешләре үзләре дә (аларны аерым алганда да) нык гомумиләштерү хасиятенә ия булырга мөмкиннәр. Безнең карашка, Г. Ибраһимов бу мәсьәләдә кискен фикер белән чыга. «Мин натурализмга каршы, – ди ул. – Тормыш кисәкләрен шул көенчә, фотографияләп дөньяга ташлау юлы белән төзелгән әсәрләрнең кыйммәте юк» [5]. Бу очракта аны да дөрес аңларга кирәк. Ул гомумиләштерү хасияте булган сәнгатьчә әсәрләр хакында сүз алып бара.

Реальлек белән натуральлек, аларның нисбәте турында сүз алып барганда, аерым авторлар үзләре уйлап чыгарган шактый бәхәсле нәрсәләргә дә таянып эш итү омтылышы да ясап карадылар. Утызынчы еллар башында, реальлек дәрәҗәсен билгеләгәндә, мәсәлән, «чынлык эквиваленты» дигән үлчәү куллануга чакыру булды [6]. Янәсе, «образ уйлап чыгарылган, аңар чынлыкта эквивалент юк һәм була да алмый икән, ул чакта ул реаль түгел, шуның белән логикалы да түгел». Болай фикерләгәндә, Ш. Усмановның «Легион юлы» – реаль, Г. Ибраһимовның «Адәмнәр»е реаль түгел булып чыга. Бу юл белән караганда, беренчесенең «чынлыкка эквиваленты» бар дип исәпләнелә, ә икенчесе, гомумиләштерелеп сурәтләнү сәбәпле, андый күрсәткечтән мәхрүм калган. Аңа карап Г. Ибраһимов әсәрендә натурализм юк дип әйтеп буламы? Һичшиксез, бар, ул бигрәк тә сурәтләү ысулында күренә, шул ук вакытта әсәр чын мәгънәсендә реаль дә, хәтта, әйтергә кирәк, романик та. Әсәрнең язылу ысулына Х. Госман да игътибар иткән иде. Бу җәһәттән Г. Ибраһимовның «Адәмнәр», М. Гафуриның «Ачлык тырнагында» әсәрләре хакында уйланганда, ул болай диде: «Бу әсәрләрдә фаҗига күбрәк натурлистик яктан күрсәтелде» [7]. Моның сәбәбе итеп ул «дөнья империализмы гаепле булу, аның җинаятьләре ачылып җитмәвен» әйтә. Бу сүзләрдә әдипнең шәхес һәм сүз рәссамы буларак үзенчәлеге бөтенләй чагылмый, аның каравы, дөресме-түгелме, сәяси як өскә чыга.

Г. Ибраһимовның исә ачлык фаҗигасенә һәм аны бәяләүгә булган карашы шактый үзенчәлекле. Ул, әдип буларак, бу ачлыкның килеп чыгу сәбәпләренә артык керешмичә, аның кешеләргә алып килгән коточкыч нәтиҗәләрен күрсәтә, моны һич тә бизәмичә, шомартмыйча, булганынча эшли. Ә менә шушы ачлыктан интегүчеләргә азмы-күпме файдасы булмасмы дигән максат белән мәҗ-

муга чыгаруны оештыру гамәле вакытында, күрәсең, башкачарак та уйлаган. Ул Ф. Әмирханга шушы мәҗмуга өчен мәкалә язуын үтенеп мөрәҗәгать итә. Әлеге мәкаләнең нинди рухтарак булырга тиешлеген, монда совет хакимиятенең гаепле булмавын, моның «самодержавиедән калган мирас» булу фикерен уздырырга кирәклеген әйткән. Ф. Әмирхан бу мәкаләне язмый. Аның каравы ул бу турыда көндәлегенә менә болай дип теркәп куйган: «Мин ачлык турысында Г. Ибраһимов теләгән рәвештә мәкалә бирә алмыйм» [8]. Чөнки ул бу фаҗигадә большевиклар фиркасенең катнашы барлыгын күреп тора. Әмма Г. Ибраһимов та дөреслекне яшереп калдырмады. Әдип буларак, шушы хыянәтчел сәясәтнең халыкка китергән һәлакәтле нәтиҗәләрен күрсәтеп, повесть иҗат итте. Ул сурәтләгәннәр тирән гомумиләштерү көченә дә ия. Димәк, аны бу очракта, Г. Нигъмәти, Ш. Госмановлар күрергә теләгән шәрәләндерелгән натурализмга бирелгән дип әйтеп булмый. Әгәр дә әлеге тәнкыйть карашларын белдергән замандашлары таләп иткәнчә, әсәрдә ачлыкның килеп чыгу сәбәпләре гадел күрсәтелсә, бу бер дә совет хакимияте файдасына булмас иде. Г. Ибраһимов боларны, Ф. Әмирхан кебек үк, яхшы аңлаган. Ихлас борчылган кеше буларак, бу фаҗига турында язмый кала алмаган. Ләкин моны сәясәткә артык кермичә эшләргә тырышкан. Большевик тәнкыйтьчеләр әлеге әсәрнең язылу ысулын натурализм белән тиңләштергәннәр икән, монда натурализмны эстетик яктан түгел, бәлки идеологик нисбәттән бәяләү өстенлек итүе күренә. Ул елларда эстетикада марксизм тәгълиматына таянучылар халыкчанлыкта, миллилектә натурализм күрделәр. Шулай итеп, әдәбият-сәнгатьне милли нигезләрдән арындыруда бу термин үзенә күрә корал итеп файдаланылды.

Иҗат кешесе бербөтен. Аны икегә бүлеп карап булмый. Ләкин шулай да әдәби, гыйльми эшкә юнәлеш бирүче, аны оештурычы сыйфатындагы Г. Ибраһимовка караганда, язучы Г. Ибраһимовка күбрәк ышанасы килә. Ул 1924 елда каләмдәшләренә киңәш рәвешендә болай дигән иде: «Сүз белән вәгазьләмә, фәлсәфә сатма, бәлки тасвир кыйлган күренешләрең, иҗат кылган типларың, ясаган тулы канлы, җанлы сурәтләрең аркылы үзеңнең төп фикереңне гәүдәләндер» [8]. Әйе, язучының төп фикере аның әсәрләренә сеңә. Димәк, үзеңнән гайре каләм әһелләре иҗатын бәяләгәндә дә шушы төп фикернең сәнгатьчә гәүдәләнешенә игътибар итү, шуннан чыгып хөкем чыгару – иң дөрес юл. Иҗат ысулы ул каләм әһеленең чынбарлыкка мөнәсәбәттә эчке инануын, кыйбласын, әсәрен иҗат иткәндәге төп бурычыннан килеп чыга торган нәтиҗә. Моны Г. Ибраһимов тирән аңлап эш иткән. «Мөхәррир я матур вә мәгънәле язсын, яки үзенең тугры тасвиры белән тормышның авыр җәрәхәтләреннән берсен укучы күз алдына ачып салып, шул хакта уйларга, авыр язмышын җиңеләйтү турында

чаралар күрә башларга – һич тә булмаса, шуны бер мәсьәлә итеп мәйданга алырга мәҗбүр итсен» [9]. Олуг әдибебез хаклы. Менә шундый киң карашлы, масштаблы сүз осталары гына үзләренең шәхесләренә бәрабәр иҗат ысулы булдыра һәм дәвамлы вакытлар өчен халык күңеленә аваздаш әсәрләр тудыра алалар. Г. Ибраһимовның әдәбиятыбыздагы урыны барыннан элек шуның белән билгеләнә дә.


ӘДӘБИЯТ

1. Кызыл Татарстан. – 1927. – 4 декабрь.
2. Халит Г. Чынлык һәм гүзәллек гармониясе // Казан утлары. – 1977. – № 3. – Б. 127.
3. Фәйзуллин Р., Нуруллин И. «Аңлаешлы» һәм «аңлаешсыз» шигырьләр яки поэзиянең гражданлык йөзе // Казан утлары. – 1978. – № 3. – Б. 154.
4. Халит Г. Тизләтелгән әдәби үсеш һәм иҗат методлары // Казан утлары. – 1971. – № 9. – Б. 150.
5. Ибраһимов Г. Әсәрләр. 1976. – Т. 5. – Б. 520.
6. Яңалиф. – 1931. – № 7. – Б. 54.
7. Госман Х. Олы юлга чыкканда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – Б. 25.
8. Ибраһимов Г. Әсәрләр. – 1978. – Т. 5. – Б. 453.
9. Әхмәдуллин А. Галимҗан Ибраһимов һәм татар драматургиясе // Казан утлары. – 1977. – № 3. – Б. 143.



УДК 821.512.145


## РОМАН Г. ИБРАГИМОВА «НАШИ ДНИ» В КОНТЕКСТЕ ОБЩЕСТВЕННОЙ И ЛИТЕРАТУРНО-ЭСТЕТИЧЕСКОЙ МЫСЛИ НАЧАЛА XX ВЕКА


***Т.Ш. Гилазов***

*Казанский (Приволжский) федеральный университет (Казань)*



Статья посвящена анализу проблематики романа Г. Ибрагимова «Наши дни» в контексте литературно-эстетической и общественной мысли начала XX века. Опубликованный в 1920 году роман «Наши дни» занимает особое место в духовном наследии писателя. В этом произведении Г. Ибрагимову удалось отобразить многие аспекты татарского общества в годы первой русской революции. Этот роман является самым ярким произведением в плане постановки актуальных социальных, национальных и просветительских проблем в дооктябрьском периоде его творчества. Г. Ибрагимов обрисовал целую галерею типов татарской интеллигенции различных социальных прослоек, представители которых ищут пути перестройки национальной жизни.



**Ключевые слова:** Галимджан Ибрагимов, роман, общественная мысль, татарская литература, реформирование татарского общества, взаимосвязь.



The article is devoted to the analysis of the problems of G. Ibragimvoa’s novel «Our Days» in the context of literary, aesthetic and social thought of

the early twentieth century. The novel Our Days, published in 1920, occupies a special place in the spiritual heritage of the writer. In this work, G. Ibragimov managed to display many aspects of the Tatar society during the years of the first Russian revolution. This novel is the most striking work in terms of posing topical social, national and educational problems in the pre-October period of his work. G. Ibragimov outlined a whole gallery of types of the Tatar intelligentsia of various social strata, whose representatives are looking for ways to restructure national life.
**Key words:** Galimdzhan Ibragimov, novel, social thought, Tatar literature, reforming the Tatar society, relationship.

## XX ЙӨЗ БАШЫ ӘДӘБИ-ЭСТЕТИК ФИКЕРЕ КОНТЕКСТЫНДА Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «БЕЗНЕҢ КӨННӘР» РОМАНЫ

***Т.Ш. Гыйлаҗев***
*Казан (Идел буе) федераль университеты (Казан)*

Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романы – сәнгати һәм тарихи көчне күрсәтә торган киң колачлы әсәрләрнең берсе. Шунысы куанычлы: Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре Г. Ибраһимов әсәрләренең академик басмасын әзерләп бастырып чыгарды. Моңа кадәр татар укучылары романның совет идеологиясе йогынтысында үзгәртеп эшләгән икенче вариантын өйрәнделәр. 15 томлыкның 4 томына Г. Ибраһимовның 1920 елда «Сабах» нәшриятының «Өмид» типографиясендә басылган романы урнаштырылган, ягъни әдәбият сөючеләр язучы әсәренең үзгәртелмәгән, оригинал варианты белән танышу бәхетенә иреште. Бу фикер язучы иҗаты яңа иҗтимагый һәм мәдәни шартларда өйрәнелгән хезмәтләрдә дә әйтелә [4: 216]. Вакыйгаларның шактый киңлеге, хәрәкәтнең куелыгы, дулкынлы көрәшнең куәтле булуы, геройларның катлаулы язмышлары аша бу роман XX гасыр башы татар милли иҗтимагый хәятын объектив рәвештә күз алдына китереп бастыра.

Мәкалә Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» әсәренә тулы бәя бирүне максат итми, романда күтәрелгән бер шәлкем проблемаларга XX гасыр башы иҗтимагый һәм әдәби-эстетик фикере контекстында бәя бирү омтылышы ясала. Тарихи роман жанрындагы бу әсәрнең идея эчтәлеге, бер яктан, XX гасыр башындагы иҗтимагый фикер, икенче яктан шул чорның әдәби хәрәкәте белән тыгыз бәйләнгән. Роман үз чоры милли чынбарлыгының актуаль проблемаларын күтәрә, аерым бүлекләрендә татар тормышын яңарту, мәдәниләштерүнең юллары тәкъдим ителә. Әсәрдә гәүдәләнеш тапкан мөһим проблемалар бу чорның күренекле галимнәре, тәнкыйтьчеләре Җ. Вәлиди, Ф. Кәрими. И. Гаспралы, Н. Гасрый һ.б.ларның фикерләре, икенче яктан, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан,

Г. Тукай, хәтта язучының үз әдәби әсәрләрендәге бәя-хөкемнәр белән аваздаш.

Романда төрле сәяси партияләр, аеруча татар эсерлары һәм социал-демократлары монархиягә, буржуазиягә каршы бердәм көрәш алып бара. Г. Ибраһимов иске татар тормышын үзгәртеп коруга нисбәтле, зыялы яшьләр арасындагы идеологик бәхәс, сәясәткә киң урын бирсә дә, инкыйлаб елларында уртак идеал хакына барлык сәяси агым вәкилләренең берләшеп, кулга-кул тотынышып хәрәкәт итүләренә басым ясый [8: 47]. Хәрәкәт бердәмлегенә төрле партия һәм партиясезләрне бергә җыйган «Мәдрәсәи Исламия»-нең шәкерт җыелышларыннан берсендә сөйләгән Җиһангир нотыгында басым ясала: «...Бездә җан булса, бездә аң булса, татар милләтенең караңгы киләчәген яктыртырга хезмәт кылу дәрте булса, бездә үземезне адәм дип белерлек, үземезне издермәслек <...> мыскыл иттермәслек намус вә куәт булса, без иптәшләр, берләшергә, бер-беребезгә кул бирешергә тиешле. Менә бу җәмгыять шул турыда булачак. ... Мәсьәлә мөһим, иптәшләр, берләшик, көрәшик, көрәшүдә табарсың син үз хакыңны» [10: 84 ]. Төрле идея юнәлешендә торган катламнарны берләштерерлек көчләр дә табыла. «Демократлар эчендә Булат, революционерлар эчендә Урманов кебек ике яктан бертигез диярлек мәхәббәт казанган иптәшләр булуы да бу ике партия кешеләренең береннән гамәлдә күп ераклашмавына сәбәп була иде», – дип яза Г. Ибраһимов [10: 250]. Татар буржуазиясе хәрәкәте белән пролетариат хәрәкәте арасында ислахчылар-шәкертләр зур роль уйный. Әдәби әсәрдә «Мәдрәсәи Исламия» шәкертләре хәрәкәтен сурәтләүгә зур урын бирелә, ул әсәрнең өчтән бер өлешен алып тора. Шәһәрне иңләп алган шәкертләр кузгалышының сәбәпләре мәрәсәләргә ислах, уку-укыту программаларын, ысулларын яңарту белән генә чикләнмичә, иҗтимагый һәм милли проблемалар белән дә тыгыз бәйләнгән.

«Безнең көннәр» романында XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы әдәби һәм иҗтимагый фикере белән бәйләнеш шәкертләр, мөселманнарның шәһәр җыелышларында төрле социаль катлам вәкилләре, инкыйлабчылар чыгышларында ачык чагыла. Шундый җыелышларның берсе шәһәрнең зур җәдиди мәрәсәсе – «Мәдрәсәи Исламия»дә була. Г. Ибраһимов аны аерым чигенешләр белән бик җентекләп сурәтли. Ул әдәби әсәрнең 26 бүлеген тәшкил итә. Җыелыш мәдрәсәнең өченче катындагы зур залда бара. Төнге өчкә кадәр сузылган мәҗлестә татар тормышын яңарту, мәдәниләштерү, татар милләтен үстерү мәсьәләсе төп көн тәртибе булып тора. Төрле сәяси фирка вәкилләре, шәкертләр, руханилар бу хакта үз карашлары һәм уйланулары белән уртаклаша. Нотыкчыларның күбесе, аеруча шәкертләр үз чыгышларын та-

тар мәдрәсәләренең артталыгына, схоластик фәннәр укытылуга, идарәнең начар мөгаләмәсенә, яшәү шартларының начарлыгына тискәре мөнәсәбәт белдерүдән башлый.

Татар милләтен үстереп, бөеклеккә, муллыкка, бәхеткә ирештерүнең төрле юллары тәкъдим ителә. Беренче рус инкыйлабы еллары шигъриятендә Г. Тукайның «Иттифак хакында» (1905), М. Гафуриның «Инсаф вә иттифак» (1905), Н. Думавиның «Берлек-иттифак» (1906), «Рак, аккош, балык» (1906), «Умарта корты» (1906) шигырьләрендә һәм мәсәлләрендә гәүдәләнгән бердәмлек, берләшү, бер сүздә булу идеясе татар милләте үсешенең, муллыкка ирешүенең төп шартларыннан беренчесе төсендә тәкъдим ителә: «Иттифак... Иттихад... Иттифак... Иттихад... Әфәнделәр һәр милләт болар аркасында тәрәккый вә тәгали итеп, әүеҗ сәгадәткә (бәхетнең иң югары ноктасына) ирешә» [10: 155]. Нотыкчы Х. Кадыйри, башка милләтләр тарихыннан мисаллар китереп, үз фикерен дәлилли.

Татар матбугатын һәм тормыш-чынбарлык вакыйгаларын сурәтләп, укучының дөньяга күзен ачкан матур әдәбиятны үстерү, рус телен өйрәнү, рус һөнәри мәктәпләрендә, реаль училищеларында белем алу татар милләтенең алгарышына, мәдәниләшүенә хезмәт итә дигән фикер әйтелә.

Татар җәмгыятендә хатын-кызларга мөнәсәбәтне уңай якка үзгәртү, аларга белем ирек һәм азатлык бирү татар милләте алгарышының бер юлы төсендә тәкъдим ителә: «...һәр милләтнең мәртәбә галиясе (югары дәрәҗәсе) хатыннарының тәрбиясе вә тәрәккыйләре мәртәбәсенә мөсави (тигез) була. Хатыннар – милләт аналары. Ана ничек кылса, бала шулай була. Безнең милләтнең артта калуы фәкать, фәкать хатыннарымызны дүрт стена эченә ябып, хиҗаб астында черетүемездәндер. Безне хиҗаб, безне шул артта калдырды. Һәр милләтнең тәрәккый итүе хатыннары аркасындадыр» [10: 155]. Бу фикер икенче нотыкчы тарафыннан үстерелеп бала тәрбиясенә, аңа дөрес тәрбия бирү һәм шул юл аша юлбашчылар, милли лидерлар җитештерү проблемасына бәйләп куела: «... һәр милләтнең тәрәккый вә тәгали итмәге – балаларның гүзәл тәрбия кылынуына баглыдыр. Бүгенге балалар киләчәк көндә милләтнең аталары, юлбашчылары, көтүчеләре булачак. Көтүче кая кауласа, көтү шунда барачагы мәгълүм» [10: 155–156]. Менә хөкемнәр Г. Исхакый, Ф. Әмирхан. Г. Тукай, С. Рәмиев карашлары, әдәби әсәрләрендә тәкрарланган идеяләр белән бик тә аваздаш. Мәсәлән Г. Исхакыйга мөрәҗәгать итик. Ул үзенең программ әсәре «Ике йөздән соң инкыйраз» (1902–1904) хыялыйпублицистик повестенда болай дип яза: «Һәр милләтнең яртысы хатыннар, һәр милләтнең рухын саклаучылар – хатыннар, һәр милләтнең теленең хосусый тәләффызларын (әйтелешләрен) шәвәсен

саклаучылар – хатыннар. Киләчәктәге ата булачак ирләрне, ана булачак кызларны тәрбия кылучылар – хатыннар идеке һәркемгә мәгълүм бер мәсьәлә булгач, минемчә, аларны тәрбия кылыргa кирәкме йә юкмы? Мәсьәләсе һәркемгә җавап бирерлек бер нәрсәдер» [11: 180].

Шәкертләр чыгышларында XX гасыр башы татар прозасында аеруча, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан әсәрләрендә, драма әсәрләрендә кызыл җеп булып сузылган иске карашлы, надан, әхлаксыз, милләткә хезмәткә аркасы белән торган руханиларга, ишаннарга каршы көрәш мәдрәсәләрне ислах итүнең төп шартларыннан берсе төсендә әйтелә. «Тарихи, иҗтимагый дәлилләр белән исбат кылган соң, кызу нотыклар белән танылган Сөләйман Сәйфуллин кискен карашлары турыдан-туры Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәренең кереш өлешендә күрсәтелгән татар милләтен инкыйразга сәбәпләргә барып тоташа: «Безне кем бетерде дисез? Безне муллалар бетерде... Бездә муллалар наданнар, җаһилләр, гыйлемсез вә фикерсезләр... Болар – милләт микроблары... Болар – безне гасырлар буенча ашап, әүвәлге шәүкәтемезне бетергән, безне аяктан еккан зарарлы кортлардыр. Без милләт өчен тырышсак, без милләтемез тәрәккый итсен дисәк, тәрәккый вә мәдәният юлына аркылы кискә булып яткан ишаннар вә мөтәгассыйб муллалар белән көрәш башларга, аларны бара торган юлымыздан читкә алып ташларга тиешлемез» [10: 157].

Романда шактый зур идея-эстетик вазифа йөкләнгән Нигъмәт казый һәм җентекләп сурәтләнгән Давыт Урманов чыгышында Ислам дине һәм мәдәният, дин һәм милләт, дин һәм заман мөнәсәбәтләре проблемаларына зур урын бирелгән. Бу фикерләр, бер яктан, Г. Ибраһимовның үз әдәби әсәрләренә, мәкаләләренә һәм икенче яктан, Ф. Әмирхан [1], Н. Гасрый [5], Г. Исхакый публицистик язмаларына, өченчедән, Җ. Вәлидинең фәнни хезмәтләлернә барып тоташа. Аларда хосусый карашлар булу белән бергә, уртак карашлар да урын ала. Мөселманнар Ислам рухын аңлап, шуның белән эш иткән чорда мәдәният һәм хакимият баскычының иң югары баскычына менүләре раслана.

Җ. Вәлиди бу мәсьәләгә үзенең татар әдәбиятын өйрәнүнең методологик проблемаларына багышланган хезмәтләрендә зур урын бирә. Әдәбият галиме һәм профессиональ тәнкыйтьче башта милләтнең дине белән гыйлеме һәм мәдәнияте бер мәгънәдә йөрүен әйтә [6]. Җ. Вәлиди динне «мәдәнияткә бер әсас», «мәдәнияткә менү өчен өчен бер баскыч» дип карый: «Ислам галәмендә мәдәниятне кабул итәрлек вә үзеннән-үзе мәдәни булып үсәрлек истигъдад (сәләтлелек), көч бар иде. Бу истигъдад дин, дин куәткә башка бер әйбер түгел иде. Шул җәһәттән карап, без исламны мәдәниятемезнең иң нык баскычы саныйбыз» [9: 351].

Ислам дине кануннары сагында торучылар һәм шулай ук Давыт Урманов та үзенең фикри үсешенең икенче баскычында «ислам милләтен аякка бастыру, аны яңадан тәрәккый вә мәдәниятле ясау өчен, шул мәңгелек нур булган исламны каплаучы яһүд мәҗүсият болытларын таратып, саф вә хакыйкый исламга кайтару» [10: 164] фикерен алга сөрә.

Аерым чыгышларда мәгърифәтчелек, уку-гыйлем, тәрбия проблемаларыннан тыш социаль: ярлылык, җирсезлек, сәяси изелү мәсьәләләре дә күтәрелә һәм алар татар милләтен инкыйразга китергән сәбәпләр буларак ассызыклана [10: 156].

Нотыкчылар, шул исәптән Давыт Урманов та, төп проблемага нисбәтле, үзләре кичергән фикри үсеш баскычлары хакында сөйли. Төп каһармандагы үзгәреш язучының «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясендәге Зәки шәкертнең, «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә»дәге (1909) Сәлимнең, «Мәрхүмнең дәфтәреннән» (1914) әсәрендәге хикәяләүче «мин»нең фикри үсеш баскычлары туры килеп кенә калмый, ә үсә-үзгәрә барып, тәмамланган төс ала: «беренче баскыч – кадимче, икенче баскыч – дин ислах итүче, өченче баскыч – татар милләтчесе, дүртенчесе – социалистлык баскычы». Романдагы аерым күренешләрнең, геройлар эш-гамәлләренең әдипнең башка әсәрләре белән бәйләнеше мәсьәләсе галимнәр тарафыннан да билгеләнгән. Татар әдәбиятында әдәби типларның үзенчәлекләре, структурасы анализланган «Әдәби типлар механизмы» (1929) китабы авторы Х. Вәли «Зәки шәкертнең...» басылып чыгуына һәм язучы әдәби эшчәнлегенә 20 ел тулу уңаеннан язылган юбилей мәкаләсендә: «Зәки безнең татар матур әдәбиятында ислахчы шәкертнең чын-чын тибы ул! Әдип Зәкидә ислахчы шәкертнең бөтен эчке мөндәриҗәсен биргән» [8: 54] – дип ассызыкласа, Г. Нигъмәти «Яшь йөрәкләр» психологик романы белән эчке бәйләнешне күрсәтә [12: 117 ]. Шул ук вакытта Г. Ибраһимов героеның эш-гамәлләре, рухи тартышлары, фикри инкыйлабы Г. Исхакыйның «Мөгаллим» (1908) пьесасындагы Салих, «Тартышу» (1907, 1917) тарихи-инкыйлаби драмасындагы инкыйлабчылар: Закир, Сабир, Насыйр, Шәйхетдин, Ф. Әмирханның «Яшьләр» (1909) драмасындагы Йосыф, Газиз, Г. Коләхмәтовның «Ике фикер» (1906), «Яшь гомер» (1908) әсәрләрендәге Давыт, Гали һәм башкаларныкы белән бик тә аваздаш. Язучы релистларча эш итеп, татар яшьләрендәге үзгәрешләрне гомумиләштереп бер типта сәнгатьчә гәүдәләндерүгә ирешә. Г. Нигъмәти романның беренче вариантын бәяләгән рецензиясендә болай дип яза: «Ул татар эсерларының уртак характер сыйфатларын бергә җыючы сурәт, әсәрдә аның үсеш, үзгәреше һәм әдип тарафыннан аңа бирелгән бәя шул вакыттагы бөтен татар эсерларына, шулар хәрәкәтенең үсешенә бирелгән бәя дип каралырга тиеш»

[12: 104]. Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» (1909) хикәясенә рецензия язган Н. Гасрый [5], Җ. Вәлиди [3] 1910 елларда ук Г. Ибраһимовның Сәлим образында инкыйлаб һәм реакция елларында зыялы татар яшьләрендәге фикри үзгәрешләрне сурәтләвен, әсәр идея эчтәлегенең заман әдәбияты белән бәйләнешен билгелиләр [7].

Социалист-революционер Давыт Урманов романда мәдрәсә чуалышларын, татар революционер яшьләрнең бишенче еллардагы көрәшләрен һәм реакция чорында тормышларын бәйләп торучы үзәк каһарман булып тора. Уртак максатлар һәм идеяләр белән бер-берсенә бәйләнмәгән вакыйгалар да Давыт Урманов шәхесе аркылы бер җепкә тагылалар. «Әсәрдә революцион яшьләрнең идеологы итеп бирелгән һәммә яшь аңа сүзсез хөрмәт белән олылап карый торган итеп күрсәтелгән Давыт менә шул» [12: 104]. Безнең карашыбызча, Давыт Урмановның прототибы – ул вакытта эсерлар партиясенең актив сәясәтчесе булган Г. Ибраһимов. Татар милләтенең матди хәлен ныгыту, икътисади хәлен яхшырту, татар мәгарифен үстерү, татар халкын мәдәни яктан алга киткән башка милләтләр дәрәҗәсенә җиткерү максатын күз уңында тоткан милли идеологлар: Шиһабетдин Мәрҗани, Исмәгыйль Гаспралы, Рәшит Ибраһимов, Галимҗан Баруди, Риза Фәхретдинов, Муса Бигиев, Йосыф Акчура, Садри Максуди, Гаяз Исхакый, Хөсәен Ямашев, Мулланур Вахитов һәм башкалар арасында татарчылык хәрәкәтен нигезләрүче Галимҗан Ибраһимов та бар.

Г. Ибраһимов «Безнең көннәр» романында сурәтләнгән тарихи вакыйгалар һәм аларда катнашкан төрле социаль катлам вәкилләренең язмышлары, дөньяга карашлары, иҗтимагый позицияләре аша татар милләтен саклап калу, аны үстерү һәм мәдәниләштерү юлларын ачыклый һәм аларны татар зыялыларына күрсәтә.

ӘДӘБИЯТ


1. Әмирхан Ф.З. Әсәрләр: 4 томда. 4 т.: Әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 390 б.

2. Вәли Х. «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» // Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2008. – Б. 49–56.

3. Вәлиди Җ. Яшьләр хәятыннан бер ләүхә // Вакыт. – 1914. – 26 гыйнвар.

4. Галимджан Ибрагимов: «Я жизнь искал, смысла в жизни искал…». – Казань: ИЯЛИ, 2017. – 336 с.

5. Гасрый Н. Яшьләр хәятыннан бер ләүхә // Ил. – 1914. – 2 гыйнвар (№ 10).

6. Гилазов Т.Ш. Вклад Джамала Валиди в историю литературной мысли у татар // Филология и культура. Philology and Culture. – 2015. – № 4 (42). – С. 206–210.

7. Гилазов Т.Ш. Рассказ Г. Ибрагимова «Один эпизод из жизни молодежи» в литературной критике 1910-х годов // Филология и культура. Philology and Culture. – 2017. – № 2(48). – С. 153–158.

8. Гыйлаҗев Т.Ш. Татар әдәбияты. XX гасыр башы: Лекцияләр, гамәли дәресләр, тестлар: Югары уку йортлары өчен уку әсбабы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 239 б.

9. Җамал Вәлили: әдәби һәм тарихи-документаль җыентык / төз. Диләрә Абдуллина, Җәүдәт Миңнуллин. – Казан: Җыен, 2010. – 624 б.
10. Ибраһимов Г.Г. Әсәрләр: 15 томда. 4 т.: роман [төз., текст, иск. һәм аңл. әзерл. Г.Г. Батыршина]. Академик басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – 376 б.
11. Исхакый Г. Әсәрләр: Унбиш томда. 1 т.: Повестьлар һәм хикәяләр (1899–1908) [төз., текст, иск. һәм аңл. әзерл. Л. Гайнанова; кереш мәкалә авт. М. Хәсәнов]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 399 б.
12. Нигъмәти Г. «Безнең көннәр» һәм аның стилендә бишенче еллар сыйнфый көрәшенең чагылышы // Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. – Б. 92–118.

УДК 82.091

## ТВОРЧЕСКИЕ И ОБЩЕСТВЕННЫЕ ВЗАИМОСВЯЗИ Г. ИБРАГИМОВА И Ш. КАМАЛА

***Г.Р. Зигангирова***
*Национальный музей Республики Татарстан (Казань)*

Архив писателя Шарифа Камала, который хранится в фондах Национального музея Республики Татарстан, включает в себя в том числе и документы, связанные с литературной и социальной деятельностью Г. Ибрагимова. Ш. Камала и Г. Ибрагимова связывало многолетнее творческое и личное знакомство. Они были самыми издаваемыми авторами в 1910-х гг. в издательстве газеты «Вакыт» и в журнале «Шура». В 1920-е годы, приехав в Казань, Шариф Камал начинает работать в Народном комиссариате просвещения, где принимает участие в формировании нового советского феномена татарской культуры. Литературная деятельность Ш. Камал была критически оценена Г. Ибрагимовым. Шариф Камал многократно посещал Г. Ибрагимова в Ялте. Их вклад в развитие татарской культуры начала XX века был важнейшей частью национального обновления.
**Ключевые слова:** Шариф Камал, Г. Ибрагимов, источники, история, музей, татарская литература.

The archive of the writer Sharif Kamal, kept in the funds of the National Museum of the Republic of Tatarstan, includes documents related to the literary and social activities of G. Ibragimov. Sh. Kamal and G. Ibragimov were connected by many years of artistic and personal acquaintance. They were the most published authors in the 1910s in the publishing house of the newspaper «Vakyt» and in the magazine «Shura». In the 1920s, having arrived in Kazan, Sharif Kamal began working at the People’s Commissariat of Education, where he took part in the formation of a new Soviet phenomenon of Tatar culture. The literary activity of Sh. Kamal was critically evaluated by G. Ibragimov. Sharif Kamal repeatedly visited G. Ibragimov in Yalta. Their contribution to the development of Tatar culture at the beginning of the 20th century was an essential part of the national renewal.
**Key words:** Sharif Kamal, G. Ibragimov, sources, history, museum, Tatar literature.

# Г. ИБРАҺИМОВ ҺӘМ Ш. КАМАЛНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ ЭШЧӘНЛЕК МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ

***Г.Р. Җиһангирова***
*Татарстан Республикасы Милли музее (Казан)*

Татар әдәбияты тарихын бүгенге мөмкинлекләрне файдаланып өйрәнү, яңа чыганаклар нигезендә төрле яклап тикшеренүләрне киңәйтү эшендә Милли музей фондларында сакланган материаллар үз кыйммәтләрен югалтмыйлар. Музей фондында сакланган бай архивларның берсе – язучы Ш. Камал коллекциясе. Бу материаллар язучының иҗатын, тормышын белү белән бер рәттән татар әдәбияты һәм тарихындагы шул дәвернең вакыйгаларын, үзгәрешләрен өйрәнү һәм анализлау өчен дә мөһим чыганак.

Шәриф Камал – татар әдәбиятында лаеклы урын алган, үзенчәлекле әдәби мирас калдырган язучы буларак кына түгел, татар халкы үз тарихында мөһим үзгәрешләр кичергән дәверендә яшәгән һәм иҗат иткән күренекле шәхес буларак та әһәмиятле. Бу фикерне дәлилләп аның гасыр башындагы татар мәдәни һәм әдәби тормышының танылган вәкилләре белән мөнәсәбәтләрен ачыклау мөһим. Кызганыч, сакланып калган материаллар арасында ул дәвердә эзәрлекләүләргә дучар булган шәхесләр белән мөнәсәбәтләрне чагылдыручы чыганаклар бик аз. Әмма булганнарының әһәмияте шуның белән зуррак та.

Шәриф Камалның Галимҗан Ибраһимовка мөнәсәбәтен күрсәтүче бик сирәк язмаларның берсе – язучы архивында сакланган кечкенә генә язма кисәге. Анда мондый җөмлә бар: «…Шулай итеп миннән "әдәм рәтле" язучы тәки чыкмады. Тик шуны әйтергә кирәк: атаклы язучы Галимҗан Ибраһимов ул чакта минем язулар турында шактый югары бәя биреп язды һәм язу эшеннән бөтенләйгә ваз кичүемә дә ул сәбәп булды»[1]. Бу Шәриф Камал иҗатының башлангыч чоры хакында әйтелгән фикер. Чыннан да Шәриф Камалның 1914 елда Оренбургта «Вакыт» газетасы нәшриятында дөнья күргән "Хикәяләр төркеме" китабы хакында "Йолдыз" газетасының № 1364 санында Г. Ибраһимовның мәкаләсе басылган.

Ә 1915 елда Әхмәтгәрәй Хәсәнигә язган хатында Г. Ибраһимов: «...Дәхи түбәндәге әсәрләрне йибәрсеннәр иде: Шәриф Камалның хикәяләр төркеме, Галимҗан Ибраһимовның моңарчы чыккан барлык әсәрләре, Галиәсгар Камалның "Дәҗҗал", "Мостафад әл-әхбар"ның беренче җилде, Риза казыйның "Әсма белән Сәлимә"се...», – дип яза [2: 91]. Г. Ибраһимов тарафыннан 1918 елда төзелгән «Яңа әдәбият» исемле дәреслектә Шәриф Камалның хикәясе урын ала.

[1] Татарстан милли музее фондлары. НМРТ КП-18118/113.

Бу ике язучының иҗади һәм иҗтимагый эшчәнлегендәге уртак тема буларак, аларның эшчеләр тормышы хакында язылган мәкалә һәм әсәрләрен билгеләп узарга була. «Кызыл Татарстан» газетасының 1924 елгы 2 июнь (107 (1019)) санында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән «Бондюг пролетариаты арасында» дигән мәкалә басылып чыга. Галимҗан Ибраһимов бу мәкаләсендә эшчеләрнең тормыш шартларын яхшырту кирәклекне һәм татар эшчеләренең административ җитәкчелектә, агарту эшендәге активлыгын арттыру кирәклеген яза. «Областком безне (Нечаев һәм мине) сәяси бер эш өчен IX өлкә конференциясе турында доклад ясап, кайбер аңлашылмауларны чишү өчен жибәрсә дә, Бондюг төбәгенең эченә кергәч, бу мәсьәлә белән бер дәрәҗәдә үк мине бу җирдәге пролетариатның көндәлек хәле үз эченә тартып алды... – дип яза Г. Ибраһимов. – ...Мәсьәләнең аеруча тукталырга тиешле урыны менә кайда: әлбәттә күп еллар буенча төзелгән завод корпусларын, серный, хлор корпусларын, сульфат мичләрен тиз генә күчереп булмаячак. Болар күп заман шунда торачак, эшләячәкләр, ләкин эшчеләр тора торган квартирларны бу сазлыктан, бу малярия, бизгәк, башка һәртөрле агулы газлар сазлыгыннан бераз читкә, служащийлар яшәгән сырт буендагы коры, таза, һәйбәт урыннарга таба күчерү эше әлбәттә, әлбәттә, беренче планда булырга тиешле иде» [3: 101]. Ә менә Шәриф Камалның 1930 елда Хөсни Кәримовка язган хатында: «Заводттан читтәрәк тау-калку җирдә 25 елда гына эшчеләр поселкасы салынган. Бик матур, агач йортлар. Дача шикелле агачлы, яхшы һавалы матур җир», – дип яза[1].

Шәриф Камал Бондюг заводы, аның эшчеләре белән шактый еллар тыгыз бәйләнештә була. 1929 елда Бондюг заводы рабкорлары Татар пролетариат язучылары ассоциациясенә хат язалар. Хатта: «...Бондюг заводының тормышын, социализм төзү юлында ирешкән уңышларын өйрәнергә үзегезнең вәкилләрегезне җибәрүегезне сорыйбыз...», – дигән үтенеч белдерелә. Татарстан пролетариат язучылары оешмасы бу хатка түбәндәгечә җавап бирә: «...1. Бондюг заводына шушы айларда Татарстан пролетариат һәм совет язучыларыннан махсус бер экскурсия, поход оештырырга; 2. Бондюг эшчеләре һәм Бондюг заводы белән ныклап танышу һәм эшчеләрне пролетариат әдәбияты алдында торган бурычлар белән таныштыру өчен ТАПП членнарыннан ике иптәшне озаграк вакытка Бондюг заводына җибәрергә» [1: 112]. Хатка кул куючылар арасында Ш. Камал да була. 1930 елның июнь-сентябрь айларында ул Бондюгта яши һәм бу әдәби командировка нәтиҗәсендә Шәриф Камал «Таулар» пьесасын яза.

[1] Татарстан милли музее фондлары. НМРТ КППи124406/2304.

Галимҗан Ибраһимов белән Шәриф Камалның милли-иҗтимагый мәсьәләләрне хәл итүдәге эшчәнлеге татар алфавиты мәсьәләсен хәл итүдә дә чагыла. 1926 елның февраль-март айларында Бакуда Беренче тюркология съезды булып уза. Төрки халыкларның алфавиты мәсьәләсен күтәргән бу съездта Татарстан вәкилләре составында Г. Ибраһимов һәм башка катнашучылар белән бергә Шәриф Камал да була. Латин алфавитына күчү яки төзәтү һәм камилләштерү юлы белән гарәп алфавитын калдыру мәсьәләсе бик кискен куела. Бу хәлдә Шәриф Камалның карашларын күрсәтүче мәкалә 1926 елда «Кызыл Татарстан» газетасының 28 март (№71) санында басылып чыккан. «Шулай да "машинаның әйләнүе, мәдәни хәрәкәтнең барышы акрынаю" мәсьәләсендә Галимҗан иптәш фикеренә беркадәр кушылырга мөмкин. Бигрәк тә "мәдәни байлык" белән икътисадый ярлылыкның каршылыклары тәгәрмәчне азмы-күпме акрынайтмый хәле юк. Ләкин тарихи туу чорларында аның ише "акрынаю"лар була, аңар карап торылмый...», – дигән фикерен җиткерә Шәриф Камал [3: 257].

1927 елның 5 декабрендә ВКП(б) Өлкә Комитеты секретариатының утырышында Г. Ибраһимовның юбилеен үткәрү комиссиясе төзелә. Ш. Камал бу комиссия составына кертелә. Билгеле булганча, 10 мартта Казанда тантаналы зур кичә уздырыла, әмма Галимҗан Ибраһимов үзе бу тантаналарда катнаша алмый.

1934 елда Шәриф Камалның иҗат кичәсен уздырганда Г. Ибраһимов аны котлап шәхси тәбрикләү җибәрә: «Кадерле Шәриф Камал иптәш! Синең иҗат эшеңә 25 ел тулу көнендә, кадерле Шәриф Камал иптәш, сиңа кайнар сәлам. Озак һәм ныклы көрәш һәм үз өстендә эшләү процессында син татар әдәбиятының чын шедеврларын тудырдың. Синең иҗатыңда бәхетле рәвештә художникның зур осталыгы һәм безнең бөек социалистик төзелешебезне тирәннән белү ярашалар. Синең уңышларыңа чын күңелдән шатланам һәм киләчәктә тагын да зур иҗат уңышларына ирешүеңне телим. Галимҗан Ибраһимов, 27 декабрь, 34» [2: 212]. Ш. Камалның 25 еллык иҗаты юбилее 1934 елның 29 декабрендә Татар дәүләт академия театры бинасында үткәрелә. Әдипнең иҗаты турында Г. Нигъмәти доклад сөйли. Тамашага юбилярның «Томан арты» пьесасы куела. Г. Ибраһимовның Кави Нәҗмигә язган хатында: «Матбугат аркылы Шәриф Камал юбилеен карап бардым. Бу бик күңелле бәйрәмгә әйләнде, бик яратып калдым», – дигән фикерләр дә бар [2: 213].

Бу ике шәхеснең иҗади, иҗтимагый аралашуы белән бергә аларның очрашу-күрешүләре дә билгеле. Шәриф Камал архивында документаль теркәлгән фактлар буенча Галимҗан Ибраһимов белән Шәриф Камал 1929 елда август-сентябрь айларында булган сәяхәт вакытында күрешә. Татар пролетариат язучылары ассоциа-

циясе, татар язучылар җәмгыяте члennары һәм сәнгать көчләренең СССРның көнчыгыш, көньяк җөмһүриятләренә экскурсиясендә катнашучы буларак Ш. Камал да Ялтада ял итүче Галимҗан Ибраһимов белән очраша. Шәриф Камалның хатларына нигезләнеп, без аның 1937 елда Ялтада ял вакытында да Г. Ибраһимов белән күрешүен дәлилли алабыз. 1937 елның 31 гыйнварында ул: «Иптәшләр – Тинчурин белән Нигъмәти бүген киттеләр. ...Эшем ничава әйбәт бара. "Матур туганда"ны бетереп кайтырга уйлыйм. Вакытында әлбәттә. Галимҗан Ибраһимов белән атна-ун көнгә бер күрешәбез», – дип яза[1]. 1937 елның 19 февралендәге хатында: «Үземнең исәнлек зарарсыз. Галимҗан Ибраһимов белән сирәк кенә күрешә торам», – диелә[2].

Замананың зур күтәрелеш, кискен борылыш елларында яшәп, үз чорларының кырыс, аяусыз дәһшәтләрен кичәргә туры килгән бу шәхесләр үзара мөнәсәбәтләренә тугрылыклы булып олы, уртак бурычларын тормышка ашыруда бар көчләрен куеп яшәгәннәр. Аларның әлеге фидакярлеге чиксез хөрмәт һәм онтылмаслык хәтергә лаеклы.

ӘДӘБИЯТ

1. Әдәбият баскычлары: татар совет әдәбияты елъязмасы (1917–1973). – Казан. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты. 1976. – 475 б.

2. Галимҗан Ибраһимов: хатлар һәм документлар / Төзүче Ф. Ибраһимова. – Казан: Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты. 2000. – 464 б.

3. Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Духовное наследие: поиски и открытия / под ред. И.Г. Гумерова. – Казань. 2017. – 336 б.

УДК 82.091

## ГАЛИМДЖАН ИБРАГИМОВ – СОЗДАТЕЛЬ ТЕОРЕТИЧЕСКИХ ДИСКУРСОВ В ТАТАРСКОМ ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИИ

***Д.Ф. Загидуллина***
*Академия наук РТ (Казань)*

Теория татарской литературы как наука возникла в начале XX века, за сравнительно короткий срок своего существования она развивалась весьма быстро и энергично, породив несколько оригинальных концептуальных направлений. Два из них связаны с именем Галимджана Ибрагимова. Он воспринимал саму литературу и литературоведение как возможность воздействия на умы и чувства соплеменников для пробуждения татарского общества от вековой спячки. Перспективным путем развития татарской литературы он считал романтизм. Ставя жесткие требования к себе и соратникам по перу, Г. Ибрагимов пытался

[1] Татарстан милли музее фондлары. НМРТ КППи-124406/332.
[2] Татарстан милли музее фондлары. НМРТ КППи-124406/234.

изменить общественно-культурное мнение средствами самой художественной литературы, литературной критики, а также теоретических изысканий.
После 1917 года в научном и художественном творчестве Г. Ибрагимова произошел отказ от этих принципов. Писатель возглавил формирование марксистско-ленинской литературоведческой концепции.
**Ключевые слова:** Галимджан Ибрагимов, татарская литература, литературоведение, теоретическая концепция.

The theory of Tatar literature as a study appeared at the beginning of the XX century. In a relatively short period of its existence it developed very quickly and energetically, giving rise to several original conceptual directions. Two of them are associated with the name of Galimzhan Ibraghimov. He considered literature and literary studies as an opportunity to influence the minds and feelings of Tatar people and to awaken Tatar society from a long age of sleep. He thought of Romanticism to be a promising way for the Tatar literature to develop. Setting strict requirements for himself and his colleagues-writers, G. Ibraghimov tried to change the socio-cultural views by means of fiction, literary criticism, and theoretical research.
After 1917, G. Ibragimov rejected these principles in his academic work and writings. The writer spearheaded the formation of the Marxist-Leninist concept of literary criticism.
**Key words:** Galimzhan Ibraghimov, Tatar literature, literary criticism, theoretical concept

Разносторонность интересов – отличительная черта многих татарских интеллектуалов. Однако у Галимджана Ибрагимова эта черта характера настолько очевидна, что зачастую непонятно, какое амплуа для него самого считалось первичным: общественно-политического деятеля, писателя, ученого-литературоведа, языковеда, историка, или что-то еще. Он во всех направлениях добился неординарных результатов.

Вместе с тем, трудно отыскать среди татарских интеллектуалов и столь противоречивого в своих взглядах человека, каким являлся Г. Ибрагимов. Это особенно заметно на примере трудов по татарскому литературоведению. Тем не менее, именно он стал основателем нескольких концептуальных направлений, тем самым способствовав формированию и развитию татарского литературоведения. Попытаемся доказать это на примере общеизвестных трудов ученого.

Первое серьезное теоретическое исследование о литературе – «Әдәбият мәсьәләләре» («Вопросы литературы») было написано им в 1910 году. Г. Ибрагимову было тогда 23 года, за плечами – обучение в кадимистском и джадидистском медресе, первые писательские и журналистские опыты. Кроме своего родного татарского, он хорошо владел русским, арабским и персидским языками;

очень много читал – и читал на разных языках. Написанная им книга «Борынгы ислам мәдәнияте» («Культура древнего ислама», 1909), касающаяся исламского влияния на культурный скачок многих народов Средневековья, свидетельствует о том, что молодой Ибрагимов приступил к поиску опорных точек для возрождения татарской культуры.

Появившаяся вслед за ней большая статья «Вопросы литературы» выделяет один из столпов в шкале ценностей, способных привести народ к духовному возрождению. В ней Г. Ибрагимов ищет ответ на вопросы «Что есть литература? Что в нее входит?» и приходит к заключению, что литературные произведения «…дают утешение при нестерпимых страданиях и разных беспокойствах жизни, возрождают поникшую душу, зажигают погасшие надежды, показывают живые явления из жизни» [3: 49]. Автор считает духовную, эстетическую и общественную роль литературы весьма важной. По его мнению, она затрагивает душу человека, обращается, прежде всего, к чувствам читателя, и благодаря этому может вести его к определенной идее, к действиям.

В свою очередь, в этой статье налицо крайне критическое и негативное отношение к современной ему татарской литературе. Художественную ценность произведения Г. Ибрагимов видит в трех признаках: красота, эмоциональность и образность. «Взвешивая» творчество современников, он заявляет, что З. Башири, М. Укмасый не являются поэтами, отсуствие красоты, эмоциональности и образности в произведениях М. Гафури и Н. Думави также лишают их перспектив. Только поэзию Тукая он находит более или менее соответствующей выдвинутым им требованиям. В целом, нехватку глубины и тематической широты он считает недостатками татарской литературы, не позволяющими ей расти и стать во главе татарской общественно-философской мысли в ее стремлении к возрождению нации.

Таким образом, становятся ясны мотивы Г. Ибрагимова, обратившего свой взор на теоретические аспекты развития художественной культуры. Он ставит высокие требования к зарождающейся новой светской литературе, иногда без учета потенциала татарских писателей и поэтов, считая себя тем, кто способен вести за собой, указывая на все положительное и отрицательное в этом пути.

Например, в 1910 году Г. Тукай составляет свою первую хрестоматию – сборник авторских произведений под названием «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» («Уроки национальной литературы в школе»). Здесь были представлены произведения самого Г. Тукая, а также стихотворения и отрывки из прозаических произведений Г. Исхаки, Ф. Амирхана, М. Укмаси, З. Хади, Р. Фахретдина, Ф. Карими и др. В рецензии на книгу Г. Ибрагимов ставит

Тукаю в упрек излишнее увлечение проповедничеством, дидактизмом, назидательностью в выборе текстов, обращает внимание на то, что некоторые произведения по духу не являются татарскими.

И это – в 1910 году, о первой (!) хрестоматии, в которой собраны авторские произведения! Почему? Г. Ибрагимов прекрасно понимал значение этой книги как пособия для мектебе, но ставил завышенные требования соратникам по перу, считая, что они своим трудом создают новую татарскую культуру. В статье «Без – татармыз» («Мы – татары», 1911) он пишет следующее: «Дела свои называем татарскими делами, сами мы – татары, язык наш – татарский, литература – татарская литература; всё, что нами достигнуто, – татарские достижения; культура, которая создается, будет татарской культурой» [6: 164].

А татарскую культуру он себе представляет на одном уровне с культурой развитых народов. Поэтому его критические статьи отличаются подробным, детальным разбором недостатков текстов. К примеру, в статье «Хаят» (1911), несмотря на высокую оценку творчества Ф. Амирхана в целом, он заявляет: «Произведение названо «милли хикәя» («национальный рассказ»). Руку даю на отсечение, это ошибочное определение. Чтобы назвать рассказ или роман национальным, недостаточно только того, что они написаны на татарском языке и о татарах, нужно, чтобы татарскость звучала в каждом слове, а герои должны быть насыщены татарским духом…» [3: 80]. С таким мнением о прекрасном классическом произведении татарской литературы начала XX века «Хаят» согласиться сложно.

Наиболее спорный труд Ибрагимова «Татар шагыйрьләре» («Татарские поэты», 1912) написан на материале творчества трех поэтов, заслуживших всеобщее признание в татарском обществе, и является поиском ответа на вопрос «Что есть поэзия?». «Всё, что воздействует на наши дух и мечты, вызывает эмоциональный отклик, есть поэзия. Стихотворение создается не столько языком и умом, сознанием, столько духом, душой человека, его мечтами и чувствами. Чтобы сделать поэтическое произведение совершенным, необходимо облечь тему в поэтические слова» [3: 117], – говорит автор и разбирает произведения трех татарских поэтов, выстраивая их по степени уменьшения значимости: С. Рамиев, Дэрдменд, Г. Тукай. В книге творчество С. Рамиева и Дэрдменда разобраны достаточно подробно и в плане мира образов, используемых приемов, и в плане новшества. В частности, поэзия С. Рамиева оценивается не как творчество для народа, а называется элитарным искусством. Г. Ибрагимов отмечает внутренний огонь его произведений, эмоциональность как наиболее сильные стороны творчества, в то же время указывает на то, что язык произведе-

ний не всегда поспевает за чувствами. «Эта эмоциональность, этот огонь Сагита слишком сильны, душа нетерпеливо и неестественно стремится куда-то, причем настолько, что такое стремление духа язык уже не успевает облечь в понятные читателю и красивые, естественные слова» [3: 115]. Таким образом, Г. Ибрагимов заявляет, что произведения С. Рамиева настолько сильные в плане эмоционального воздействия и заложенного в них смысла, насколько слабые в плане языка и речи.

Что касается творчества Дэрдменда, здесь Г. Ибрагимов высоко оценивает философскую глубину его произведений, облеченных в совершенную форму: «Потому что у него чувствуется истинный дух… литературный вкус, истинное мастерство слова, красивая форма, короткие и емкие фразы, легкость письма и чистое поэтическое чувство, соединенное с грустной мыслью...» [3: 131]. В ходе анализа отдельных произведений достаточно полно раскрываются отголоски экзистенциальной философии, общечеловеческие и личные ценности, выраженные в творчестве поэта. Этот материал Г. Ибрагимова имеет полное основание считаться трудом, где дана полная оценка творчества поэта.

Разговор о творчестве Г. Тукая Г. Ибрагимов начинает с критики его художественного языка. Анализ отдельных произведений также выстроен в виде раскрытия недостатков литературной мысли поэта. Г. Ибрагимов ставит вопрос: «Тукай – поэт или нет?» Обобщая, дает следующий ответ: «Читатель, который ценит, прежде всего, рифму, язык произведения, заложенные в него мысли и мнения, несомненно, будет считать его поэтом. Так как у Габдуллы эфенди все это присутствует с избытком. Но те, кто хорошо подготовлен, чтобы отличить поэзию от простого рифмованного текста, содержащего моральные предписания, у кого развит художественный вкус, вряд ли ответят на вышеуказанный вопрос однозначно… Даже если посчитают его поэтом, то не всегда, не все его произведения назовут поэзией, но только малую часть творчества» [3: 158].

Опровергнув тезисы Ибрагимова, Дж. Валиди в статье «Татарские поэты» (1912), обвинив автора в том, что тот хочет видеть поэзию только лишь идеальной, элитарной, утверждает следующий порядок: Г. Тукаев, Дэрдменд, С. Рамиев.

Объективные и субъективные причины появления книги «Татарские поэты» Г. Ибрагимова в татарском литературоведении обстоятельно проанализированы, и нет нужды повторяться. Хочется обратить внимание только на тот факт, что не только в критических и теоретических статьях, но и в своем творчестве Г. Ибрагимов отдает предпочтение романтизму европейского типа. Его рассказы («Яз башы» («Начало весны», 1910), «Диңгездә» («На море», 1911), «Йөз ел элек» («Сто лет назад», 1911), «Сөю –

сәгадәт» («Любовь – счастье», 1911), «Уты сүнгән җәһәннәм» («Геенна без огня», 1911), «Карак мулла» («Мулла-вор», 1911) и др.) и роман «Яшь йөрәкләр» («Молодые сердца», 1912) написаны в рамках этой художественной парадигмы.

Г. Ибрагимов в этот период времени считал романтизм перспективным путем для развития татарской литературы, поскольку он, по его мнению, способен довести до народа национальную идею. Особенно четко это проявилось в предисловии к «Альбому», сборнику иллюстраций изобразительного искусства («Альбом» мөнәсәбәте белән бер-ике сүз», 1915) для абонентов журнала «Анг». В статье дан ответ на вопрос: «Что есть искусство?»: «искусство состоит в материальном воплощении идеального мира человека искусства» [4: 37]. Одновременно подчеркивается, что искусство должно служить национальным целям: «Лишь искусство способно показать истинное лицо, натуру народа» [4: 41]. Далее затрагивается вопрос служения литературы татарскому этносу: «Его спасет от полного исчезновения, от поглощения бурным культурным потоком других народов только собственное искусство, способное сыграть на самых тонких струнах ее души», «люди искусства станут единственным спасителем нации» [4: 48].

На татарской литературоведческой арене это время примечательно тем, что является периодом поиска основ для формирования теории татарской литературы. Приспосабливая турецкую и арабскую науку о литературе к татарской литературе, Г. Сагди один за другим выпускает два учебника для медресе: «Мохтасар кавагыйде әдәбия» («Краткие правила литературы», 1911), «Мохтасар кавагыйде әдәбия»гә гыйлавә» («Дополнения к кратким правилам литературы», 1911). По сути, они являются переложением материалов по риторике, которые прошли долгий путь, начиная с переводов древнегреческого – на арабский, далее на турецкий языки. Татарское научное сообщество отвергает их, считая теорию устаревшей – с чем нельзя не согласиться.

Осознав необходимость перехода к новой системе понятий, основанной на западноевропейской и русской теоретической мысли, Г. Сагди пишет еще два учебника – «Әдәбият ысуллары» («Методы литературы», 1912) и «Әдәбият мөгаллиме» («Учитель литературы», 1913). Хотя в них многие понятия были уже адаптированы к национальной литературе, концептуально труды опирались на средневековые восточные поэтики, из-за чего не смогли справиться с поставленной задачей, не нашли свое место в формирующейся новой науке – теории литературы.

Отвечающей требованиям мировой литературно-теоретической мысли начала XX в. и национального литературного процесса стала теория литературы Габделбари Баттала. Его учебник «Нәзарияте

әдәбия» («Теория литературы», 1913) опирается на «Учебный курс теории словесности» Н. Ливанова, во многом является переводом с русского языка. При этом автор учебника касается и разъясняет многие термины и понятия, которые функционируют за рамками татарской литературы. Поэтому, хотя книга Г. Баттала ставит точки во многих открытых дискуссиях по проблемам теории татарской литературы, она не смогла полностью ответить на существующие вызовы в данной сфере.

На основе опыта преподавания татарской литературы в 1916 году Ибрагимов издает большой труд «Әдәбият дәресләре» («Уроки литературы»), где закладывает основы поэтики в соответствии со своими представлениями. Именно этот труд – «Уроки литературы» завершает в татарском литературоведении целый этап – формирование литературной теории. Хотя книга и написана в форме учебника, функции этого труда намного шире: объяснить, оценить татарскую литературу, основываясь на теоретических законах, определить пути ее дальнейшего развития. Идеализированный подход, подчиненный вполне функциональной цели – возрождению и развитию татарской культуры – стал основой его теоретического дискурса. Ибрагимов разрабатывает концепцию изучения татарской литературы – исходя из особенностей национальной литературы.

Вместе с тем, после 1917 года взгляды Г. Ибрагимова в целом на литературу, на ее цели и функции, критерии оценки отдельных произведений претерпели коренные изменения [2]. В трудах «Пролетариат әдәбияты турында» («О пролетарской литературе», 1924), «Кара маяклар, яки Ак әдәбиятлар» («Черные вехи, или Белоэмигрантская литература, 1924), «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» («Каким путем пойдет татарская литература?», 1927), написанных в духе марксизма-ленинизма, им подчеркивается, что литература является эффективным оружием в классовой борьбе, говорится о том, что дореволюционная литература не могла играть значительной роли в пролетарской борьбе, а эмигрантская литература вредна по сути. Самое печальное, пожалуй, то, что Г. Ибрагимов противопоставляет классовость и национальность, «говорит о разных течениях в татарском общественном движении, оценивает их с позиций классовой принадлежности участников, а представителей татарской интеллигенции, которые смогли спастись от крючка большевизма в эмиграции, обвиняет в контрреволюционной деятельности» [1: 142].

Труд под названием «Пролетариат әдәбияты турында» («О пролетарской литературе»), который был издан отдельной книгой в Москве, носит теоретический характер. В ней рассматриваются вопросы отношения марксизма к литературе, классовости

в литературе, связь литературы с общественной жизнью, затрагивается история просветительского движения в татарской культуре, общественный подъем под воздействием революции 1905 года, отдельные взгляды и мнения, господствовавшие в татарском обществе начала XX века и после революции 1917 года. Подводя итоги, Г. Ибрагимов пишет следующее: «…идеология, литература всегда и везде служат жизни, они обязаны быть связанными с событиями общественной жизни, подпитываться ими, поэтому и эпоха диктатуры пролетариата должна иметь свою собственную идеологию, искусство и литературу» [5: 214–215].

Отдельно останавливаясь на вопросе культурного наследия, Г. Ибрагимов и здесь пишет достаточно резкие слова, имевшие негативные последствия для дальнейшего изучения татарской литературы: «Ни один марксист не внесет в список произведений, способных помочь в воспитании рабоче-крестьянской массы и молодого поколения в плане развития их сознания, чувств, мечтаний и замыслов, способных формировать классовое сознание, «Салиму», «Магишат» или «Зулейху»» [5: 232]. Статья завершается призывом к татарским писателям создавать пролетарскую литературу.

В статье «Өч җавап» («Три ответа», 1922), написанной в духе теоретического спора с Ф. Бурнашем, который обратил внимание на изменения в теоретических взглядах Г. Ибрагимова, писатель заявляет, что он совершенно не отрицает своей дореволюционной теории относительно литературы: произведение должно быть написано на основе реальной жизни или же в отрыве от реальности. Он соотносит марксизм и дореволюционные теории относительно татарской литературы следующим образом: «…писатели и поэты живут не на небесах, талант их одухотворяется не небесами; они продукт своего времени, определенных общественно исторических условий, они плоды этой жизни. Поэтому миры, которые они рисуют, разные. Так же, как разные события жизни рождают в нас совершенно разные мысли, совершенно по-разному воздействуют на нас, описанные поэтами, писателями миры оставляют совершенно разный, но глубокий след в душе читателя. Здесь и встает вопрос о принадлежности поэта, писателя к какому-нибудь определенному классу, определенной точке зрения» [5: 113].

Г. Ибрагимов справедливо считается одним из основоположников научной истории татарской литературы, которая как самостоятельное направление науки возникла в 1920–1930-х годах. С одной стороны, фундаментальные труды по истории татарской литературы Г. Рахима и Г. Газиза, Г. Сагди появились благодаря организационной поддержке Г. Ибрагимова. Его мнение о необходимости изучать исторические корни татарской литературы начиная с Средневековья, высказанное в объемной статье «Татар әдә-

бияты тарихына материаллар» («Материалы к истории татарской литературы», 1923) в отношении второго тома «Истории татарской литературы» Г. Рахима и Г. Газиза, стало решающим при создании хронологии истории татарской литературы в дальнейшем, а одобрение Ибрагимова звучало как официальное признание данной концепции. Вместе с тем, Г. Ибрагимов в этой статье подчеркивает необходимость написания истории современной татарской литературы на основе марксистского метода.

Концепция истории литературы взаимосвязана с вопросом культурного наследия. Спор между Г. Ибрагимовым и Дж. Валиди в 1922–1923 годах возник именно на этой почве. Валиди проводил мнение, что прошлое культуры необходимо изучать и знать, несмотря на идеологические предпочтения. Ибрагимов же защищал мнение о том, что и к культурному наследию необходим классовый подход. Например, в статье Г. Ибрагимова «Татар әдәбиятында өченче дәвер (Аңларга тырышыгыз!)» («Третий период развитии татарской литературы (Постарайтесь понять!)», 1922), ценность классовой литературы поставлена гораздо выше ценности памятников словесности.

Коренная трансформация литературоведческих взглядов Г. Ибрагимова после 1917 года и сегодня вызывает противоречивые оценки. Многие его заявления не соотносятся с образом теоретика, который очень хорошо знал историю татарской и мировой литературы, и главное, как никто другой понимал истинную ценность художественного произведения. Сегодня мы не сможем однозначно ответить на вопрос, было ли это связано с искренней верой в революцию как возможность развития национальной культуры, или желанием сохранить то ценное в общественно-культурном развитии татарского народа, что было достигнуто в начале XX века. Видимо, при любом раскладе ясно одно: он считал себя сильным, чтобы ответственность за свой народ брать – на себя.

ЛИТЕРАТУРА

1. Абдуллин Я. Милләт язмышы: уйланулар. – Казан: Фән, 1999. – 317 б.

2. Заһидуллина Д. Галимҗан Ибраһимов – марксистик әдәбият фәне тудыруның үзәгендә // Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр: Унбиш томда. 8 т. –Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – Б. 8–30.

3. Ибраһимов Г. Әсәрләр: Унбиш томда. 6 т.: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1914). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – 327 б.

4. Ибраһимов Г. Әсәрләр: Унбиш томда. 7 т.: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1915–1916). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – 375 б.

5. Ибраһимов Г. Әсәрләр: Унбиш томда. 8 т.: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1918–1933). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – 431 б.

6. Ибраһимов Г. Әсәрләр: Унбиш томда. 11 т.: Тарихка һәм иҗтимагый фикергә караган хезмәтләр (1909–1920). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – 462 б.

УДК 821.512.145

# ОСМЫСЛЕНИЕ ГРАЖДАНСКОЙ ВОЙНЫ В ПЬЕСАХ ТОЙ ЭПОХИ (сравнительный анализ пьес Г. Ибрагимова, Ш. Усманова, Ф. С.-Казанлы)

***А.М. Закирзянов***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

Гражданская война, начавшаяся после революций 1917 года, основывалась на классовом противостоянии между двумя сословиями. Хотя татарские писатели по-разному относятся к войне, большинство воспринимает ее как путь к справедливому и свободному существованию. В статье анализируются пьесы Г. Ибрагимова, Ш. Усманова, Ф. С.-Казанлы, написанные в эти годы, рассматриваются вопросы борьбы героев за счастье народа, взаимоотношения классов внутри одной нации, пути к победе и др.
**Ключевые слова:** революция, Гражданская война, татарская драматургия, жанр, конфликт, герой.

The civil war that began after the revolution of 1917 was based on the class confrontation between the two estates. Although Tatar writers have different attitudes to the war, most perceive it as a path to a just and free existence. The article analyzes the plays of G. Ibragimov, Sh. Usmanov, F. S.-Kazanli, written during these years, examines the issues of the struggle of heroes for the happiness of the people, the relationship of classes within one nation, the path to victory, etc.
**Key words:** revolution, civil war, Tatar drama, genre, conflict, hero.

# ГРАЖДАННАР СУГЫШЫНЫҢ ШУЛ ЧОР ПЬЕСАЛАРЫНДА ЧАГЫЛЫШЫ (Г. Ибраһимов, Ш. Усманов, Ф. Сәйфи-Казанлы әсәрләре мисалында)

***Ә.М. Закирҗанов***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (Казан)*

1917 елгы инкыйлаблар нәтиҗәсендә ил ике лагерьга бүленә һәм ул Гражданнар сугышына китерә. Бүгенгедән чыгып караганда, бер якны аклау, икенче якны гаепләү була алмый. Анда җиңүчеләр юк, бары җиңелүче генә бар, бу – ил халкы, чөнки туган белән туганның үтерешүен, халыкларның бүлгәләнүен, бер өлешенең чит илләргә куылуын җиңү дип атап булмый. Әмма ул чорларда әлеге гаять катлаулы вакыйгаларны аңлау һәм бәяләү авырлык белән бара. Татар әдипләре Октябрь инкыйлабын һәм пролетариат диктатурасын кабул итү мәсьәләсендә өч лагерьга бүленә. Берләре яңа хөкүмәтне кабул итсә, икенчеләре чит илләр-

гә китә, өченчеләре исә икеләнеп кала, каршылыкларда азаплана. Әлеге мәкаләдә Гражданнар сугышы вакыйгаларының шул чор татар драматурглары әсәрләрендә чагылыш үзенчәлекләре тикшереп бәяләү максаты куела. Шуннан чыгып, әлеге чор җәмгыятендә туган җитди мәсьәләләрнең Г. Ибраһимов, Ш. Усманов, Ф. Сәйфи-Казанлы пьесаларында чишелешен, әсәрләрнең идея-эстетик эчтәлеген, заман геройлары чагылышын һәм кайбер поэтик үзенчәлекләрен ачыклау бурычлары куела.

Гражданнар сугышы вакыйгаларының татар әдәбиятында, шул исәптән драматургиядә чагылышы шактый өйрәнелгән. Басылып чыккан яисә сәхнәгә куелган пьесаларга әдәби тәнкыйть үз вакытында ук мөнәсәбәтен белдерә (Ш. Байчура, Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Ходаяров һ.б. мәкаләләре). XX гасыр дәвамында Г. Ибраһимов әсәре турында Г. Халит, М. Хәсәнов, Р. Бикмөхәммәтов, Б. Гыйззәт, шулай ук Ш. Усманов турында А. Яхин, А. Сагайдак, Г. Кашшаф, ә инде Ф. Сәйфи-Казанлы турында Х. Хисмәтуллин һ.б. тикшеренүләр алып бара. Бу чор драматургиясен аеруча тулы А. Әхмәдуллин өйрәнә. Ул әсәрләрнең жанр хасиятен билгеләү аша, күтәрелгән проблемаларны ачыклый һәм поэтик үзенчәлекләренә туктала [1: 123–146]. Без исә әлеге өч авторның беренче пьесаларын чагыштырып бәяләүне алга куябыз.

Октябрь инкыйлабыннан соң башланып киткән Гражданнар сугышы һәркем алдына «Син кем белән?» дигән сорауны куя. Инкыйлабларга һәм Гражданнар сугышына, кан коюга драматургларның мөнәсәбәте бертөрле генә булмый. Яшь совет власте әдәбиятны агитация максатларында файдаланырга омтыла. Бу эшкә милли лидерлар да алына. Белгәнебезчә, патша хөкүмәтеннән аермалы буларак, яңа хөкүмәт милләтләргә үзбилгеләнү вәгъдә итә. Шуңа да күпләр яңа власть шартларында милли мәнфәгатьләрне яклау мөмкинлеге тууга ышана.

Пролетариат диктатурасы һәм әдәбият мөнәсәбәтенә беренчеләрдән булып Г. Ибраһимов мөрәҗәгать итә. Инкыйлаблар һәм Гражданнар сугышы елларында язылган хезмәтләрендә үк бу мәсьәләгә әледән-әле әйләнеп кайта. Инкыйлабтан соң, Ф. Сәйфи-Казанлы белән бергә «Ирек», аннары «Безнең юл» кебек газеталар чыгарган әдип, милли азатлык хакына югары һәм түбән катлауларны берләштерү идеясен кире кага һәм сыйнфый көрәш юлына баса. Г. Ибраһимов болай дип яза: «Бөек канлы көрәш бара. (...) Бер якта – коллар, мәзлумнар (изелгәннәр), эшчеләр, ярлы крестьяннар, икенче якта шаһлар, байлар, алпавытлар, хуҗалар, хәзергечә – капиталистлар» [7: 263]. Әнә шундый шартларда күпчелек әдипләр яңа җәмгыятьнең беренче адымнарын, сугышның ачы михнәт-афәтләрен сурәтләргә омтыла. Бу елларда язылган әсәрләр иҗтимагый һәм көнкүреш эчтәлек белән сугарылып, яңа жанрга –

тарихи-революцион һәм героик драмаларга нигез сала [4: 89]. Аларда, чор таләп иткәнчә, үзара дошман булган, килешмәүчән ике сыйныф арасындагы көрәш сурәтләнә.

Гражданнар сугышы елларында Ш. Усмановның «Канлы көннәрдә» (1919), Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» (1920), Ф. Сәйфи-Казанлының «Дошманнар» (1920) кебек пьесалары язылып, басылып чыга яисә сәхнәләргә куела. Дөрес, беренче тәҗрибә буларак Г. Ниязбаевның «Беренче таң» (1918) әсәрен атау да дөрес булыр. Автор анда халык бәхете өчен көрәш юлына чыккан геройны мәйданга чыгара. Әмма әсәрдә 1905 ел вакыйгалары сурәтләнә. Без исә түбәндә Гражданнар сугышы чагылыш тапкан әсәрләргә киңрәк тукталабыз. Әлеге пьесаларның язылу максатларында уртаклык бар дип уйларга кирәк: бер яктан, бу чорда театр труппаларының кытлык кичерүе, икенче яктан, сугыш шартларына яраклы пьесаларның булмавы яисә бик аз булуы; өченче яктан, халык массаларына көрәшүче якларның асыл теләген ачу аша, аларны яңа тормыш өчен көрәшүчеләр ягына тарту.

Әсәрләр арасында үзенең әдәби-эстетик эшләнеше, автор карашларының ачыклыгы һәм алдагы чор әдәбиятына тәэсире ягыннан Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр»е аерылып тора. «Драма гражданнар сугышы чоры татар әдәбиятында барган эзләнүләрне аңлау-аңлату ягыннан һәм яңа иҗтимагый-тарихи, мәдәни-социаль шартлар тудырган әдәбият үрнәге буларак әһәмиятле» [5: 68]. Г. Ибраһимов Гражданнар сугышы шартларында яңа кешеләр формалашуны, аларның рухи-әхлакый йөзен, теләк-максатын ачуны алга куя. Чорның һәр кешесе алдына куелган сорауга җавап эзләп, инкыйлабка килү, аны кабул итү яисә итмәү мәсьәләсен куя. Әсәр геройлары төрле юллар белән халык бәхете өчен көрәшкә килә. Төп герое исә шактый катлаулы юл үтә: көнләшеп, кеше үтерә, каторгадан кача, сугышта инкыйлабны яклаучыларга кушыла.

Ш. Усмановның 1919 елның гыйнварында Оренбургта тәмамланган [1: 126]. «Канлы көннәрдә» пьесасында Гражданнар сугышының канлы вакыйгалары чагылыш таба. Авторның беренче әсәре икәнен исәпкә алсак, сәнгати эшләнешенең йомшаклыгы да аңлашыла. Ш. Усманов үзе әлеге вакыйгалар эчендә кайнап яши, татар легионында комиссар буларак акгвардиячеләргә каршы сугышларда катнаша. Автор драмада «революциягә килү юллары» [4: 235] проблемасын үзәккә куя. Беренче чиратта, ул бер гаилә яисә якын туганнарның караш-мөнәсәбәте буларак бирелә. Бертуган Камил һәм Хәмит аңлы рәвештә совет властен яклап сугышка керсә, гимназист энеләре Йосыф башта акгвардиягә языла, шулар сафында торып, кызылларга каршы сугышта катнаша, яралана. Шул вакыйгалар өермәсе аша яңа властьны яклау юлына

килә. Ә инде Хәмзә, башкорт гаскәре офицеры Зариф кебекләрнең бәхәсләр аша инкыйлабны яклауга килүе күпләр өчен гыйбрәт буларак сурәтләнә.

Ф. Сәйфи-Казанлының «Дошманнар»ында вакыйга 1917–1918 елларда бара. Инкыйлаблардан соң илнең тузгыган чагы, власть советларга күчеп барса да, контрреволюция әле көчле. Шуңа бәйле «Кем-кемне?» мәсьәләсе көн кадагында тора. Автор геройларының теге яисә бу лагерьга килү юлын ачу мәсьәләсенә зур урын бирә. Бу яктан Айсылу образы үзенчәлекле. Инкыйлаби романтизм аша сурәтләнгән хатын әтисе белән ире арасын җайга салырга тырышса да, вакыйгалар барышында иренең чын асылын белә. Хатип бай һәм аның янындагыларның дошманлыгын ачуга да зур өлеш кертә. Ахырда ул иренә болай ди: *«Сез хәзер миңа бары сыйнфый көрәштәге дошманым гына»*. Пафос белән әйтелгән сүзләр дәлилле ачылып бетмәсә дә, авторның бу мәсьәләгә карашын ачык күрсәтә.

Г. Ибраһимов инкыйлабларны шатланып каршы алса да, сугышка, кан коюга җиңел генә карый алмый. Шуңа да аның геройлары бу мәсьәләдә җитди бәхәс алып бара. Яңа җәмгыять төзүнең гуманлы юллары турында уйлана. Г. Ибраһимов объектив катламда властьны алу, аны саклау өчен кан коюны котылгысыз дип саный. Төп герой Батырхан әлеге карашны яклаучы буларак тәкъдим ителә. Бер яктан, «ул гөнаһсыз кан коюларга каршы чыгып, артык каты кыланучы Тимеркәй белән бәхәс алып бара» (4: 237). Икенче яктан, Шәйбәк карт позициясен дә кабул итми. Әлеге карт *«кан түгүгә киткәч, шәп түгел инде ул»* дигән фикердә тора. Батырхан исә революция өчен «*Канлы юл – изге юл!*» дип чыга. Вакыйгалар барышы шул фикерне раслауга хезмәт итә. Әсәрнең субъектив катламында әлеге каршылык укучыны бәхәскә китерә. Кан түгү, үтерү белән бәхетле җәмгыять төзү мөмкинлеген шик астына куя.

Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» драмасы төп яңалыгы, билгеле инде, яңа геройлар белән бәйле. «Г. Ибраһимов революция тудырган һәм революцияне ясаган көрәшчеләрне «яңа кешеләр» дип атый, яңа дәвернең үзенчәлеген һәм өстенлеген иң әүвәл шундый каһарманнарда күрә» [2: 170]. Шуңа да аның «яңа кешеләр» буларак сурәтләнгән Батырхан, Камәр, Тимеркәй кебек образлары шул чор кешеләренә гыйбрәт итеп калкытып куела. Д. Заһидуллина билгеләп үткәнчә, «Г. Ибраһимов гаилә мөнәсәбәтләре аша сыйнфый көрәш мәсьәләсенә килә, көрәшнең сәбәпләре итеп иҗтимагый тигезсезлек һәм милли азатлыкка ирешү өметен билгели» [6: 42].

Ф. С.-Казанлы, драма исеменнән күренгәнчә, власть өчен көрәшүчеләрнең үзара «дошманнар» булуын әсәр дәвамында

ача. Әлеге тартышны тагын да кискенләштерү өчен геройларны туганлык-гаилә мөнәсәбәтендә бирә. Ярлы халык мәнфәгатен яклаучы булып фабрика эшчесе Кәрим торса, югары катлау кешеләре фабрика хуҗасы Хатип бай тирәсенә җыела. Үзара дошманлыкларын яшермәгән бу ике кешене Кәримнең кызы, ә Хатипның хатыны Айсылу үзара бәйли. Конфликт гаять кискен булып, беренче күренешләрдә үк Кәрим югары катлау вәкилләрен «мәңгелек дошманнарыбыз» ди. Әсәрдә моның сәбәбе хәрәкәттә бирелмәсә дә, байлар ярлы халык эшләгәнне, тапканны ашаучылар итеп сурәтләнә. Алай гына да түгел, байларның үз балаларын да «елан» итеп үстерүләре кат-кат искәртелә. Югары катлау вәкилләре булган Хатип бай, Гомәров, Федоров һ.б. властьны коткару өчен барысын да эшләргә, хәтта террор оештырырга әзерләр итеп бирелә. Совет властен бәреп төшерү өчен, хәрби полклар оештыруга, газеталар чыгаруга миллионнар тотып, халык арасында җитди пропаганда алып баралар. Нәтиҗәдә күп кан түгелә, Кәрим дә үтерелә.

Г. Ибраһимов яңа җәмгыятьтә милләтләрнең урыны нинди булу, аларның иреге, сәяси-иҗтимагый хокуклары мәсьәләсе белән даими кызыксына һәм даими матбугатта чыгыш ясый. «Яңа кешеләр»дәге вакыйгаларда ул шулай ук чагылыш таба. Г. Мөхәммәдова фикеренчә, әсәрдә сыйнфый көрәш сәбәпләрен ачу белән бергә, милләтләр киләчәге турында җитди сүз бара: «Татар өчен милли азатлык мөһим булса, урыс өчен – бүленмәгән бөтен бөек Россия» [8: 132].

Ш. Усманов «Канлы көннәрдә» милләт азатлыгы мәсьәләсен читләтеп үтмичә, Хәмзә образында ярлы-байны милләт байрагы астына җыю фикерен күтәрә. Ул сәбәп-нәтиҗә бәйләнешендә ачылмаса да, әлеге герой бу фикереннән баш тартып, сыйнфый көрәшкә килә. Автор Гражданнар сугышының ил тәнендә яра булуын ача. Кызганыч ки, сугышучы яклар кан коюны яклап чыга, еш кына бер гаепсез кешеләр үтерелә. Йосыф *«мин сезнең кызыл бандалар талаган кадәр кеше таламам»* диюе белән совет яклыларның эш-гамәленә бәя бирсә, Камил акларның судсыз-нисез бик күпләрне юк итүләре, җәзалаулары турында әрнеп сөйли.

Ф. С.-Казанлының «Дошманнар»ында куелган мәсьәләләрнең берсе – «Бер милләт эчендә уртаклыкка ирешеп буламы, әллә инде сыйнфый көрәш котылгысызмы?» соравына җавап эзләү. Автор зур булмаган бәхәс аша ярлы-бай каршылыгы котылгысыз дигән фикергә китерә. Шуңа да эшче Кәрим белән бай Хатип каршылыкның ике ягында торып эш итәләр. Кәрим шактый тулы эшләнгән образ булып ачыла. Ул эзлекле, максатчан, байлардан үч алу теләге белән йөри. Еш кына лозунглар белән сөйләшә: *«Үлем байларга!»* яисә *«... телеграмм баганасына асачакмын...»* Бу яктан карганда, Хатип бай реаль тормышка якынрак, әмма гомерен саклап

калу өчен хатынына ялварган күренештә ясалмалылык сизелә. Ф. Сәйфи-Казанлы инкыйлабның, яңа тормышның корбаннар биреп кенә яулап алынуын ача. Шуңа да Айсылуның әтисе Кәрим гәүдәсе янында *«зур һәм бәхетле үлем»* дию инкыйлабый аскетизм чагылышы булып тора.

Шулай итеп, Гражданнар сугышы чорында язылган пьесаларны чагыштырып бәяләү аша түбәндәге нәтиҗәләргә килергә мөмкин: авторлар «яңа чор әдәбияты нинди булырга тиеш?» дигән сорауга җавап эзлиләр һәм бу мәсьәләдә Г. Ибраһимов әйдәп бара; пьеса авторлары совет хакимияте тудырган мифка ышанып иҗат итәләр һәм шуның белән киләчәктә тагы да үстереләчәк жанрларга, алым-формаларга нигез салалар; барысында да конфликт сыйнфый каршылыкка нигезләнә, ул исә аерым бер милләт эчендәге бердәмлек идеясен кире кага; пьесаларның җитди яңалыгы үзәккә чыгарылган көрәшче герой, яңа герой образы белән бәйле; Г. Ибраһимов, Ш. Усманов, Ф. Сәйфи-Казанлы инкыйлабны хуплап каршы алып, яңа хакимияткә хезмәт итәләр, шуңа да әсәрләрдә югары катлау кешеләре сыйнфый дошман буларак сурәтләнә; авторлар яңа җәмгыятьнең бары көрәш, кан кою аша гына төзү мөмкинлеген күрсәтә, шуның белән бергә, бу сугышның кешелек идеалына каршы килүен дә аңлыйлар һәм ул аерым геройлар эш-гамәлендә шактый ачык сизелә.

ӘДӘБИЯТ

1. Ахмадуллин А.Г. Татарская драматургия (История и проблемы). – Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. – 510 с.

2. Әхмәдуллин А. Г. Ибраһимов һәм татар драматургиясе // Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – Б. 165–177.

3. Әхмәдуллин А. Драматургия // Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 4 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 68–89.

4. Әхмәдуллин А.Г. Ш. Усманов драматургиясендә герой проблемасы // Дөреслеккә ирешү юлында. Мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – Б. 234–242.

5. Закирҗанов Ә.М. Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» драмасында яңа чор иҗат концепциясе чагылышы // Г. Ибраһимов мирасы һәм төрки дөнья: Г. Ибраһимовның тууына 125 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (17 апрель, 2012 ел). – Казан: ИЯЛИ, 2012. – Б. 67–71.

6. Заһидуллина Д.Ф. Галимҗан Ибраһимовның тормыш юлы һәм киңкырлы эшчәнлеге // Әсәрләр: 15 томда: 1 т. : хикәяләр, роман / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. Г.Н. Зәйниева; кереш сүз авт. Д.Ф. Заһидуллина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – Б. 10–61.

7. Ибраһимов Г. Шәрыкның бөек революционеры Мулланур иптәш Вахитов // Ибраһимов Г. Әсәрләр: 15 томда. 11 т.: тарихка һәм иҗтимагый хәрәкәткә караган хезмәтләре (1909–1920) / төз. Ә.Х. Алиева; текст, иск. һәм аңл. әзер. Ә.Х. Алиева һ.б.; кереш сүз авт. К.Г. Әхсәнов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2021. – Б. 362–372.

8. Мөхәммәдова Г. Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» драмасына карата кайбер фикерләр // Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: Тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. – Казан: Фикер, 2002. – Б. 130–132.

УДК 801.8

# ПРОСТРАНСТВЕННАЯ ОРГАНИЗАЦИЯ ПРОИЗВЕДЕНИЙ Г. ИБРАГИМОВА

***Г.Ф. Каюмова***
*Казанский (Приволжский) федеральный университет (Казань)*

В статье анализируется пространственное представление произведений разных жанров Г. Ибрагимова. Анализ произведений «Чубарый», «В море», «Начало весны», «Дети природы», «Судьба татарки», «Дочь степи», «Наши дни» показывает, что пространство является важным структурообразующим элементом в творчестве Г. Ибрагимова, оно тесно связано, с одной стороны, с событиями, текущими на фоне данного пространства, с другой стороны – с психологическими переживаниями героев, часто обуславливая и предопределяя их. Особое внимание уделяется анализу таких видов топоса как деревня, море, степь, город и локусов дома, медресе.
**Ключевые слова:** Г. Ибрагимов, пространственное представление, интерпретация, мифологические мотивы, татарская литература.

The article analyzes the spatial representation of G. Ibragimov's works of different genres. An analysis of the works «Chubary», «In the Sea», «Beginning of Spring», «Children of Nature», «The Fate of a Tatar Woman», «Daughter of the Steppe», «Our Days» shows that space is an important structure-forming element in the work of G. Ibragimov, it is closely connected, on the one hand, with the events taking place against the background of a given space, on the other hand, with the psychological experiences of the characters, often conditioning and predetermining them. Particular attention is paid to the analysis of such types of topos as the village, sea, steppe, city and loci of the house, madrasah.
**Key words:** G. Ibragimov, spatial representation, interpretation, mythological motifs, Tatar literature.

# Г. ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ПРОСТРАНСТВО БИРЕЛЕШЕ

***Г.Ф. Каюмова***
*Казан (Идел буе) федераль университеты (Казан)*

Матур әдәбият әсәрләрендә пространство категориясе бирелеше, аның оештырылу үзенчәлекләре галимнәрнең игътибар үзәгендә тора. Еш кына аны вакыт категориясе белән бәйлелектә карап, хронотоп категориясе составында тикшерәләр, физик һәм әдәби (мәдәни) пространстволарны чагыштырып өйрәнәләр, төрле тип пространстволарның – ачык һәм ябык, реаль һәм уйлап чыгарылган, «үз» һәм «ят», динамик һәм статик – әдәби әсәр идеясен ачудагы ролен тикшерәләр. Проблемага багышланган фундаменталь хезмәтләрдән М.М. Бахтин, Д.С. Лихачев, Г. Миноквский, Н.К. Шутая хезмәтләрен атарга була [1; 6; 7; 12].

Тәкъдим ителә торган эштә XX гасыр башында әдәбият мәйданында ныклы урын алган, әдәби барышта актив катнашкан, совет

чоры әдәбиятын да классик әсәрләре белән баеткан Г. Ибраһимовның әсәрләрендә пространство бирелешенең кайбер үзенчәлекләре тикшерелә. Әлбәттә, иң элек әдәби пространство үзенчәлекләре әсәрнең романтизм яки реализм кысаларында иҗат ителүе белән бәйле, чөнки романтик һәм реалистик геройлар дөньяны төрлечә кабул итәләр, ә укучыга урын-ара тасвирлары ешрак геройның кабул итүе аша җиткерелә. Иҗатының башлангыч чорынла романтик юнәлеш зуррак урын алуны искә алып, иң элек әдипнең романтик рухлы әсәрләрендәге пространство поэтикасына игътибар итик.

Г. Ибраһимовның романтизм белән сугырылган әсәрләрендә, тулаем алганда, романтик юнәлешкә хас мондый үзенчәлекләр калку гәүдәләнеш таба:

– кешене әйләндереп алган дөньяның чиксезлеге, ике тормыш: күнегелгән җир тормышы һәм илаһи-идеаль дөнья хакындагы күзаллау үзәккә куела;

– кеше серле көчләр җимеше, үткән һәм киләчәкне тоташтыручы күпер итеп карала;

– тормыш-чынбарлыкны тәнкыйтьләү, кире кагу алга чыга һәм пессимистик компонент ачык билгеләнә башлый;

– үткәнне – тарихны идеаллаштыру, экзотик материалга мөрәҗәгать итү, авторның субъектив позициясе ачык билгеләнү, фәлсәфи һәм лирик чигенешләр ясау кебек алымнарны куллану күзәтелә.

Әйтелгәннәрнең пространство бирелешендә чагылыш табуын тикшерик. Язучының иң күркәм романтик хикәяләренең берсе – «Диңгездә».

«Диңгездә» хикәясенең герое образы турында галимнәр түбәндәге фикердә: «Көнбатыш Европа һәм рус романтизм әдәбиятындагы традицион образны хәтерләтә. Ул шәһәр цивилизациясеннән бизеп, ниндидер илаһи галәмгә омтыла. Г. Ибраһимов, аның шул сыйфатын күрсәтеп бүтән якларын читтә калдырган. Кем ул, нинди профессия кешесе, кайда яши, гаиләсе бармы – берсен дә белмибез» [10: 164]. Без аны нәкъ менә диңгез буенча көймәдә баруын күрәбез. Диңгез – татар әдәбияты өчен ят, чит пространство, аңа мөрәҗәгать итү романтик геройның тормыш-чынбарлыкны, «үз» пространствоны (хикәядә ул төтенли торган торбалар тасвиры аша күңелгә ятышсыз итеп тасвирлана) кабул итмәве, куркыныч, шомлы булса да, «чит» аралыкка омтылышын күрсәтә. Тыныч диңгездә бару анда романтик кичерешләр уята, ул диңгез белән күкне илаһилаштыра, сынландыра, аларны гашыйк ярлар итеп күрә: «Гүя күк белән диңгез беренче сөю сәгатьләрен кичерәләр, гүя күк үзенең нурлы күзләре белән диңгезнең йөрәгенә карый да, бусы аңа миллионнардан күп, вак зиннәтле, сөйкемле елмаюы белән карап елмая, гүя бер-берен оныталар, тын кичәдә бер-берենә ташланалар, кушылалар» [4]. Әмма автор романтик героен сынау

алдында куя: дәһшәтле диңгез аның күңелендә кире кагу хисен уятмасмы, герой үзенең күнегелгән тирәлегенә омтылыш күрсәтмәсме? Герой икенче төрле диңгез белән таныша: ачулы, дәһшәтле диңгез картинасы укучының да күз алдына бастырыла: «Кояш баер алдыннан каты җил чыкты, шимальдән гаҗиб куәтле болытлар кузгалып, тиз арада алар бөтен дөньяны каплап алдылар. Тиз арада җирне судан, күкне диңгездән, уңны сулдан аера алмаслык караңгылык басты. Җил көчәя. Күк, таулар-ташлар җимергән, дөньяның астын өскә китергән кебек, куәт белән күкри. Яшеннәр өзлексез уйныйлар, җир-күкне каплаган катлаулы болытларны ярып, уңнан, сулдан утлы сызыклар сызгалыйлар» [4]. Кечкенә көймәдә мондый дәһшәт вакытында исән калу өмете аз булуын герой да, көймәчеләр дә кат-кат кабатлыйлар, әмма могҗиза була: көймә диңгез дәһшәтенә каршы тора. Барлык юлчылар да икенче көнне коры җиргә шатлана-шатлана аяк басалар, бары романтик герой гына вәхши тавышлы поездар үкергән, завод морҗаларыннан чыккан төтен күңелне болгаткан реаль чынбарлык күренешләре белән килешергә теләмичә, моңсу гына алга атлый.

«Яз башы» хикәясендә вакыйгалар бер татар авылы чикләрендә барса да, унбер яшьлек романтик герой кичерешләре ярдәмендә ачык пространство топослары тиз-тиз алмашынып тора. Тугыз ай укыган кысан мәдрәсә топосы хикәядә искәртеп кенә алына, аңа каршы рәвештә туган йорт топосы тасвирлана. Малай өчен туган йорт – ана образлары аерылгысыз, аларның очрашуын автор аерым бер җылылык белән тасвирлый. Акрынлап туган йорт пространствосы киңәя: герой бакча, сарай, келәт, ындырларны карап, һәр корылма белән аерым исәнләшеп чыга, болар барсы да аның күңеленә әйтеп бетергесез шатлык, ләззәт бүләк итә. Алга таба туган авыл кырлары, күлләре, уҗым басуының матур-романтик образлары, малай күңеле аша үткәрелеп, укучыга тәкъдим ителә. Хикәянең икенче бүлегендә күл, камышлык топослары әкияти-мифологик мотивлар белән өртелеп сурәтләнә. Безнең фикеребезчә, Көнбатыш Европа һәм татар романтик язучыларының пространствоны күрүдәге аермалыклар Г. Ибраһимов иҗатында ачык чагылыш таба. Көнбатыш Европа әдипләренең романтик иҗатында еш кына реаль чынбарлык пространствосы кеше өчен ят булган инферналь пространство белән кушып, үреп бирәләр, «гайре табигыйлык, реаль чынбарлык белән багланышлар тудырып, романтиклар иҗатында табигый бер күренеш буларак кабул ителә башлый, яхшылык һәм начарлык бәрелешен яктыртуда яңа чагылышлар табылуга китерә, шул рәвешле, ике дөнья – реаль һәм демоник дөньяны берләштерүче үзенчәлекле пространство хасил була» [9: 164]. Г. Ибраһимов иҗатында исә гайре табигый, «чит» пространство чаткылары шулай ук урын ала, әмма алар инферналь дөнья белән түгел, ә халык

мифологиясе, әкиятләре белән бәйләнештә хасил була. «Яз башы» хикәясендә ул елан, аждаһа, юха еланнар турындагы мифлар белән бәйлелектә хасил була һәм романтик герой күңеленә үтә көчле йогынты ясый. Аңын югалтыр дәрәҗәгә җиткән малай туган йортында, таныш пространствода тиз арада сихәтләнеп, яшәү көчен алып, көндәлек тормышын дәвам итә.

Г. Ибраһимовның «Яз башы» хикәясендә дә әкияти-мифологик пространство күренешләренә игътибар итик:

– Шуннан алып китә, китә, китә икән дә, ди, җиде диңгезне, җитмеш дәрьяны чыгып, Каф тауларына алып барып, гел еланнар, аждаһалар гына кайнап, ыжгырып ята торган бер төпсез мәмерҗәгә ташлыйдыр, ди [11: 125]

Аңлашылганча, биредә диңгез, дәрья пространстволары чит аралыкны белдерү өчен кулланылалар. Авторга аларны тасвирлау өчен эпитет, метафораларга мөрәҗәгать таләп ителми, ул моның өчен җиде (җитмеш) саннарын куллана. Барлык халыкларда да диярлек иң көчле символик саннарның берсе ул – җиде. Галимнәр аның тамыры **jet-di>jeti** (нәрсәгә дә булса ирешү, ахыргы нәтиҗә) дигән гомумтөрки сүз дип фаразлыйлар. Татар тел дөнья картинасында ул көчле сакраль семантикага ия. Иң элек борынгы бабаларыбызның дөнья төзелеше турындагы космологик күзаллауларын искә төшерик. Алар уйлавынча, фәрештәләр, рухлар яшәүче күк җиде каттан торган, шулай ук җир астын да җиде каттан тора дип уйлаганнар. Әкиятләрдә еш очрый торган «җиде диңгез арты», «җиде тау арты», кагыйдә буларак, чит территорияне белдерәләр. Романтик геройның дөнья картинасы әле тулысынча формалашып бетмәгән, ул әле нибары укучы бала, шуңа күрә мондый пространствоны ул, бер яктан, уйдырма дип кабул итәргә дә әзер, болар – күреп түгел, ишетеп белгән урын-аралыклар («бу чакта авылыбызның тәмле, килешле итеп әкият сөйләү белән даны чыккан Фәхринең сөйләгәннәре, иң элек ишетүем булганга, әле дә исемнән чыкмыйлар» [11: 125]), әмма бала күңеле аны чынбарлык итеп тә кабул итәргә әзер тора һәм хикәядәге вакыйгалар моны нәкъ раслыйлар да.

Г. Ибраһимов хикәяләрендә пространство элементлары метафорик мәгънәдә кулланылып, авторның дини-мифологик күзаллауларын, пространство архетибын аңлау үзенчәлекләрен ачыкларга ярдәм итә. Мәсәлән, түбәндәге очракта җәһәннәм чагыштыру нигезе ярдәмендә халкыбызның дини-мифологик пространствоны аңлавы чагылдырыла. Язучы «Табигать балалары» әсәрендә эссе җәй көнен җәһәннәм белән чагыштыра:

Көн кызганнан-кыза, җир, күк көйгәннән-көя бара, – әйтерсең, дөньяга *җәһәннәмнән бер тишек ачылган* да, безне шуның каршысына китереп куйганнар [4: 133].

Ислам мифологиясе буенча мәңгелек дөнья кеше өчен җәһәннәм һәм җәннәт дигән поляр пространство берәмлекләреннән тора. Алар газап / ләззәт бинарлыгы нигезендә бер-берсеннән кискен аерылып торалар, газап чыганагы буларак ут атала. Кызу җәй көнендә, өстәвенә ураза вакытында печән чабучы геройның кичерешләренең авырлыгы дәрәҗәсен ассызыклау өчен язучы җәһәннәм пространствосын метафора рәвешендә куллана.

Г. Ибраһимовның реализм методына нигезләнеп язылган әсәрләрендә авыл, шәһәр топослары аерым урын алып тора, алар романтик әсәрләрдән үзгә шәкелдә тасвирлана. Бу әсәрләргә дә мөрәҗәгать итү мөһим, чөнки әдип үзе: «Мин – реалист мөхәррир. Беренче әсәремнән хәзергәчә шул мәсләктә барам. Арада кайбер әсәрләремдә романтизм элементларының бераз куера төшкән урыннары булгалады (реакция чорында), ләкин боларда да төп мөндәриҗә нигез реализм иде», – дип яза [2: 27]. Әдипнең «Безнең көннәр», «Тирән тамырлар» әсәрләрендә сулык топослары метафорик-символик мәгънәләрдә килеп, авторның илкүләмендәге үзгәрешләргә мөнәсәбәтен ачыклыйлар. Г. Ибраһимов «Безнең көннәр» романының беренче битләрендә үк су, дулкын, диңгез образларына мөрәҗәгать итә. Игътибар итик: «Төн караңгы. Дөнья тын. Ләкин диңгез шаулый. Диңгез түбәндә кемгәдер ачу белә үкерә. Аның куәтле дулкыннары, тау-тау булып, биек, ташлы, текә ярларга һөҗүм итәләр. Күңелгә шом килә: гүя менә-менә тагын бер-ике аткырыргып атылачаклар да, дөньяны каплап китәчәкләр. Ләкин сезгә куркыныч юк. Дулкын ничаклы каты булса да, ул сезнең биек тау итәгендәге урыныгызга килеп җитә алмаячак. Сезгә тыныч булырга, тәрәзәләрегезне ачып, диңгез тавышын тыңларга да аннан соң рәхәт-рәхәт тагы йокыгызга чумарга мөмкин» [3: 9]. Г.Ф. Мөхәрләмова игътибар иткәнчә, «Тирән тамырлар» әсәрендә дә Идел елгасы ачык пространство хронотобы буларак кулланыла һәм символик мәгънәләр белән баетыла: аның иксез-чиксез киңлеге, тирәнлеге, мул сулы булуы, тизлеге, борылмалылыгы 20–30 нчы еллар ил, җәмгыять тормышына ишарә итә, аңа автор бәясен күрсәтә [8: 12].

Г. Ибраһимовның реалистик иҗатында пространство берелешендә романтик иҗатыннан кискен аерып торган як буларак ябык пространство хронотопларының актив кулланыла башлавын ассызыкларга кирәк. «Тирән тамырлар», «Безнең көннәр» кебек әсәрләрендә моңа мисал булып коммуна, колхоз, артель топослары, шулай ук төрмә топосларын атап була.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: Г. Ибраһимов әсәрләрендә пространство берелеше романтик әсәрләрдә диңгез, күл, тау, мәдрәсә / туган йорт топослары аша тәкъдим ителә. Экзотик топос (диңгез) геройның чынбарлыктан качу омтылышын ачыкларга

ярдәм итә, туган йорт һәм туган авыл топосы саф күңелле, самими романтик герой образын тулырак ачарга ярдәм итә. Романтик әсәрләрдә топослар әкияти-мифологик коннотацияләр белән баетыла. Әдипнең реализм юнәлешенә караган әсәрләрендә ачык пространство (диңгез, Идел) символик мәгънәләр белән баетыла. Реаль чынбарлык тасвирларын бирүдә нигездә ябык пространство топослары – колхоз, совхоз, төрмә һ.б. катнаша.


ӘДӘБИЯТ

1. Бахтин М.М. Формы времени и хронотопа в романе // Бахтин М. Литературно-критические статьи. – М.: Худ. лит-ра, 1986. – С. 234–407.

2. Галимуллин Ф. Табигыйлеккә хилафлык. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 304 б.

3. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр. – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – 612 б.

4. Ибраһимов Г. Хикәяләр, повесть, роман / төз. Р. Акъегет. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 463 б.

5. Ибраһимов Г. Әсәрләр. Академик басма. Унбиш томда. 5 т.: роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 423 б.

6. Лихачев Д.С. Поэтика художественного пространства // Поэтика древнерусской литературы. – М., 1979. – С. 235–351.

7. Минковский Г. Пространство и время // Принцип относительности: сб. работ по специальной теории относительности / сост. А.А. Тяпкин. – М.: Атомиздат, 1973. – С. 167–179.

8. Мухарлямова Г.Н. Художественное время и пространство в произведениях татарской прозы 20–30-х годов XX век: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2010. – 20 с.

9. Нечаева Е.А .Особенности инфернального топоса в произведениях Э.Т.А. Гофмана. – URL: https://cyberleninka.ru/article/n/osobennosti-infernalnogo-toposa-v-proizvedeniyah-e-t-a-gofmana/viewer; мөрәҗәгать итү вакыты: 15.03.2022.

10. Нуруллин И.З. XX йөз башы татар әдәбияты. урта мәктәп укытучылары, студентлар һәм югары класс укучылары өчен дәреслек-кулланма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – 286 с.

11. Татар хикәяләре. XX гасыр башы. – Казан: Мәгариф, 2007. – 399 б.

12. Шутая Н.К. Типология художественного времени и пространства в русском романе XVIII–XIX веков: автореф. дис. … д-ра филол. наук. – М., 2007. – 35 с.


УДК 398

# ФОЛЬКЛОР В ЛИТЕРАТУРОВЕДЧЕСКИХ ВЗГЛЯДАХ Г. ИБРАГИМОВА


***К.М. Миннуллин***

*ИЯЛИ им. Ибрагимова АН РТ (Казань)*


В статье рассмотрен вклад Г. Ибрагимова в формирование методологических основ татарской фольклористики. Исследованы его приоритеты относительно сбора, научного изучения и публикации фольклора. Обозначена его позиция в изучении фольклора с опорой на взаимосвязь последнего с историей этноса. Показан его вклад в классификацию татарского фольклора и новаторский подход к проблеме жанровой типологии. Он первым выдвинул идею о сильном влиянии общемусульманской

культуры на фольклор, когда чувство религии полностью победило чувство нации. Сделан вывод о том, что Г. Ибрагимов пришел к фольклору путем создания программы теоретических размышлений по истокам прекрасного в искусстве еще в самом начале своего творчества.
**Ключевые слова:** Г. Ибрагимов, фольклористика, жанровая типология, методология, татарский этнос, мусульманская культура, эстетическая программа.

The article considers the contribution of G. Ibragimov to the formation of the methodological foundations of Tatar folklore. His priorities regarding the collection, scientific study and publication of folklore are investigated. His position in the study of folklore based on the relationship of the latter with the history of the ethnic group is indicated. His contribution to the classification of Tatar folklore and an innovative approach to the problem of genre typology are shown. He was the first to put forward the idea of a strong influence of the general Muslim culture on folklore, when the feeling of religion completely won over the feeling of the nation. It is concluded that G. Ibragimov came to folklore by creating a program of theoretical reflections on the origins of beauty in art at the very beginning of his work.
**Key words:** G. Ibragimov, folklore, genre typology, methodology, Tatar ethnos, Muslim culture, aesthetic program.

Галимджан Гирфанович Ибрагимов (1887–1938) – общественный деятель и политик, организатор науки и ученый, писатель, литературовед и педагог… Формирование и развитие многих отраслей гуманитарных наук связаны с его именем. В их числе – и фольклористика.

Фольклористикой называется наука о народном творчестве, которая состоит из двух взаимосвязанных направлений: сбор, сохранение и популяризация произведений; их научное изучение и анализ. У татар первое направление берет начало с XVIII века, целенаправленная собирательская работа активизировалась во второй половине XIX и начале XX веков, когда на страницах многочисленных календарей, а затем – газет и журналов появилась мода на публикацию сказок, песен, легенд или загадок. Г. Ибрагимов стоял у истоков второго направления, способствовав формированию методологических основ татарской фольклористики.

Может быть, красивые места слияния рек Турсали и Аургази Башкортстана, певучий язык и протяжные песни, обычаи и обряды оставили в душе талантливого юноши свой след – с первых художественных произведений его стиль отличается богатством пейзажных и этнографических материалов. Уже в повести «Татар хатыны ниләр күрми» («Судьба татарки», 1909), обратившись к сюжету баита «Семь девиц», он словно стремится показать все богатство и красоту повседневной жизни татар и башкир – через обряды и обычаи, праздники (помочи, Сабантуй, посиделки, сва-

дебные обряды и др.). Эта манера проявилась и в рассказах (например, «Яз башы» («Начало весны», 1910)) писателя.

Параллельно Г. Ибрагимов одним из первых попытался определить основные задачи, направления татарской фольклористики в своем первом серьезном теоретическом исследовании – «Әдәбият мәсьәләләре» («Вопросы литературы», 1910). Труд состоит из трех глав, вторая из которых под названием «Халык мосаннәфаты» («Народная литература») посвящена вышеназванным вопросам. В самом начале дается определение устного народного творчества. «Халык арасында авыздан-авызга күчеп йөри торган, фәкать шул халыкның зиһенендә генә сакланып килгән вә чыгаручысы мәҗһүл булган, борынгы заманнан калма әсәрләрнең мәҗмугына халык мосаннәфаты дип исем биреләдер» [1: 42] («Собрание сочинений, распространенных среди народа и передающихся из уст в уста, сохранившихся только в памяти этого народа, а авторство их не известно, дошедшие до нас из древности, называется народное творчество»).

Сразу оговаривается – «Мәдәни милләтләр тарафыннан бу нәүгы әдәбиятка зур әһәмият биреләдер» [1: 43] («Высокоразвитые народы уделяют большое внимание этой разновидности литературы»), и указывается, что ученые специально собирают их, и публикуют, чтобы можно было использовать в образовательной и иной деятельности. К примеру приводится ситуация с русской фольклористикой, припоминаются изестные фольклористы, их труды, взгляды представителей мифологической, исторической школ и концепции заимствований. Ибрагимов находит следы фольклорных материалов в творчестве известных русских поэтов и писателей, упоминаются фамилии Пушкина, Кольцова, Некрасова, Достоевского, Толстого, Никитина.

Г. Ибрагимов заявляет о необходимости как сбора и публикации, так и научного изучения фольклора. Фольклор им воспринимается как неисчерпаемый источник народного языка и познания духовной жизни, психологии, менталитета, истории народа, и как важное средство обогащения художественной литературы элементами народной культуры, которое, в свою очередь, направлено на сближение интеллигенции и простых людей. Эти слова прозвучали в унисон с призывами многих других татарских исследователей-гуманитариев (А. Валиди, Х. Максудов, Х. Бигиев, Г. Рахим и др.) к выявлению, сбору, популяризации произведений фольклора.

Особенности татарского фольклора Г. Ибрагимов рассматривает в тесной взаимосвязи с историей этноса, выявляет некоторые особенности татарского фольклора. Им называются четыре жанра устного народного творчества: 1) сказки; 2) песни и баиты;

3) пословицы; 4) загадки. Это было одной из первых жанровых классификаций на основе наработок русской фольклористики. Вместе с тем, он пытается найти другие подходы к проблеме ранжирования: на примере сказок указывает, что есть сказки, дошедшие до нас с языческих времен, и сказки, связанные с исламом. Он был первым исследователем-фольклористом, который заметил в татарском фольклоре сильное влияние общемусульманской культуры: «дин хисе миллият хисен тәмам җиңгән») [1: 46] («чувство религии полностью победило чувство нации»).

Как видно, теоретические воззрения Г. Ибрагимова еще не имеют системно-завершенный характер. Но, видимо, желание их разработать не оставляет его: в книге по поэтике «Әдәбият дәресләре» («Уроки литературы», 1916) написанной в качестве учебного пособия для медресе, он сделал весьма успешную попытку найти методологическую основу для татарской фольклористики. Сегодня эту книгу можно рассматривать и как первый труд по поэтике фольклора. Она переиздается в 1918, 1919 годах под названием «Әдәбият кануннары» («Литературные каноны», 1916), на долгое время становится популярным учебником по литературоведению и фольклористике.

Книга состоит из трех глав. Первая – «Бәлягать вә вәзен – әсәрнең тел вә өслүбе хакындагы канун вә нәзарияләр» («Риторика и стихосложение – законы и правила о языке и стиле произведения») – задумана как теория стилистики и риторики. В ней автор пытается дать комплексный ответ на вопрос «Что есть художественное произведение?», объясняя про тему, проблематику, сюжет и композицию, стиль и звучание и т.д. Под шапкой «художественное произведение» рассматриваются и собственно-литературные, и фольклорные произведения. Единственно: автор разделяет их на поэтические и прозаические. Многочисленные определения, приводимые в книге, применительны как в отношении художественной, так и народной литературы. К примеру, термин «произведение» объясняется таким образом: «Билгеле бер әйбер хакында булган уй вә тойгыларны, шул әйбернең сурәтен хыялда җанландырырлык яки аның тугрысында бөтен бер аң вә тәэсир калдырырлык рәвештә сүз белән (язып яки сөйләп) ифадә кылу» [2: 130] («Письменное или устное повествование о мыслях и переживаниях об определенном явлении, об образе этого явления, чтобы оно пересоздавалось в наших представлениях, оставило свой след в нашем сознании»). Это определение, безусловно, подходит к произведениям и фольклора, и литературы. Практически все теоретические формулировки имеют такой характер.

Вторая глава («Шигъри әсәрләр, әдәбияты нәфисә хакында канун вә нәзарияләр» («Законы и правила о поэтических произведе-

ниях, о художественной литературе»)) полностью посвящена художественной литературе, которую Г. Ибрагимов разделяет на две части: народная литература; письменная литература. По мнению автора, и фольклор, и авторская литература состоят из трех видов: эпос, лирика и драма. Тем самым он ставит знак равенства между поэтикой фольклора и художественной литературы.

Так звучит определение фольклора: «Чыгаручысы билгеле булмаган, вакытында китапларга язылмаган, бәлки халык арасында буыннан-буынга сөйләү, балалар – атадан, аталар – бабадан ишетү юлы белән генә безгә ирешкән борынгы әсәрләрне халык әдәбияты дип атыйлар» [2: 170] («Народной литературой называют древние произведения, у которых автор неизвестен, они не закреплены в книгах, дошли до нас путем передачи от одного поколения к другому, путем услышания детей – от отца, отцов – от дедов»). Не останавливаясь в таком разъяснении, в 5-ом подразделе главы «Халык әдәбияты белән язма әдәбият арасында төп аермалар» («Отличительные особенности между народной литературой и письменной литературой»), он выделяет 5 характерных для народной литературы черт: фольклор не имеет автора и практически является результатом коллективного творчества; хранится в памяти народа и передается устно; произведения фольклора поэтичны, даже написанные прозой зачастую имеют ритм и рифму, красивое звучание; народная литература выражает мысли, чувства, переживания, взгляды на мир целого народа; фольклор является первоисточником художественной литературы.

Еще один, 6-й подраздел посвящен определению ценности фольклора. По мнению Г. Ибрагимова, народная литература является хранителем чистоты родного языка; и свидетелем менталитета, образа жизни, этнического духа: «Бик мәшһүр сүз: халык әдәбияты – халык рухының сихерле көзгесе. Халык ни уйлый, дөньяга ничек карый? Моны аңлау өчен, безгә иң дөрес юл – халык әдәбиятын тикшерүдер. Чөнки халыкның йөрәгендәге кайгысы, шатлыгы, тәҗрибә белән туган яхшы хикмәтле уйлары, аның хыялына азык булган сурәтләр, аңа кызыклы күренгән вакыйгалар, аның уены, көлкесе, гомумән, бөтен җан вә йөрәк хәяты шул җырлар, мәкальләр, бәет вә әкиятләр аркылы әйтелә килгән» [2: 173] («Известны слова: народная литература – волшебное зеркало народного духа. Этнос о чем думает, как смотрит на мир? Чтобы понять это, самый краткий путь – изучение народной литературы. Потому как горе или радость в сердце народа, рожденные опытом мудрые думы, ставшие пищей для фантазии картины, кажущиеся ему интересными события, его игры, смех, вообще вся жизнь сердца и духа, передавались через эти песни, пословицы, баиты и сказки»).

В книге Г. Ибрагимов еще раз возвращается к проблеме жанровой типологии. И в этом вопросе его представления стали цельными и системными. Он выделяет 7 жанров татарского фольклора [2: 173]: 1) баиты; 2) песни; 3) сказки; 4) пословицы; 5) загадки; 6) частушки; 7) прибаутки. Каждому из них дается определение, выделяются особенности, генезис, приводятся примеры. Г. Ибрагимов затрагивает жанровые формы, упоминает собирателей тех или иных жанров из татар. Таким образом, вторая глава практически охватывает все вопросы теории фольклора.

Третья глава («Мәнсүр әсәрләр хакындагы канун вә нәзарияләр» («Законы и правила о прозаических произведениях»)) рассказывает об эпических произведениях, внутри которых Г. Ибрагимов рассматривает и научную, общественно-политическую, критическую литературу; описания, прежде всего, путешествий; рассказы о прошлом (история, автобиография, воспоминания); и даже тексты проповеднического, назидательного характера.

В свою очередь, по мере возможности упоминаются и комментируются многие жанровые разновидности, функционирующие в татарской культуре. Г. Ибрагимов пытается дать конкретное определение, приводит примеры из мировой, русской и татарской литературы или фольклора.

Таким образом, Г. Ибрагимов является автором первого теоретического труда, разъясняющего основы изучения татарского фольклора по образцу художественной литературы. Его вклад в становление и развитие теоретической фольклористики неоспорим.

Научные проблемы фольклористики не потеряли значимость для него и после революции 1917 года. В опубликованном в феврале 1922 года обзоре «Татар әдәбияты (Хисап урынында)» («Татарская литература (Вместо отчета)») Г. Ибрагимов начинает разговор с голода в Поволжье, подробно объясняет ситуацию со школьными учебниками и пособиями, рассказывает о новых художественных, научных, исторических, политических произведениях. В 5-ой главе писатель затрагивает вопрос сбора и изучения произведений устного народного творчества: «Халык әдәбиятыннан безнең матбугатта тик Хуҗа Бәдигыйнең әсәрләре бар. Әкиятләр исә һич тә җыелмаган иде. Менә бу юлда да Гата Исхакый иптәшнең («Әдәбият юллары» мөхәррире) мөһим бер хезмәте бар: ул садә, саф, матур көенчә, нәкъ халыкның үз телендә сөйләнгәнчә, 500 биттән артык әкият җыйган. Болар Татар Җөмһүриятенең Дәүләт нәшрияты кулында. Бүлеп-бүлеп бастырылачаклар» [3: 75] («Из фольклора, в нашем издательстве публикуются только труды Ходжи Бадиги. Сказки пока были не собраны. И вот на этом поприще появился труд товарища Гаты Исхаки (автора «Әдәбият юллары»):

он собрал рассказанных чистым красивым языком, по-народному, сказок на 500 страниц. Они находятся в Государственном издательстве Республики Татарстан. Частями будут опубликованы»). Таким образом, писатель еще раз напоминает об актуальности исследования вопросов фольклористики.

В том же году в статье «Вакытсыз һәлак булды» («Погиб безвременно», 1922), посвященной Ш. Бабичу, Г. Ибрагимов с восхищением отмечает вклад поэта в сбор образцов фольклора. Он указывает, что Бабичем собрано более 200 страниц народных песен, сказок, быличек, и называет их «источниками таланта поэта» («...болар Бабичның нинди азыклар белән сугарылуын күрсәтәләр» [3: 86].

В предисловии к драме М. Файзи «Галиябану» («Галиябану» хакында бер-ике сүз» («Несколько слов о «Галиябану», 1922)) как новое достойное похвалы явление, привнесенное в татарскую драматургию этой пьесой, указывается этнографизм: «Беренче мәртәбә диярлек һичбер буяусыз, саф булганча, үзләренең уен-көлкеләре, җырлары, музыкалары, гыйшыклары, интригалары, бәетләре, көрәшләре белән крәстиян егетләре, крәстиян кызлары бу әсәр аркылы безнең театр галәменә килеп керәләр» [3: 107] («Практически впервые крестьянские юноши и девушки вошли в театральный мир вместе со своими играми, песнями, музыкой, влюбленностями, интригами, баитами, борьбой, такими как есть, без дополнительных красок». Там же отмечено, что этнографический материал в этом произведении играет полноправную роль в передаче содержания, органично вплетаясь в ткань пьесы.

Тот факт, что теоретические взгляды Г. Ибрагимова относительно поэтики фольклора не претерпели изменений, прослеживается в статье «Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы» («Метод марксизма в изучении истории общественных, литературных движений», 1922). В ней он разделяет историю татарской литературы на три этапа: средневековья («Борынгы-кадим Шәрык дәвере»); период национального возрождения («Яңару, яурупалашу дәвере», со второй половины XIX века); классовой борьбы («Сыйнфый көрәшләр аша икътисади азатлыкка ирешү дәвере»). Писатель рассматривает народную литературу как одно из направлений средневековой татарской литературы: «Бу дәвердә халыкка җан азыгы булган кыйммәтле әдәби җәүһәрләр (...) халык әдәбиятыдыр» [3: 121] («В этот период духовной пищей народу служили драгоценные жемчужины (...) устного творчества»).

В объемной статье, посвященной 100-летию Каюма Насыри «Каюм бабаның йөз еллыгы» («К 100-летию Каюма-баба», 1920)

Г. Ибрагимов пытается оценить роль просветителя в изучении и возвращении народу произведений фольклора. Им отдается должное заслугам Насыри в области собирания и изучения народной литературы – первооткрывателя на пути создания татарской фольклористики как науки, «первого реформатора из татар» («татарның беренче реформаторы») [3: 249].

Программной для фольклористики стала статья «Тел-әдәбият мәсьәләләренең кирәкле бер тармагы (Татар халык әдәбияты турында)» («О важной отрасли языка-литературы (О народной литературе татар)», 1926). Тезисообразно Ибрагимов заявляет о нескольких перспективных проблемах по изучению фольклора.

1. Использовать язык народной литературы для формирования лексической базы, терминологии татарского языка (это была новая установка в татарском языкознании).

2. Необходимость не только сбора, но и научного изучения фольклора: «Таки таркау материаллар бергә җыелсын, мәсьәләгә гыйльми анализ ясалсын да мәгълүм бер система буенча дөньяга чыга алсын» [3: 261] («Пусть разрозненные материалы собираются воедино, выполняется научный анализ и они представляются миру в соответствии с известной системой»).

3. Сбор фольклора не только казанских татар, но и всех групп этноса, а также – с целью сравнения, родственных тюркских народов (упоминаются ногайцы и башкиры, а также казахи). По мнению Ибрагимова, фольклор различных субэтнических групп татарского народа станет опорой в изучении языка различных диалектов.

Резюмируя сказанное, Г. Ибрагимов ставит четыре задачи, которые им рассматриваются как этапы развития единой науки – фольклористики: «1) халык авызыннан җыю; 2) төрле вакытта җыелып та басылмый ятканнарны, басылып, таркау хәлдә торганнарны бергә туплау; 3) һәммәсен гыйльми метод белән тикшереп, системага салу; 4) аннан соң тәртипләп бастырып чыгару» [3: 263] («1) собирать из уст народа; 2) объединить все материалы, собранные в разное время, но не изданные; или изданные, но малоизвестные; 3) исследовать их научным методом и систематизировать; 4) издать в определенном порядке».

В заключении хочется привести слова доктора филологических наук А.Х. Садековой, в трудах которой были изучены и некоторые взгляды писателя относительно фольклористики, и фольклоризмы в его творчестве: «Ибрагимов пришел к фольклору осознанно, путем теоретических размышлений, на основе четкой программы, созданной им в самом начале своего творчества. В основу его эстетики легло положение о том, что прекрасное в искусстве создается обращением к самим истокам – к народно-

му творчеству» [4: 68]. Наши дальнейшие изыскания подтверждают это.


ЛИТЕРАТУРА

1. Ибраhимов Г. Әсәрләр: Унбиш томда. 6 т.: Әдәбият hәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1914). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – 327 б.

2. Ибраhимов Г. Әсәрләр: Унбиш томда. 7 т.: Әдәбият hәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1915–1916). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – 375 б.

3. Ибраhимов Г. Әсәрләр: Унбиш томда. 8 т.: Әдәбият hәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1918–1933). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – 431 б.

4. Садекова А.Х. Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова // В мире творчества Галимджана Ибрагимова. – Казан: ИЯЛИ АН РТ, 2012. – С. 9–102.



УДК 82


## ИЗУЧЕНИЕ ТВОРЧЕСКОГО НАСЛЕДИЯ Г. ИБРАГИМОВА В НАЧАЛЕ XXI ВЕКА


***А.Р. Мотигуллина***

*Поволжский государственный университет физической культуры, спорта и туризма (Казань)*



В данной статье деятельность и творческое наследие Г. Ибрагимова исследуется через призму теоретической и научно-методологической монографии Э.Р. Галиевой «Культурно-историческая школа в татарском литературоведении» (2002). В ней творческое наследие литературоведа и критика Г. Ибрагимова рассматривается с одной стороны, как исследователя идей культурно-исторической школы. С другой стороны, автор монографии анализирует эстетические взгляды Г. Ибрагимова, опираясь на труды и статьи современников писателя Г. Саади и Г. Нигмати. В целом, Э.Р. Галиевой дана научно-обоснованная методология анализа творческой и научно-исследовательской деятельности Г. Ибрагимова.



**Ключевые слова:** культурно-историческая школа, творческий метод, методология анализа, творчество писателя, роман, критика.



In this article, the activities and creative heritage of G. Ibragimov are examined through the prism of the theoretical and scientific-methodological monograph by E.R. Galiyeva «Cultural and historical school in Tatar literary criticism» (2002). In it, the creative heritage of the literary critic and critic G. Ibragimov is considered on the one hand, as a researcher of the ideas of the cultural-historical school. On the other hand, the author of the monograph analyzes the aesthetic views of G. Ibragimov, relying on the works and articles of the writer's contemporaries G. Saadi and G. Nigmati. In general, E.R. Galiyeva was given a scientifically based methodology for analyzing the creative and research activities of G. Ibragimov.



**Key words:** cultural-historical school, creative method, analysis methodology, writer's work, novel, criticism.

# XXI ГАСЫР БАШЫНДА ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ИҖАТ МИРАСЫН ӨЙРӘНҮ

***Ә.Р. Мотыйгуллина***
*Идел буе дәүләт физик тәрбия, спорт һәм туризм университеты (Казан)*

Галимҗан Ибраһимов төрле чорларда тикшеренүчеләрнең игътибарын җәлеп итеп торган әдип. Без XX гасыр башы әдибе дип атарга күнеккән Г. Ибраһимов XXI гасыр башында дөнья күргән фәнни хезмәтләрнең дә тикшеренү объекты булып тора. Бу юнәлештә төп игътибар иткән хезмәт авторы филология фәннәре докторы Э.Р. Галиеваның «Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе» монографиясендә Г. Ибраһимов иҗатын, эшчәнлеген, әдәби-теоретик ачыш-табышларын өйрәнү булып тора.

Тикшеренүче Э.Р. Галиева Г. Ибраһимов иҗатын культура-тарих мәктәбе кысаларында язылган хезмәтнең өйрәнү объекты итеп карый. «Татар галимнәре Г. Сәгъди, Җ. Вәлиди, Г. Рәхим, Г. Гобәйдуллин культура системалары эчендә функциональ пландагы бәйләнешләргә игътибар бирделәр. Әдәбиятны тел, тарих, театр, музыка, мәгариф, дин һ.б. культура күренешләре белән функциональ бәйләнешләрендә яктыртуны алга куйдылар», – дип ассызыклап уза галимә. Шунда ук 1920 нче еллар казанышы буларак Г. Ибраһимов һәм Г. Нигъмәтинең «язучы иҗатын аны билгеләүче төрле сәбәпләр бәйләнешендә, теге яки бу әдәби күренешне барлыкка китерүдә катнашкан факторлар системасында» өйрәнүләрен дә билгеләп үтеп, әлеге фикерләрнең татар әдәбияты барышын өйрәнүгә ясаган йогынтысын да дәлилләп бара.

Монографик тикшеренүдә Г. Ибраһимов эшчәнлеге ике юнәлештә карала: беренчедән, аның культура-тарих мәктәбе идеяләрен эшләүче тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме буларак. Бу нисбәттән Э.Р. Галиева Г. Ибраһимовның Октябрь инкыйлабына кадәр язылган мәкаләләрен һәм хезмәтләрен өйрәнеп, аларны билгеле системага салу барышында «Европа һәм рус культура-тарих мәктәбе теоретиклары И. Тэн, Александр Н. Веселовский, Д.Н. Овсянико-Куликовский һәм башкаларның» фикеренә таянуына игътибар итә. Әлеге хезмәт кысаларында әдипнең тәнкыйди һәм әдәби осталыгын югары бәяли.

Икенчедән, шул ук хезмәттә Г. Ибраһимов иҗатының эстетик ягын өйрәнүгә дә басым ясап узыла. Аерым алганда, галимә Э.Р. Галиева «Язучы иҗатын тикшерү методикасы» өлешендә Г. Нигъмәти һәм Г. Сәгьдинең тәнкыйди мирасында татар язучыларның иҗатын аерым бер әсәрне анализлау яки иҗат ысулларын бәяләү ягыннан өйрәнүгә тукталып уза.

Бу өлештә Г. Ибраһимов иҗатын төрле яклап өйрәнүче галим буларак Г. Сәгъдинең ачыш-табышлары барлана. Аерым алганда, галимә Г. Сәгъдинең «Галимҗан Ибраһимов һәм аның әдәби иҗатлары» (1928), «Галимҗан Ибраһимов иҗатында типлар эволюциясе» (1928), Г. Нигъмәтинең «Г. Ибраһимов һәм аның әдәби иҗаты» (1932) мәкаләләренә таянып, Г. Ибраһимов иҗатын монографик планда тикшерү методикасының үрнәген тәкъдим итә [1: 181].

Хезмәттә Г. Сәгъдинең дүрт бүлектән торган «Галимҗан Ибраһимов» дигән җыентыкка кергән «Галимҗан Ибраһимов һәм аның әдәби иҗатлары» дигән мәкаләсе аерып карала. Аның кысаларында Г. Ибраһимовның иҗатын чорларга бүлү мәсьәләсе хәл ителүен дә дәлилләп, Г. Сәгъдинең иҗатны өч чорга бүлүе ассызыклана: беренче чор – 1907–1910 нчы еллар, икенче чор – 1910–1916 нчы еллар һәм өченче чор – Февраль, Октябрь революциясеннән соңгы заман», – дип бүлеп чыгаруга игътибар итүен күрсәтә [1: 182].

Тикшеренүче Э.Р. Галиева Г. Сәгъди хезмәтендә авторның типлар тудыру осталыгын ачу юлларын тәфсилләп өйрәнә. Беренче төр типларга Зәки шәкерт («Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы»), Сәлим һәм Җәлилне («Яшьләр хәятеннән бер ләүхә»), икенче типка ул Нури бай, Зариф бай, Гөлбануларны («Татар хатыны ниләр күрми?») кертүен дәлилләп күрсәтә. Шунда ук Э.Р. Галиева галимнең әдәби барышны тирән аңлавын, язучы иҗатының башлангыч чорында «мәгърифәтчелек реализмы, романтизм, натурализм элементлары катнашмаларыннан гыйбарәт булуын төшенде», – дип күрсәтә [1: 183]. Хезмәт кысаларында Г. Сәгъди фикерләренә бәя берьяклы гына булмавына игътибар итәбез. Тикшеренүченең Г. Ибраһимов иҗатын тирән белүенә, татар әдәбияты белеме өлкәсендәге эрудициясенә, гыйльми-теоретик белеменә таянып Г. Сәгъдинең романтизмга «икеле мөнәсәбәттә торуын» дәлилләргә омтылып, «Г. Ибраһимовта «реализмның киресе булган романтизм ягына тайпылу хәрәкәте булып алды», – диелә. Шунда ук Эльмира Рәкыйповна Г. Сәгъдинең «әдәбияттагы романтизм фәлсәфәсендәге идеализм чишмәсенең сәнгатьчә бормаланып, шаулап аккан киң бер ермагы» [4: 203], – дип белдерүенә нигезләнеп, дәвам итә: «Г. Сәгъдинең методологик хатасы романтизмны философик агым белән тәңгәлләштереп каравында, алар арасында бернинди дә аерманы күрмәвендә булуын дәлилли. Мондый методологик ялгыш, ягъни реализмны – материализм, романтизмны – идеализм белән тәңгәлләштереп карау – совет чоры әдәбияты белемендә 50 нче елларда калкып чыккан иде» [1: 184]. Ләкин шунда ук фикерен дәвам итеп, Э.Р. Галиева Г. Ибраһимов иҗатындагы романтизм

иҗат методы турында сүз барганда Г. Сәгъдинең «объективлык позициясендә кала алуын», «татар әдәбиятында романтизм (милли хис) барлыгын таныды», – дип, ассызыклап уза [1: 185].

Тикшеренүче Э.Р. Галиева Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романының романтизм иҗат ысулы белән язылган булуын дәлилләү максатыннан тагын да Г. Сәгъдинең әсәрдәге психологизмның тирән булуына басым ясавын билгеләп үтә. Бу нисбәттән галимнең әдип романындагы «эчке рухи дулкыннарны оста тасвир итүе белән соклануын да» күрсәтә.

Әлеге хезмәттә күренекле галим Г. Нигъмәтинең дә Г. Ибраһимов иҗатына биргән бәясе белән танышып узабыз. Э.Р. Галиева Г. Нигъмәтинең «Г. Ибраһимов һәм аның әдәби иҗат юлы» мәкаләсендә әдипнең ике күләмле романын – «Яшь йөрәкләр» һәм «Безнең көннәр»нең беренче вариантын анализлавын өйрәнә. Галимнең Г. Ибраһимов иҗатындагы романтизга мөнәсәбәтен дә аерып күрсәтә: «Ул, Г. Ибраһимов иҗатын тикшерүчеләр арасында беренчеләрдән булып, язучы иҗатынагы романтизмның аерым билгеләрен, күренешләрен, сыйфатларын бердәмлектә, үзара бәйләнештә, системада карау юлы белән барды, боларны әдипнең романтизм концепциясеннән чыга торган, аның романтизм белән бәйле күренешләр булуына әһәмият бирде» [1: 193].

Гәрчә Г. Нигъмәти һәм Г. Сәгъди тарафыннан язылган мәкаләләрдә Г. Ибраһимов иҗаты төрле яссылыкларда анализланса да, бер яктан, икесе арасында фикер тәңгәллеген күреп бетермәсәк тә, Э.Р. Галиева аларның мәкаләләрендә аерым язучы иҗатының төп фикри баганаларның утыртылуына игътибар итә. Галимә Г. Сәгъдинең «Галимҗан Ибраһимов һәм аның әдәби иҗаты» Г. Ибраһимов иҗат табышларын өйрәнүгә багышланган мәкаләсенең дүртенче өлешен анализлау барышында аерым игътибарны әдип иҗатындагы психологизмны аерып алып бәяләвен ассызыклап уза. Шунда Г. Сәгъди күрсәткән Г. Ибраһимов иҗатындагы психологизмының унлап хосусиятенә туктала: «1) әдипнең вакыйгаларга тиз керүе; 2) Г. Ибраһимов әсәрләренең халык мәкальләре белән бәйләнешле булган фәлсәфи төшенчәләрне үз эченә алуы, аларда халык әкиятләре, халык легендаларының урын алуы; 3) мәхәббәт кичерешләрен сурәтләү нечкәлеге; 4) әсәрләренең тирән лиризм белән сугарылган булуы; 5) күп типларның рухи-психологик планда бирелүе; 6) геройның сөйләм үзенчәлегенең аның характерына туры китереп бирелүе; 7) Г. Ибраһимовның төрле әсәрләрендә аерым геройларның, аерым типларның эволюциясе күрсәтелүе; 8) авторның контраст типларны капма-каршы куеп күрсәтә белү осталыгы; 9) типларның дедукция методы белән бирелүе; 10) геройның рухи хәлләрен табигать күренешләренә

мөнәсәбәтле рәвештә сурәтләү; 11) «әсәрләренең күбесендә табигать хәдисәләреннән берәр төрле охшату алу белән башлануы» [1: 188–189]. Күреп үткәнебезчә, Г. Ибраһимов иҗатында психологизм билгеләре эзләгән Г. Сәгъдинең ачыш-табышларын, фәннитеоретик карашларын соңгы елларда киң таралган психологизм теориясе белән чагыштырып карау мөмкинлеге дә туды. Психологизм мәсьәләләрен тикшерүдә әдәбият белеме фәнендә соңгы табыш, ачышларны рус нәзариячесе А.Б. Есин хезмәтләрендә очратабыз [1]. Гәрчә, Э. Галиева хезмәтендә Г. Ибраһимов психологизмы соңгы еллар ачыш-табышлары белән чагыштырып карал-маса да, без А.Б. Есин фикерләре белән тәңләштерүне урынлы күрдек. Рус галиме психологик сурәтләүнең төп өч формасын бүлеп чыгара: 1) суммар-белдерүче (суммарно-обозначающая), 2) туры (прямая), 3) читләтелгән (косвенная). Беренче очракта эчке дөнья хәлләре бары аталалар гына, икенчесендә – җентекләп тасвирлана, өченчесендә сурәтләү үз-үзеңне тоту билгеләрен тасвирлау аша тормышка ашырыла [1: 298–299].

А.Б. Есин хезмәтендәге бүленешнең икенче һәм өченчесе Г. Ибраһимов тарафыннан тасвирланганнарга тәңгәл килә. Әдипнең характерлар һәм типлар тудыру үзенчәлекләрен Г. Сәгъди билгеләп үткәнчә, «галим әдип мирасының гомумкешелек кыйммәтенә ия булуын билгеләп үтте, аның фикеренчә, «татарның мәдәни хәрәкәте, мәдәни үсеше бөтен кешелек әдәбиятының кечкенә булса да бер ботагы» буларак күрсәтелә.

Шул рәвешле, тикшеренүче Э.Р. Галиева үзенең «Татар әдәбияты белемендә культура-тарих мәктәбе» монографик хезмәтендә Г. Ибраһимов иҗат табышларын өйрәнү барышанда әдәбият галимнәре Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти биргән бәяне җентекләп өйрәнә. Галимнәрнең карашларын бүгенге көн әдәби-мәдәни барыш белән белән чагыштырып, әдәби әсәрләрне заманча анализлау методикасы казанышлары яктылыгында бәяләп бара.

ӘДӘБИЯТ

1. Есин А.Б. Принципы и приемы анализа литературного произведения. – М.: Флинта, 2000. – 248 с.

**2.** Галиева Э.Р. Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе. – Казан: «Фән» нәшр., 2002. – 360 б.

3. Ибраһимов Г. Татар әдәбиятын өйрәнү юлында // Әсәрләр: 8 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – Т. 5. – Б. 379–391.

4. Сәгъди Г. Татар әдәбияты тарихы. – Казан: Татарстан дәүләт нәшр., 1926.

УДК: 792.03.

# СОВРЕМЕННЫЕ ИНТЕРПРЕТАЦИИ ХУДОЖЕСТВЕННЫХ ПРОИЗВЕДЕНИЙ Г. ИБРАГИМОВА НА ТАТАРСКОЙ СЦЕНЕ

***А.Р. Салихова***

*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

Галимджан Ибрагимов сыграл заметную роль в татарской культуре, его богатое творческое наследие до сих пор востребовано и вызывает большой интерес. Особого внимания заслуживает бытование его литературных произведений в сценическом искусстве. В статье рассматриваются современные интерпретации художественных произведений Г. Ибрагимова на татарской сцене. Постановки 2021 года отличаются свежестью прочтения, яркой художественной образностью, эмоциональностью. То, что мысли, чувства и образы писателя остаются интересными и сегодняшнему зрителю, свидетельствует о важности, оригинальности и художественных достоинствах повестей и рассказов Г. Ибрагимова.

**Ключевые слова:** Г. Ибрагимов, татарский театр, спектакль, инсценировка, режиссер.

Galimzhan Ibragimov played a significant role in Tatar culture, his rich creative heritage is still in demand and is of great interest. The existence of his literary works in theatrical art deserves special attention. The article deals with modern interpretations of works of art by G. Ibragimov on the Tatar stage. The productions of 2021 are notable for their freshness of reading, vivid artistic imagery, and emotionality. The fact that the writer's thoughts, feelings and images remain interesting to today's viewer testifies to the importance, originality and artistic merit of G. Ibragimov's stories.

**Key words:** G. Ibragimov, Tatar theatre, performance, staging, director.

Творческая деятельность Г. Ибрагимова была удивительно многогранной. Публицист, ученый-востоковед, лингвист и литературовед, автор и составитель многочисленных учебников, редактор, педагог, общественный деятель… Г. Ибрагимов сочетал в себе качества талантливого художника слова, ученого-теоретика и блестящего организатора-практика. Литературное наследие Г. Ибрагимова необычайно богато. За сравнительно короткий период жизни им созданы десятки рассказов, 3 повести, 4 романа, одна из первых революционных пьес. Кроме того, Ибрагимовым опубликовано 12 научных книг по истории революционного движения, теории и истории литературы, эстетике и лингвистике, около 350 теоретических, критических и публицистических статей, более 10 учебников по языку и литературе. Личность Г. Ибрагимова вызывает к себе неугасающий интерес. Большая работа проводится по собиранию, изучению и изданию творческого наследия писателя. Важным событием стало издание академического собра-

ния сочинений Г. Ибрагимова в пятнадцати томах. Это наиболее полное издание литературного наследия Ибрагимова на татарском языке, в него наряду с художественными произведениями вошли критические работы и статьи, публицистика, труды по истории и филологии, а также письма и воспоминания. Регулярно проходят научные конференции, посвященные различным аспектам жизни и творчества писателя. Но, помимо научного исследования, большое значение имеет и художественное осмысление его произведений, их живое непосредственное бытование в современном культурном пространстве, актуальные трактовки и интерпретации.

Новую жизнь его литературным произведениям дарит сценическое искусство. В 1920 году Г. Ибрагимов написал драму «Новые люди», которая по новому осветила некоторые темы и стала определенной вехой в истории татарской драматургии. По словам А. Ахмадуллина: «Среди первых пьес, посвященных революционной тематике, драма «Новые люди» отличается сложной проблематикой» [1: 139].

Уже в шестидесятые годы театральное искусство обратилось к прозе Г. Ибрагимова. В 1960 году артист Татарского государственного академического театра Х.Ю. Салимжанов перевёл его повесть «Судьба татарки» на сценический язык, написав драму в трёх действиях. «Творчество Г. Ибрагимова привлекло инсценировщика своей художественно-смысловой всесторонностью, остротой социально-этической проблематики, своеобразными чертами театральности» [5: 118]. Также ярким событием стала постановка театром имени Г. Камала спектакля «Глубокие корни» по одноимённому роману Г. Ибрагимова в1969 году.

То, что в советское время произведения Г. Ибрагимова с их социальной тематикой и классовым подходом были востребованы, неудивительно. Примечательно, что и в наши дни интерес к ним по-прежнему высок. 27 марта 2022 года состоялось вручение республиканской театральной премии «Тантана». Высокую оценку экспертного совета получили спектакли, созданные молодыми талантливыми татарскими режиссерами по произведениям Г. Ибрагимова.

Атнинский татарский государственный драматический театр им. Г. Тукая представил постановку по рассказу «Алмачуар», премьера которой состоялась 26 июня 2021 года. Трогательная история крестьянского мальчика и выращенного им жеребенка была опубликована в 1922 году и сразу завоевала любовь читателей. Реалистичная и эмоциональная, она поднимает волнующую и актуальную тему любви и дружбы, нравственного взросления человека через горести и потери. Имеющая большое воспитательное значение, она также интересна и взрослому читателю, так как бередит чувства и поднимает серьезные проблемы доброты и ответственности.

Режиссер и автор инсценировки Айдар Заббаров подчеркнул поэтичность рассказа, создав оригинальное сценическое пространство. В самом начале спектакля зрителя встречает дурманящий запах свежескошенной травы, покрывающей плотным слоем поднятую вверх платформу, на которой (и за которой) разворачивается действие. Возникает убедительная иллюзия раздольной и волнистой башкирской степи: на первом плане на платформе, словно на вершине холма, играют актеры, а скрытно от глаз, словно в низине, поднимая пыль, несутся на бешеной скорости лошади, радостно разбрызгивая воды холодной реки, купаются мальчишки. Невидимые нам события, благодаря разбуженному зрительскому воображению, предстают весьма убедительно, даже ярче, чем можно было бы показать.

Саму историю актеры играют вполне традиционно. Актер Марат Хабибуллин от лица своего героя – состарившегося Закира ведет неспешное повествование о делах давно минувших дней. Авторский текст сохранен практически полностью, и все перипетии сюжета с их бытовыми подробностями, характерными приметами дореволюционной жизни, психологическими переживаниями плавно проходят перед зрителем. Все это аккуратно проиллюстрировано актерской игрой. Иногда складывается впечатление, что основная задача авторов спектакля – ознакомление подростков с произведением из школьной программы (что, безусловно, важно). Самую оригинальную и трогательную роль в спектакле – жеребенка Алмачуар исполнила молодая актриса Алина Сидеева. Очень нежно и пластично она сумела показать его хрупкость, наивность, доверчивость и уязвимость. Тем самым подчеркнув основную идею рассказа – призыв к бережному отношению ко всему живому, невосполнимость душевных потерь и неоправданность жертв, которые люди зачастую приносят в угоду своему тщеславию и амбициям. Следует отметить также талантливую работу хореографа Александра Николаева и художника по свету Ольги Окуловой.

«Алмачуар» Атнинского татарского государственного драматического театра им. Г. Тукая – достаточно легкий спектакль для семейного просмотра, он пробуждает теплые чувства, оставляет светлое впечатление. Совсем иначе обстоит дело со спектаклем «Адәмнәр» («Люди») театра кукол «Экият», который рассказывает о страшном голоде, свирепствовавшем в Поволжье в 1921–1922 годах и глубоко потрясает трагизмом и безысходностью.

Повесть «Люди», опубликованная в 1923 г. вызвала в свое время большой резонанс и множество негативных откликов. Большинство современных Г. Ибрагимову литературоведов, считавших, что литература должна изображать только красоту, изящество, раскритиковало его за темные, горестные описания, невзрачные натуралистические краски [2: 911]. Писателя обвиняли

в том, что он «очерняет советскую действительность». Возможно, именно за это он в дальнейшем и поплатился свободой и жизнью.

Режиссер и автор инсценировки Ильгиз Зайниев сумел точно и выразительно передать суть страшной в своей натуралистичности повести Галимджана Ибрагимова художественными средствами искусства театра кукол. В этом спектакле большое внимание уделено живому плану (то есть такому плану, где внимание сосредоточено на исполнителях, а не на куклах). На сцене всего два актера. Главный герой – плотник Гарай в исполнении заслуженного артиста Татарстана, многократного лауреата премии «Тантана» Дилюса Хузяхметова. Шаг за шагом прослеживается этапы его духовной деградации под влиянием нечеловеческих мук голода. Игра актера подробна и реалистична, пронизана глубоким драматизмом. Вторая исполнительница – Альбина Шагалиева создает символический образ материализованного Голода. «Игра этой актрисы – настоящее потрясение. Сгусток энергии, выплеск эмоций, взрыв потаённого темперамента – всё это и многое, многое другое заключено в лукавом прищуре её глаз, саркастической улыбке, вкрадчивых обертонах голоса» [3]. Вместе с тем, она, мгновенно перевоплощаясь, оживляет своим искусством многочисленных кукол – персонажей повести Г. Ибрагимова. В руках актрисы обретают живую душу и неповторимую индивидуальность умирающая от голода жена Гарая, его сын Зайни и дочь Нафиса, деревенские жители, люди и собаки…

Сами куклы весьма необычны и выразительны. Круглые, словно опухшие от голода, животы (у некоторых – с зияющими дырами вместо животов), грязные серые отрепья, стертые лица-картошки, тонкие руки, заканчивающиеся деревянными ложками – все это воздействует на зрителя даже просто на физическом уровне. Вместе с тем, такое решение подчеркивает хрупкость, беззащитность людей перед голодом, наводит мысль на художественные и философские обобщения. «Идея сделать куклы в виде картошки пришла во время работы над спектаклем. Старый, сморщенный корнеплод напоминает лицо старика, – раскрывает секреты художник-постановщик спектакля Сергей Рябинин. – Если куклу делать один в один похожую на живого человека, то рядом с актером она не выиграет. Артист тоже тогда будет смотреться нелепо. Из всех эпизодов я бы отметил очень трогательный момент, когда кукла протягивает актеру ложку, обгрызенную, обкусанную, напоминающую человека. Это точное попадание в образ голодного человека» [4].

Под стать куклам и сценография. «Раздвигается занавес, и мы оказываемся в странном пространстве – дощатом коробе, заполненном снегом. В центре стоит прямоугольный ящик с глухой крышкой – по-видимому, ларь для муки. И вместо неба – дощатый навес.

Сценография Сергея Рябина удивительно проста и строга. И это настраивает зрителя на нужную тональность восприятия всего происходящего. Придерживаясь принципа, что на театральной сцене не должно быть лишнего, художник-постановщик спектакля выстраивает не просто фон, а создаёт пространство как предмет сугубо утилитарный, и актёры могут использовать его как хотят. Этот прямоугольный ящик с глухой крышкой – и дом главного героя, и его постель, и внешний уличный атрибут, и «ящик Пандоры», из которого по миру разлетелись все несчастья и бедствия, на дне, под захлопнутой крышкой, осталась лишь надежда» [3]. Особенная роль в создании атмосферы отведена музыке спектакля. Ориентируясь на минимализм сценографии и смысл спектакля – исследование нравственных переоценок, композитор Эльмир Низамов воссоздаёт в звуках и рушащиеся железные принципы, и надрывный плач сердца, и вселенскую скорбь, и масштаб происходящего [3].

Спектакль «Адәмнәр» в постановке Ильгиза Зайниева получил высокую оценку критиков. Он номинирован на Российскую национальную театральную премию «Золотая маска 2022» в пяти номинациях: «Лучший спектакль в театре кукол»; «Лучшая работа режиссера» – Ильгиз Зайниев; «Лучшая работа художника» – Сергей Рябинин; «Лучшая работа актера» – Дилюс Хузяхметов; «Лучшая работа актера» – Альбина Шагалиева. При этом нужно отметить, что спектакль «Адәмнәр» целиком и полностью – продукт Татарского государственного театра кукол «Экият». Как сказал сам режиссер, они смогли выпустить его без помощи со стороны, без приглашенных специалистов. Это подтверждает высокий уровень театра и мастерство его коллектива.

Таким образом, литературное наследие Г. Ибрагимова и сегодня востребовано. Оно служит источником вдохновения и дает материал для создания серьезных и глубоких произведений сценического искусства.

ЛИТЕРАТУРА

Ахмадуллин А. Татарская драматургия: история и проблемы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2012.

Ахметова М.А. Тема голода в повести Г. Ибрагимова «Адәмнәр» («Люди»): критическая и литературоведческая рефлексия // Вестник удмуртского университета. Серия история и филология. 2020. – Т. 30, вып. 5. – С. 909–917.

Бельцев Зиновий. «Люди» в кукольном театре: восхождение к катарсису. Казанский репортер 27 июня 2021. URL: https://kazanreporter.ru/post/4604_ludi-v-kukolnom-teatre-voshozdenie-k-katarsisu [дата обращения: 25.03.2022].

Исаева Лика. «Он видел еду в собственных детях»: в Казани состоялась премьера спектакля о голоде. В главных ролях – люди и куклы. Пруфы. Свободная медиа платформа. 24 июня 2021. URL: https://kazan.prufy.ru/news/kazan_society/108535-on-videl-edu-v-sobstvennykh-detyakh-v-kazani-sostoyalas-premera-spektaklya-o-golode/[дата обращения: 25.03.2022].

Фардеева Д.Р. Национальная проза на сцене татарского государственного академического театра имени Г. Камала / Д.Р. Фардеева. – Казань: ИЯЛИ, 2014.

УДК 82.091

# ОСОБЕННОСТИ ИЛЛЮСТРАЦИИ НАТУРАЛИЗМА В ПОВЕСТИ Г. ИБРАГИМОВА «ЛЮДИ»

***З.Г. Саляхова***

*Учитель татарского языка и литературы гимназии №10 (Казань)*

Повесть «Люди» Галимджана Ибрагимова – произведение натуралистическое, в основе которого лежит биофизиологический детерминизм. Ужасные страдания от голода превращают человека в зверя, приводят к утрате им человеческого достоинства, что писатель и иллюстрирует на примере трагедии семьи бывшего крестьянина-середняка, деревенского плотника Гарая.

Одно из самых сильных натуралистических описаний в повести «Люди» – собирательный образ смерти. Жертвы голода изображены автором в пугающих биофизиологических подробностях.

**Ключевые слова:** натуралистические описание, биологические и физиологические качества человека, эстетика натурализма, биологический детерминизм, теория натурализма.

The story «People» by Galimjan Ibragimov is a naturalistic work based on biophysiological determinism. Terrible suffering from hunger turns a person into a beast, leads to the loss of human dignity, which the writer illustrates by the example of the tragedy of the family of a former peasant-middle peasant, village carpenter Garai.

One of the strongest naturalistic descriptions in the story «People» is the collective image of death. The victims of hunger are depicted by the author in frightening biophysiological details.

**Key words:** naturalistic description, biological and physiological qualities of a person, aesthetics of naturalism, biological determinism, theory of naturalism.

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «АДӘМНӘР» ПОВЕСТЕНДА НАТУРАЛИЗМНЫҢ ГӘҮДӘЛӘНҮ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

***З.Г. Сәлахова***

*10 нчы гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучысы (Казан)*

Г. Ибраһимов «Адәмнәр» повестенда, 1921 нче ел ачлык трагедиясен үтемле итеп күз алдына китерү өчен, бик еш натуралистик алымнарга мөрәҗәгать итә. Әсәрнең башында ук чынбарлыкны укучыга түкми-чәчми дистәләгән детальләрдә җиткерү омтылышы белән очрашабыз. Ул мондый юллар белән башланып, укучыны дәһшәтле вакыйгалар эченә алып кереп китә: « Үлем үзенең кара канатларын җәйде. Җир йөзе гүя, шуның астында капланып калды. Тирә-як куркыныч караңгы каберлекләр, ләхетләр белән, бер үлгәч терелеп чыккан җанлы мәетләр белән тулды» [6: 3].

«Адәмнәр» повесте үзенең фаҗигале асылы һәм дәһшәтле чынбарлыкны булганынча, гадел тасвирлавы белән дә үзенчәлекле.

Әсәрдәге һәр герой иң элек газапланучы, җәфа чигүче ачлык корбаны буларак күз алдына килеп баса. Җан өшетерлек күренешләр әсәр сюжетында кино тасмасындагы кебек алмашынып тора. Беренче абзацтан соң әдип укучыны Галим карт янына алып килә һәм хиссез, кыска җөмләләр ярдәмендә аның белән таныштыра. Үз героена игътибар итмәгән кебек тоелса да, автор төрле эпизод, фрагментларны бер-бер артлы тезә дә, шуларны бик оста итеп монтажлап, натурадан фотога төшереп алган шикелле, ачлык елларының киң панорамасын күз алдына китереп бастыра. Әсәрне уку барышында татар халкы башыннан кичкән куркыныч реаль вакыйгалар, кино лентасындагы сыман, бер-бер артлы күздән кичерә барыла.

Әсәрнең беренче битеннән үк кешенең биологик хайвани табигатен, физик халәтен тасвирлаган, авыр, дәһшәтле картинаның эченә кереп китәбез. Түбәндәге өзек шуны расласа кирәк: «Мәгәр ул бераз гына кичеккән иде инде: бик зур бер карт ала эт үлекнең эчен актарып, эчәген, бавырын ашап ята!!» [6: 4]. Бу юллар коточыргыч вәхшилекне тулылыгы белән күзалдына китереп бастыра. Автор хакыйкый дөньяны, чынбарлыкны, әйтерсең лә, бер үзгәрешсез әсәр тукымасына күчереп утырткан.

Тормыш дөреслеген мөмкин кадәр тулырак бирү максатын күздә тотып, Г. Ибраһимов әсәрдә геройларның портретын, кием – салымын җентекләп сурәтләүгә, натуралистик детальләрне сайлауга күп игътибар бирә. Бу очракта ул, тәнкыйтьчеләр язганча, натуралист язучыларга хас сыйфатларның берсе: «...Натуралист не критикует, не отрицает, а ... отвратительное эстетизирует...» [2: 130], дигән кагыйдәгә турылыклы булып кала.

Әсәрдә кеше тормышы һәм психологиясе турыдан-туры биологик һәм физиологик сыйфатлары белән ялангачландырып күрсәтелә. Повестьта геройларга артык зур характеристика бирелми, төп игътибар ачлык аркасында килеп туган, алар белән булган хәлләргә юнәлтелә.

Бүгенге көн галимнәре натурализм теориясенең нигезендә О. Конт позитивизмы һәм И. Тэнның сәнгать һәм әдәбият турындагы карашларын гына түгел, ә билгеле бер күләмдә һәм дәрәҗәдә нечкә һәм катлаулы күренеш булган – пантеизмны да күрәләр. Шуңа да натуралистик стилистикага үлем, череп таркалу, ягъни яшәешнең тәмамлануын күрсәтү мотивлары да күпмедер дәрәҗәдә хас дип саныйлар. Әлеге күренеш натурализмны әдәбиятта декадентлык алымы белән дә якынайта. Г. Ибраһимов та укучыга тагын да үтемлерәк, көчлерәк тәэсир итү чарасы буларак, ачлыкның кешеләргә китергән һәлакәтен натурализмның шушы сыйфаты аша җиткерә.

«Монда үзенә бер дөнья – караңгы, куркыныч үлем дөньясы иде: келәтнең ишеген ачуга бөтенләй ялангач бер хатын белән бер зур, киң, ак сакаллы картның гәүдәсе ята. Киемнәре юк, өсләрен-

дәге капчык бер яккарак төшкән. Каралып, күгәренгән коточкыч тәнләре кабер җәфасын күрсәтәләр. Болардан арырак аяк-куллары төрле якка таралган, биш-алты яшь баланың үләксәсе бер-berенә ябышып туңып катканлар. Балаларның гәүдәләрен башына мендәр кебек ясап сөялгән бер карчык, бик артык шешенгән тәне белән тау кебек өелеп сузылып төшкән. Ул, беренче каруда тере кебек күренә, чәчләре тузып җилкәсенә салынган, авызы елмайган рәвештә ачык, сирәк сары тешләре бер-берenә кысылганнар, пыяла күзләре ишекдән керүчегә, гүя шелтә белән, үпкәле ачу белән карап торалар…» [6: 8].

Әсәрдәге натуралистик ысул белән җентекләп язылган бу тасвирны уку җиңел түгел. Алар күңелдә бик тә авыр тәэсир калдыралар. Әсәрнең бу ягына ачлык вакыйгалары белән таныш тәнкыйтьчеләр дә игътибар итми калмый. Күренекле галим Гали Халит: «Бу әсәрдә Г. Ибраһимов осталыгына хас көчле генә сурәтләр, укучының йөрәген тетрәтерлек психологик элементлар байтак. Ләкин алынган теманың гомуми рухы чыгышсыз трагизм, куе бер вәхшәт караңгылыгы, гадәттән тыш авыр вакыйгаларны натуралистик чагылдыру белән сугарылган» [8: 324], ди. «Адәмнәр» повестьтендагы үзәк урынны кеше һәм җәмгыять, аларның үзара мөнәсәбәте мәсьәләсе алып тора. Натуралистлар, гомумән, кешенең социаль мохиткә бәйле булуына басым ясарга яраталар. Шуңа да алар әдәби әсәрне «кешелек документы» буларак кабул итеп, көнкүрешне тулы итеп тасвирлау, кеше психикасының физиологик нигезләрен тәфсилле итеп күрсәтү белән мавыгалар.

Г. Ибраһимов та повестьта кеше яшәгән әйләнә-тирәлекне натуралистларча гәүдәләндерә. Әдипнең һәр җөмләсе укучыны фаҗигале вакыйгалар һәм халәтләр чолганышына алып кереп китә. Повестьның башыннан ахырына кадәр кан, дәһшәт, җан өшеткеч сурәтләр, куркыныч детальләр, коточыргыч тасвирларның ургылышы бара.

Г. Ибраһимов «Адәмнәр» повестенда натуралистларга хас булганча, көнкүреш өчен характерлы булган вак-төякләрне, башка язучылар әсәрдә күрсәтергә ярамый дип санаган яшерен якларны бик төгәл итеп, тормыштагыча һәрдаим фотога төшереп алып бара. Ләкин кайбер тәнкыйтьчеләр натурализм эстетикасына бәя биргәндә, ялангач фактография белән чын сәнгать әсәренең бурычлары бервакытта да туры килә алмый, тормыш ваклыкларыннан торган «фотографик сурәтләр чүп-чары»н әдәби әсәрләрдә теркәү кешене усал, явыз, намуссыз итеп сурәтләргә генә мөмкинлек бирә, дип исбатларга тырышалар.

Чынбарлыкны объектив гәүдәләндерү һәм тасвирлау өчен автор җентекләп бирелгән натуралистик деталь һәм тасвирлардан, риторик алымнардан ирекле файдалана. Повестьта язучы фикере

гомумидән конкретлыкка таба хәрәкәт итә. Бу исә үз чиратында укучыга конкрет бер шәхес белән танышырга һәм ачлыкның тетрәндергеч картиналарын калку итеп күз алдына китереп бастырырга мөмкинлек тудыра. Әсәрдә кеше тормышы турыдан-туры аның биологик сыйфатлары һәм тирәлек белән бергә үреп бирелә. Ачлык нәтиҗәсендә кешеләр үзләренең кешелек сыйфатларын югалту дәрәҗәсенә кадәр барып җиткәннәр. Г. Ибраһимов Зәбидә карчыкның казаныннан алып ташланган кып-кызыл ит кисәкләренә ачларның ни рәвешле ябырылуын түбәндәгечә тасвирлый: «Бер читтәрәк торган хәлсез ике егет уртага ташландылар, этме, баламы ите икәнен уйламастан сәкедә пычракта яткан эссе кисәкләрне хапхоп йота башладылар. Башкалар казанны актарып калган итне алдылар, кемгә күпме нәрсә эләксә, бер минут эчендә юк кылдылар. Гәрәйнең кулына кечкенә, нәзек, аз итле бер сөяк туры килгән иде.

– Карагыз, бармак бит бу ?! – дип каты кычкырып җибәрде……» [6: 13].

Әлеге юлларны укыганда чәчләр үрә тора. Әдип ачлыкның кешеләр психикасына коточкыч тәэсир итүен натуралистик алымнар белән сурәтләгәндә Аллаһы тәгалә яраткан кеше дигән олы зат читтә калып, ул бары тупас физиологизм – корсак фәлсәфәсе, аш казанын нәрсә белән булса да тутыру ягыннан гына сурәтләнә. Мондый натуралистик тасвирларны биргәндә әхлак, кешелеклелек кануннары онытыла, А. Красносельский әйткәнчә, «…стремление к беспристрастности в описании « голой правды» неизбежно приводит натуралистов к равнодушию в вопросах морали, безразличному отношению к проявлениям добра и зла» [3: 80].

Г. Ибраһимов ачлык вакыйгалары кешенең физик халәтенә генә түгел, ә аның психологиясенә дә тискәре йогынты ясавын күрсәтә. Кешеләр үзләренең кылган гамәлләре өчен җавап бирә алмаслык дәрәҗәгә җитәләр, кешелек сыйфатларын югалталар. Бу хакта язучы, тарихчы Г. Гобәйдуллинның да «Вестник научного общества Татароведения» журналының 1925 нче ел 1–2 санында әсәргә карата әйткән фикере гыйбрәтле: «“Адәмнәр”дә татар авыл тормышы фонында ачлык сәбәбеннән туган кеше ашаучылык психологиясенең эволюциясе тасвирланды. Биредә материалист автор ачлыкны сурәтләп һәм урта кул крестьянның иң нормаль психикасына коточкыч тәэсир итүен күрсәтеп, җинаятьнең экономикага багълы булуын ачып бирде» [4: 66].

Чыннан да, Г. Гобәйдуллинның фикерләре белән килешми мөмкин түгел. Ибраһимов повестьта бер татар авылында барган ачлык вакыйгаларын гына түгел, ә гомумкешелек мәсьәләләрен күтәрә. Шушы авыл мисалында ачлыкның татар халкына алып килгән коточкыч газапларын ача. Кешелектән, ачлык нәтиҗәсендә, ерткычлыкка бару юлын тасвирлый. Әлеге юлның һәр адымын

натуралистик юл белән укучы йөрәгенә үтеп керерлек итеп сурәтли. Авторның һәр җөмләсе куркыныч картиналардан, дәһшәтле тасвирлардан тора. Повестьны укыган саен бөтен җаныңны шом баса. Әхмәт Сәхапов әйткәнчә: «“Адәмнәр” повесте, чыннан да, җан өшетерлек образлары, натуралитстик картиналары, дәһшәтле фактографик эпизодлары һәм йөрәк яргыч психологик нюанслары белән тетрәндерә» [7: 325].

Г. Ибраһимов кебек оста каләм иясе генә натуралистик сурәтләү аша чынбарлыкның тере картинасын тудырып, бу вакыйгаларны үзәк өзгеч итеп әйтеп бирә ала. Әлеге коточкыч күренешләрне натуралистик юл белән тасвирлау, минемчә, һич тә урынсыз түгел.

Алга таба «Адәмнәр» поэмасына күз салсак, ачлыкның кеше психикасына тәэсир итү көче тагы да ачыла. Повестьтагы һәр җөмлә акрынлап ачлык дәһшәтен арттыра бара. «Бу икесенең авызборыннары изелде; идәндә тапталып аяк астында изелгән кызыл иттән башка нәрсә калмады» [6: 14], дигән юллар, бер яктан, ачлыкның кеше аңына ни дәрәҗәдә тәэсир итүен ачып бирсә, икенче яктан, Г. Ибраһимовның бу әсәрендә натуралистик тенденциянең бик көчле булуын күрсәтә.

Кыскасы, әдип татар авылы тормышы мисалында ачлык сәбәбеннән туган кеше ашаучылык психологиясенең эволюциясен, кешелектән ерткычлыкка таба адым ясавын шулай ачык итеп тасвирлый.

Ф. Бәширов та әсәргә карата: «Коточкыч ачыгу нәтиҗәсендә акылдан шашарлык булган, кеше ите ашауга кадәр барып җиткән адәмнәрнең кылганнары кырыс, хәтта әйтергә кирәк, фактографик, натуралистик тәфсиллек белән сурәтләнгән» [1: 5], – дигән фикерне әйтә. Әйе, Ф. Бәширов хаклы. Ул вакыйгалар күңелдә авыр, гаять авыр тәэсир калдыралар. Повестьның бер генә җөмләсен дә тетрәнмичә уку мөмкин түгел. Язучы крестьян тормышының шундый күңелсез якларын, татар халкының фаҗигале үткәнен ачып, мөгаен, укучының күңелен йомшартырга, аны уйландырырга телидер. Әсәрдә кешеләрне чолгап алган тирәлек тә караңгы, кызганыч итеп сурәтләнгән. Шул тирәлектә яшәүче геройларның да дөньяда гамьнәре, нинди дер хыяллары, теләк-омтылышлары юк. Араларында аерылып торган образлар да юк, бөтенесен дә ачлык берләштерә. Ачларның кылган эш-гамәлләре дә бары тик ризык табу белән генә бәйле. Шушы ачлык хәлләрен Г. Ибраһимов Гәрәй гаиләсе мисалында гәүдәләндерә. Әнә шул бер гаилә аша авыр трагедияләрнең дәһшәтле күренешләрен укучыга җиткезә. Бу гаиләдәге һәрбер кешегә аерым-аерым тукталып, ачлыкның коточкыч фаҗигасен ачып бирә. Җентекләп аларның тормышын, ачлыкның һәрбер көнен ничек үткәрүләрен, гадәтләрен, кием-салымнарын яза.

Повестьта Артур Шопенгауэрның кеше табигатенә хас вәхшилек турындагы: «В глубине своего существа человек – животное

дикое и жестокое. Человек единственное животное, способное истязать других ради самой цели...» [5: 150], – дигән фикерләре үзәк мотивны тәшкил итә. Г. Ибраһимов әсәрдә билгеле бер ситуациядә кешенең йомылып яткан кыргый инстинктлары уянып баш калкытуын һәм аның куркыныч ерткычка әйләнүен ышандырырлык итеп тасвирлый. Повестьның «Адәмнәр» дип аталуы ук, биредә сүзнең кешеләр турында түгел, ә алардан түбәнрәк баскычта торучы җан ияләренең яшәеше, ягъни немец философы әйткәнчә, тереклек итү өчен өзлексез көрәше турында барачагына ишарә ясый. Әсәрне уку барышында, әлеге адәми затларның кешеләргә хас булмаган гамәлләр кылып, иң зур ерткычка әверелә баруларына инанасың. Әдип кеше дигән олуг затның куллары дөньяда матурлык тудыру, изгелекләр кылу белән бергә, үз баласының гомерен дә чикләүгә сәләтле икәнлеген күңелнең иң нечкә кылларан тетрәндерерлек итеп ача.

Әсәрдә чынбарлык бернинди бизәкләрсез «ялангач» килеш бирелгәнгә күрә, укучы күңеленә гаҗәп дәрәҗәдә көчле тәэсир итә. Укучы бу әсәр аша дистә еллардан соң да тарихи дөреслекне белә ала. Шуңа да повестьны Ә. Сәхапов «татар милләтен инкыйраздан коткарырга булышкан милли әсәр», – дип атый. Аныңча, «Кеше ашау дәрәҗәсенә кадәр җиткән адәмнәр турындагы бу дәһшәтле әсәре белән Г. Ибраһимов татар халкының киләчәк язмышы өчен Гаяз Исхакый кебек зур борчылу һәм тирән хәсрәтләнү белдерә». Ә. Сәхапов «Адәмнәр»не, бер яктан, «үзенең фаҗигале асылы, публицистик пафосы һәм дәһшәтле чынбарлыкны булганынча, гадел тасвирлавы белән Г. Исхакыйның «Дулкын эчендә» драмасының трагик лейтмотивын дәвам иттерә» дисә, икенче яктан, «Адәмнәр»не Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәре белән чагыштырып, «Повестьларның һәрберсе милләтне инкыйраздан саклап калу рухы белән сугарылганнар. Һәр повестьның лейтмотивы нигезендә кисәтү, искәртү, уяу булырга чакыру, мондый аяныч хәлләр белән авыр фаҗигане булдырмас өчен көрәшкә өндәү рухы ята» [7: 327], – дигән фикер әйтә. Чыннан да, бөек әдип милләт җанлы шәхес булган. Ул халкы кичергән авыр язмышны күреп, бөтен күңеле белән сыкранган. Шул тирән борчылулар аны «Адәмнәр» әсәрен язарга этәргән. Татар халкының тарихы киләчәктә бозып күрсәтеләчәген сизенгәндәй, әдип әсәре аша тарихи дөреслекне дә язып калдырырга омтылган.

Г. Ибраһимов «Адәмнәр» повестенда көнкүрештәге һәр детальне җентекләп язып, геройларның үз-үзләрен тотышын, кылган эш-гамәлләрен биологик детерминизм аша сурәтләп, һәр эпизодны натурада бирергә тырыша. Әдип тормыштан «җанлы кисәкләрне» алып ачлыкның коточкыч фаҗигасен, кешеләргә тәэсир итү көчен, натуралистик буяулар белән тетрәндергеч итеп ачып бирә. Бу дәһшәтле вакыйгаларның тере картинасын тудыра. Повестьтагы

һәр вакыйга куркыныч күренешләр җыелмасыннан гыйбарәт, һәр җөмлә натуралистик буяуларга мул манылган йөрәк яргыч психологик нюанслардан, гадәттән тыш хәл-әхвәлләрдән тора. Шуңа да Г. Ибраһимов әлеге әсәрен классик натурализм үрнәгендә иҗат итә.

«Адәмнәр» повестен укып чыкканнан соң шундый нәтиҗәләргә киләбез. Беренчедән, Идел буендагы ачлык табигать китергән бәла-каза гына түгел. Аның тамырлары тирәнгә, большевикларның властька мәҗбүри рәвештә килеп, халыктан көчләп, соңгы бөртек икмәген дә кырып-себереп җыеп алып, аны ач калдырган продразверстка кебек мәгънәсез эш алымнарына, ягъни сәясәткә барып тоташа.

Г. Ибраһимов совет хөкүмәтенең әлеге кара җинаятен яшереп калдыра алмады, аның татар халкына алып килгән җан тетрәткеч газапларын «Адәмнәр» повесте аша киләчәк буынга язып калдырды. Икенчедән, натурализм турында язган галимнәрнең хезмәтләренә таянып, Г. Ибраһимов «Адәмнәр» дә натурализмның натурализм – биологизм яки натурализм – физиологизм төрен файдаланган дип, әйтә алабыз.

ӘДӘБИЯТ


1. Бәширов Ф. Ачыла тарих битләре… // Мирас. – 1997. – № 3. – Б. 5–7.
2. Буров А.И. Марксистко-ленинская эстетика против натурализма в искусстве // Вопросы философии. – 1950. – № 1. – С. 117–138.
3. Вильчинский В.П. Русская критика 1880-х годов в борьбе с натурализмом // Русская литература. – 1974. – № 4. – С. 78–89.
4. Гобәйдуллин Г. Новые произведения Галимджана Ибрагимова // Вестник научного общества Татароведения. – 1925. – № 1–2. – С. 66–67.
5. Джованни Реале и Дарио Антисери. Западная философия от истоков до наших дней. – Т. 4. – СПб.: ТОО ТК «Петрополис», 1997. – С. 150.
6. Ибраһимов Г. Адәмнәр. – Казан: Татарстан матбугат һәм нәшрият комбинаты нәшере, 1923. – 25 б.
7. Сәхапов Ә. Исхакый һәм XX гасыр татар әдәбияты. – Казан: Мирас. – 1997. – 325 б.
8. Халит Г. Татар совет әдәбияты тарихы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – 324 б.


УДК 821.512.145

## ОТРАЖЕНИЕ ДЕТСКОЙ ПСИХОЛОГИИ В РАССКАЗЕ Г. ИБРАГИМОВА «ЯЗ БАШЫ»


***С.Г. Самитова***

*Казанский научно-исследовательский технологический университет (Казань)*



В нашей работе мы впервые в татарской гуманитаристике предпринимаем попытку рецепции одного из наиболее известных рассказов Г. Ибрагимова «Яз башы» («Начало весны») с позиций академической

психологии и психоанализа. Традиционное литературоведческое восприятие названного произведения сквозь призму канонов просветительского реализма раскрывает глубины детской психики. В ходе предпринятого исследования нами была выявлена перспективность трактовки фольклорно-мифологических образов рассказа с точки зрения аналитической психологии.
**Ключевые слова:** татарская литература, Г. Ибрагимов, психологизм, архетипы, мифические образы.

In our work, for the first time in Tatar humanities, we attempt to receive one of the most famous stories of G. Ibragimov «Yaz Bashi» («The Beginning of Spring») from the standpoint of academic psychology and psychoanalysis. The traditional literary perception of this work through the prism of the canons of educational realism reveals the depths of the child's psyche. In the course of our research, we have identified the prospects of interpreting folklore and mythological images of the story from the point of view of analytical psychology.
**Key words:** Tatar literary , G. Ibragimov, psychologism, archetypes, mythical images.

## Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «ЯЗ БАШЫ» ХИКӘЯСЕНДӘ БАЛА ПСИХОЛОГИЯСЕ ЧАГЫЛЫШЫ

***С.Г. Сәмитова***
*Казан фәнни-тикшеренү технология университеты (Казан)*

Танылган татар язучысы Г. Ибраһимов иҗатында балалар психологиясен тирән чагылдырган әсәрләр бик күп. Шулар арасында «Яз башы» (1911) хикәясе үзенчәлекле урында тора. Язучы әлеге әсәрендә көндәлек тормыш вакыйларын мифологик ышанулар һәм фантазия аша яктыртып, үсмер баланың эчке дөньясын, хистойгыларын ачып бирә. Бала психологиясен тасвирлаганда мифологик мотивларга мөрәҗәгать итү әдәбиятта билгеле алым.

Совет чорында хикәя нигездә мәгърифәтчелек реализмы кысаларында, кадими мәктәп-мәдрәсәләрдә белем бирү дәрәҗәсенең түбән булуы һәм яшь буынны дини хорафатларга нигезләнеп тәрбияләү, әсәрдә кулланылган мифологик персонажларның әдәби-эстетик кыйммәте кебек проблемалар яссылыгында өйрәнелә [3: 4].

Г. Ибраһимов иҗатында күтәрелгән психологик проблемалар, шул чор кешеләренең психологик портреты әлегә кадәр аз өйрәнелгән. Теманың актуальлеге шуның белән аңлатыла да.

Бу мәкаләдә Г. Ибраһимовның «Яз башы» хикәясендәге мифологик персонажлар тикшерелә, аларның функцияләрен психоанализ күзлегеннән ачарга омтылыш ясала, әсәрнең төп герое унбер яшьлек Салихның балачагы психологик һәм фәлсәфи яктан анализлана. Хикәядә бер ел дәвамында мәдрәсәдә укып, җәйге ял-

ларга авылга әти-әнисе янына кайткан 11 яшьлек Салих турыда сүз бара. Көндәлеген әнисенә күрсәтеп, аларның мактау сүзләрен ишеткән бала дуслары белән уйнарга чыгып китә. Авыл балалары авылдан читтәрәк урнашкан күлгә балык тотарга китәләр. Балык тоту барышындагы кызу бәхәсләр, ярышлар, уеннар, кызыклы экиятләр – барысы да хикәянең идея-проблемасын ачуга хезмәт итәләр. Хикәя нибарысы геройның бер көнен генә тасвилауга карамастан, автор әсәрдә кулланган символлар аша бик тирән мәгънә бирә алган.

Хәзер хикәядә сурәтләнгән күренешләрне психологик һәм фәлсәфи яктан анлатырга тырышырбыз. Хикәя шәкертнең әнисе белән очрашып, аңа шәһадәтнамәсен күрсәтү эпизоды белән башлана. Әнисенең билгеләре белән танышу барышында, үсмернең кичерешләре, дулкынлануы тасвирлана. Салих шатлык катыш канәгатьләнү хисләрен яшерә алмый: «Эчемнән бер нәрсә, бер көчле ялкын кайнап бугазыма, битемә таба килә. Әни моны белде ахры. Арык, талган кулларының, аркамнан сөеп, җылы вә мәхәббәтле кочакка алганын, нәкъ йөрәгенең өстенә кысылганымны әле дә бик ачык хәтерлим.Тавышы чыгыш вә һәрбер хәрефе эчке бер теләк, мәхәббәт вә изге уй белән тулган... . Шул сүзләрдән соң әнинең күземнән, маңгаемнан үбүен кабергә кергәнче оныта алмаслык бер тойгы белән каршы алганымны хәзер дә исемдә саклыйм... [2: 32]. Китерелгән өзектә Салих күнеле аша үткән хис-кичерешләр ташкынын күрәбез. Беренче карашка яшүсмер малайның ел дәвамында туган йортыннан читтә булу сәбәпле туган сагыну хисләре сурәтләнә сыман, Г. Ибраһимовның образларын шәрехләгәндә психологик алымнардан иркен файдалана белү сәләтен исәпкә алсак, язучы әйтергә теләгән фикернең тирәндәрәк булуына төшенербез. Г. Ибраһимов сурәтләгән хисләрне ачыклау өчен, психологиягә нигезләнгән теорияләргә мөрәҗәгать итү кирәк. Өзекне Австрия психологлары Зигмунд Фрейд (1856–1939) һәм Карл Густав Юнгның (1875–1961) җәмәгатьчелеккә «беренчел чын мәхәббәтне балалар капма-каршы җенестә булган ата-анага карата хис итүләре хакындагы» теориясе аша анализларга мөмкин. Алар әлеге теорияне XIX йөз ахыры һәм XX йөз башында тәкъдим итәләр. Ул чорда бу теориянең татар теленә тәрҗемә ителмәве мәгълүм, аның әле рус теленә тәрҗемә ителүе дә икеле. Хикәя белән танышкач, бөтен халыклар өчен уртак булган универсаль фикер булганмы, әллә язучы халыкның гасырлар дәвамында туплап килгән белемнәрен кулланганмы дигән сорау туа. Танылган әдәбият белгече Дания Заһидуллина бу чор татар әдәбияты үсеше хакында әйткән фикерләрнең хаклыгына тагын да ныграк ышанасың: «Татар әдәбиятына модернизм Европа һәм рус әдәбиятларындагы яңа агымнар тәэсирендә үтеп керә. Ләкин милли үзенчәлекләргә дә ия булган бу юнәлеш

аерым бер концепцияләргә йөз тота, әдәбиятчылар һәм язучылар татар әдәбияты үсешенә тәэсир итәрлек дип саналган фәлсәфи-эстетик өйрәнүләргә игътибар бирәләр. Чөнки мәдәни мәйданда модернизм белән кызыксыну XX йөз башынды, төгәлрәк әйтсәк, 10 нчы еллар тирәсендә калкып чыга. Бу вакыт – татар дөньясын үзгәртү омтылышының җәмгыятьтәге төрле өлкәләрне: икътисад, белем бирү, сәясәт, әдәбият, журналистика, фән юнәлешләрен колачлап алган чагы [1: 16].

Хикәядән күренгәнчә, Салих әнисенә карата беренчел сөю хисләрен кичерә, әнисенең сүзләреннән яшерен мәгънә эзли, кагылулары-үбүеннән ниндидер назлылык тоя, шунлыктан үзе дә аңламаган тойгылар эчендә кала һәм бу хисләрне «мәңге онытмам» яки «кабергә кергәнче оныта алмаслык тойгы» кебек сүзләр белән аңлата. Психологлар бу чорда балага аеруча игътибарлы булуны сорыйлар: капма-каршы җенестәге ата-ана белән бала мөнәсәбәтенең дөрес яки дөрес булмавыннан, кешенең шәхес буларак җитешүе; балигъ булгач, капма-каршы җенес вәкилләре белән аралаша белүе, гаилә кору һәм гаиләдә җылы атмосфера тудыра алуы формалаша. Ата-ана гаиләдә балалары белән тиешле мөнәсәбәт урнаштыра алмаган очракта төрле психологик проблемалар туарга мөмкин. Шулардан Эдип (З. Фрейд, 1897) һәм Электра (К.Г. Юнг, 1913) комплексларын атарга мөмкин [5: 5]. Бу теорияләрне аңлатуда Аурупа галимнәренең нигездә антик мифологиягә мөрәҗәгать итүе, әдипнең Салихның калебен ачуда кулланган мифологик образлардан файдалануы, аның чын психолог булып җитешүен исбатлый, тик бер «тайпылыш» белән, Г. Ибраһимовның героена инде 11 яшь. Шунысы кызык: хикәядә Ата образы бөтенләй телгә алынмый. Атаның гаиләдә булмавы, үз чиратында, ир бала тәрбиясендәге тайпылышларны ачыкларга ярдәм итә, алда әйтелгән Эдип комлексы турындагы фикерләрне тагын да ныгыта.

Салихның эмоциональ халәтен язучы берничә вакыйга аша чагылдыра. Менә ул үзенең дуслары белән очраша. Шактый вакыт аралашмый тору аркасында булса кирәк, авыл малайлары башта читтәрәк йөриләр, Салихны күзәтәләр, тикшерәләр. Малайлар дусларының элеккеге кебек гади булуын аңлагач, акрынлап аралаша башлыйлар һәм соңрак бөтенләй дуслашып, күлгә юл тоталар. Бу эпизодны тасвирлаганда да, әдипнең бала холкын яхшы аңлавы күренә.

Менә малайлар инде күл буенда. Көннең кояшлы булуы да балалар психологиясен ачуга хезмәт итә. Төрле ярышлар, кызыклы уеннар һәм дә әби-бабайлардан ишеткән «булган» хәлләр турында сөйләшү белән мавыгып, көннең үтеп киткәне сизелми дә кала. Язучының реаль тормышта барган вакыйгаларга экияти фантасти-

каны кертүе, бала үсеше антогенезында мондый төр экият-хикәятләр бик әһәмиятле роль башкаруын ассызыклый.

Моннан тыш экиятләр борынгы бабаларыбыз яшәешендә зур роль уйнавын да онытырга ярамый, бу текстларда халыкның яшәеше, әйләнә-тирәне танып-белүе чагыла. Борынгылар тормышының иң әһәмиятле мизгелләрендә экиятләргә – ыруның изге хикәяләренә мөрәҗәгать иткән. Һәр халык яшь буынны тәрбияләгәндә авыз иҗаты әсәрләренә, бигрәк тә, экиятләргә һәм мифларга актив мөрәҗәгать итәләр. Мифологик сюжетларга таянып, балаларны көндәлек тормыш, яшәеш үзенчәлекләре, табигать күренешләре белән таныштырганнар, кешеләр янәшәсендә яши торган мифологик персонажлар белән гароминиядә яшәргә өйрәткәннәр.

Борынгыдан кешеләр акыл белән аңлатып булмаган күренеш-вакыйгалар, гадәти булмаган сюжетлар, тылсымлы предметлар, мифологик персонажлар белән аеруча кызыксынганнар, аларны аңларга омтылганнар. Балалар да фольклорның бу төр жанры белән кызыксына, аларны тыңларга һәм сөйләргә ярата. Психологлар билгеләр үткәнчә, мондый хикәяләр мәктәпкәчә яшьтәге һәм башлангыч сыйныф балалары үсешендә шактый мөһим роль уйныйлар. Чөнки экият сюжетлары аркылы балалар яхшылык һәм яманлык кебек төшенчәләр, кайбер экзестенциаль проблемалар белән тәүге тапкыр танышалар. Бу сюжетлар яхшылыкның явызлыкны җиңүен һәм дә явызлык җәзага тартылачагын, үлемнең ни икәнен аңларга ярдәм итә.

Киләчәк буынга кешелекнең беренчел кыйммәтләре дә экиятләр аша сеңдерелә. Әлбәттә, бу экиятләрне балалар өлкәннәрдән ишетсәләр яхшырак. Юкка гына сөекле шагыйребез Габдулла Тукай «Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән», – дип язмаган. Татарларда баланың психологик хәләтен кайгырту һәм халык традицияләренә өйрәтү башлыча әби-бабаларга йөкләнгән, чөнки әти-әнинең вазифалары – баланы матди яктан тәэмин итү һәм аның физиологик сәламәтлеген кайгырту булган. Әбиләрнең экиятне эмоциональ бизәкләрләргә төреп, бик сәнгатьле итеп сөйли белү сәләте булуын да исәпкә алсак, алардан да үтемлерәк экиятчене табу кыен булыр. Нәкъ шушындый хикәяләр сөйләү буыннар арасындагы бәйләнешләрне ныгыткан, менталь кыйммәтләрне тапшыра торган чылбырны саклаган.

Шуны истә тотарга кирәк: барлык куркыныч вакыйгалар читләтеп күрсәтелә, алар табигый кабул ителә. Балалар, бу яшьтә авыр кабул ителә торган, ялгызлык, якыннарны югалту, үлем кебек темалар белән 5–7 яшьтә кызыксына башлыйлар. Бу очракта экият – әлеге четрекле мәсьәләрне аңлату өчен үтемле чара. Психологлар раслаганча, «бераз курку» – баланың нормаль ихтыяҗы. Кеше бу дөньяга килгәндә, ягъни туганда бер хис-курку хисе белән туа.

Курку хисе табигатьтә үз-үзеңне саклау инстикты буларак барлыкка килә. Мондый тәҗрибәне кечкенәдән туплау, кешене күп ситуациядән чыгу юлларын булдыра, курку хисен киметә, кайбер очракта аның бөтенләй юкка чыгуына китерә.

Галимҗан Ибраһимов сурәтләгән мифик персонаж – аждаһа образы төрле амплуада һәм төрле исемнәр белән дөнья халык әкиятләрендә бик еш очрый торган герой, бер берсе белән бәйләнештә булмаган халыклар мифологиясендә формалаша. Аждаһа – мифологиядә көч, яшерен акыл, зирәклек символы. Татар мифологик хикәятләрендә бирелгән мәгълүмат буенча, ул: төрле формага керә ала; тынычсызламаганда, ул тыныч кына күлдә ятарга мөмкин; күпмедер яшькә җиткән аждаһаны давыл күтәрергә яки ул үзе дә канатланып очарга мөмкин; авызыннан утлар чәчәреп әйләне-тирәне яндырырга һәм 100–1000 еллар яшәгәч, юха еланына әйләнеп, теләсә-нинди җан иясе кыяфәтенә керергә мөмкин. Психологик символларга килгәндә, тыныч кына су төбендә яткан аждаһа – тынычлык халәтен сакланган интуиция яки яшерен хисләр, канатлы аждаһа исә кеше өчен иң кадерле хисләрне: мәхәббәт, гайрәт; ут чәчә торганы иҗади сәләтне, эстетик зәвыкны; җирдәгесе реаль кешеләргә хас сыйфатларга ия булуын тасвирлый. Бер сүз белән әйткәндә, һәр кеше үзенең үсеш этапларында аждаһа төрләренең бөтенесен дә үтә.

Г. Ибраһимовның татар тарихына, фольклорына, этнографиясе, халык педагогикасы һәм этнопсихологиясенә мөнәсәбәтле эшчәнлеге барыбызга да таныш. Ул аларны туплау, саклау буенча зур эш башкарган һәм үзенең «Әдәбият кануннары» хезмәтендә бер бүлекне тулысынча халык авыз иҗатына багышлаган [2: 16]. Ул халыктан җыйган сүз сәнгате геройлары ярдәмендә балалар һәм яшүсмерләрне гаять катлаулы психологик проблемаларны аңларга һәм кабул итәргә өйрәтә. Шулай ук XX гасыр башында Европада киң таралган психологияне ачу ысулларын да куллана.

Көнбатыш галимнәре аң, аң арты, Эго, Супер Эго, Ид, коллектив аңсызлык кебек категорияләр белән мавыккан бу чорда, әдипләр дә кеше психологиясен мифлар һәм мифологик персонажлар ярдәмендә аңлаталар. Алар фикеренчә, мифлар һәм аның геройлары – кешедә барган психик процессларның иллюстрацион чагышы.

«Яз башы» хикәясен укыгач, әдипнең бу теорияне үзләштергән булуына шик калмый. Бәлки ул халык педагогикасының һәм психологиясенең нигезендә яткандыр!?

Әдипнең аждаһа образына мөрәҗәгать итүе һич тә очраклы түгел. Әкиятләрне тасвирланган аждаһа да, герой да – безнең психиканың өлешләре. Аждаһа – кеше психикасында табигый инстинкт символы, ә Салих исә, киресенчә, аңлылык, гасырлар дәвамын-

да халкыбыз тудырган, туплап килгән мәдәни кыйммәтләр һәм әхлакый кагыйдәләр чагылышы. З. Фрейд аңлатканча, табигать биргән инстиктлар, гадәттә, җәмгыять һәм социум тафыннан катгый тәнкытьләнә, ягъни Эго белән Ид арасындагы мөнәсәбәтне гаилә тәрбияләгән мораль-этик кыйммәтләр җыелмасы булган Супер Эго һәрдаим күз угында тота һәм кирәк вакытта катгый хөкемнәр дә кабул итә.

Г. Ибраһимовның әсәрләрендә бу персонажга урын бирүенең икенче бер максаты булуы да ихтимал. К.Г. Юнг теориясенә мөрәҗәгать итеп, аның Анима, Анимус, Тень, Самость, Ана, Ата архетипларын исәпкә алсак, бу хикәядә архетипларның кайберләренең чагылышын күзәтергә мөмкин. Иң беренче чиратта, шәхеснең асылын күрсәтә торган Самость архетибын ачу юлында да әдип аждаһа образын файдалана.

Хикәя тукымасыннан күренгәнчә, Салих инде туган йортыннан киткән, әнисеннән аерым яши, сепарацияне узган, димәк ул инде җитлеккән егет. Шулай да булуга карамастан, әнисеннән әле тулысынча аерылып бетмәгән. Моның дәлиле буларак, алдарак баланың анасына булган хисләре турында язып үткән идек. Бер очракта аждаһа образын Ана, хатын-кызны чагылдыручы символ итеп күрсәтеп булыр иде. Бу очракта төп каһарманыбыз Салихның киләчәктә ир-ат буларак нинди хатын-кызлар белән аралашачагы, хатын-кызлардагы нинди сыйфатларга игътибар бирәчәгенә ишарә ясала. Геройның Анима архетибы формалашуында әнисенең йогынтысын ачык күреп була.

Йомгаклап әйткәндә, Г. Ибраһимов үзенең «Яз башы» хикәясендә Салих шәкертнең бер көн эчендә кичергәннәрен генә сурәтләп калмаган. Бәлки халык авыз иҗаты аждаһа образын файдаланып, үсмернең психологик халәтен ачып биргән. Әйтергә кирәк, бу әдипнең әдәби осталыгы, шулай ук нечкә психолог һәм халык педагогикасы һәм психологиясе белгече булуын исбатлый. Бу хикәя, һичшиксез, балалар әдәбияты өлкәсендә кечкенә герой дөньясын ачып бирүдә иң камил әсәр булып саналырга хокуклы. Шуңа да ул бүгенге көн балаларының да яраткан әсәре булып кала бирә.

ӘДӘБИЯТ

1. Заһидуллина Д.Ф. Модернизм һәм ХХ йөз башы татар прозасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 255 б.

2. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр. Т. 1. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1957. – 527 б.

3. Садекова А.Х. Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова // Галимҗан Ибрагимовның иҗат дөньясында. Казан, 2012 . – Б. 9–103.

4. Садыйкова А.Х. XII–XX гасыр башы татар әдәбиятында дини фольклор. – Казан: ИЯЛИ, 2014. – 308 б.

5. Фрейд З., Юнг К. Опасные желания. Что движет человеком? Перевод с нем. – М.: Алгоритм, 2018. – 288 с.

УДК 070

## О ПСЕВДОНИМЕ «ГАБДИ»

***Ф.Г. Файзуллина***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

Научные статьи, освещающие вопросы татарской литературы, языка, также публицистические статьи, особенно раннего периода, Г. Ибрагимова, опубликованы под разными псевдонимами. На страницах периодической печати наблюдается множество его псевдонимов. В статье говорится о псевдониме «Габди», к которому больше всего обращался автор.
**Ключевые слова:** татарская литература, Г. Ибрагимов, «Габди», публицистика, псевдонимы.

Scientific articles covering the issues of Tatar literature, language, as well as journalistic articles, especially of the early period, by G. Ibragimov, were published under various pseudonyms. On the pages of the periodical press, there are many of his pseudonyms. The article talks about the pseudonym «Gabdi», to which the author turned most of all.
**Key words:** Tatar literature, G. Ibragimov, «Gabdi», journalism, pseudonyms.

## «ГАБДИ» ИМЗАСЫ ТУРЫНДА

***Ф.Г. Фәйзуллина***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (Казан)*

XX йөз башында күп кенә әдипләрнең төрле имзалар белән язуы билгеле. Моңа инану өчен шул чор татар матбугат битләренә күз төшереп алу да җитә. Бик күп имзалар тикшерелеп, аларның кемнеке булуы бүгенге көндә әдәбият галимнәре тарафыннан расланды. Мәсәлән, татар халык шагыйре Г. Тукайның укучыларга 65 имзасы билгеле («Шүрәле», «Су анасы», «Тәртә башы» һ.б.) [11: 306]. Татар әдәбияты классигы Ф. Әмирхан үзенең әсәрләрен «Ташмөхәммәд», «Дамелла» кебек яшерен исемнәр белән бастырган.

Язучы, татар әдәби-нәзари фикерен үстерүгә зур өлеш керткән әдәбият галиме, тел белгече, тарихчы, журналист һәм педагог, шул ук вакытта җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче буларак танылган Г. Ибраһимовның да шактый имзалары билгеле. XX йөз башында Г. Ибраһимов кебек киңкырлы эшчәнлек алып барган шәхесләребезнең төрле имзалар белән басылулары гаҗәп тә түгел кебек.

Г. Ибраһимовның әдәби әсәрләре, татар әдәбияты һәм теле мәсьәләләрен яктырткан фәнни мәкаләләре, публицистик язмалары XX гасыр башында чыккан «Әлислах», «Йолдыз», «Аң», «Ялт-йолт» (Казан), «Вакыт» (Оренбург), «Тормыш» «Безнең

юл», «Ирек» (Уфа), «Чулпан» (Мәскәү) кебек газета-журналларда басылганнар. Бигрәк тә башлангыч чор язмалары төрле имзалар белән дөнья күргәннәр. Матбугат битләре аша аның «Әлислах мөхбире», «Мөхбиреңез», «Габди», «Г-җан», «Гъ-Джан», «Г», «Гъ», «Джан», «Г.И.», «Гыйрфанзадә», «Тыңлаучы» «Г-Джанъ»[1] кебек имзалары билгеле. Г. Ибраһимовның имзаларын ачыклауга Рашат Гайнанов зур өлеш кертте [11: 306]. «Габди» имзасы иң күп кулланылган булса да, кайбер әдәбият галимнәре арасында аның Г. Ибраһимовныкы булу-булмавы төрле сораулар тудырган, шик уяткан. Р.И. Нафигов үзенең Г. Ибраһимов белән Г. Тукай арасындагы мөнәсәбәтләрне ачыкларга тырышып язган язмасында: «До сих пор кое-что написанное Габди, приписывается некоторыми литературоведами Г. Ибрагимову, что вносит дополнительную путаницу в историю...», – дип яза [10: 138]. Әлеге сүзләрне язарга Г. Ибраһимовның үзенең язмасы этәргеч булган. Чөнки, «Йолдыз» газетасының 1911 елгы 25 декабрь санында ул: «Габди илә Галимҗан Ибраһимов буталмаска тиешлеләр» [7], – дигән мөрәҗәгать белән чыга.

Бу мәсьәләне ачыклауда Г. Ибраһимовның «Габди» имзасы белән басылган «Казан китапчылары» [4] һәм «Казан китапчыларының рәддиясе *(кире кагуы)* хакында» [5] дигән мәкаләләре игътибарга лаек. «Вакыт» газетасының 1911 елгы 1 октябрь санындагы «Казан китапчылары» мәкаләсендә автор, Казанда китап басу эшенең торышын яктыртып: «Һәрбер мәүзугъта унар-унбишәр төрлесе язылган булса да, мәктәп китабы дип атау мөмкин булган чүпләрне нәшердә дәвам итәләр, ә адәм санлы әсәрләрне рәд кылалар», [4] – дип, кирәкмәгән китаплар бастырып ятучы наширләрне тәнкыйть утына ала. Аның «Ни өчен матбугат юлына билгеләнгән сәрвәт *(мал)* бер шәһәрдә чамадан тыш бүлекләргә, вак кулга бүленә?» [4] дигән соравы наширләрнең ачуын кузгата. Бу мәкаләгә җавап буларак, «Йолдыз» газетасында Шиһаб Әхмәровның «Сөйләү ансат, эшләү читен» исемле язмасы дөнья күрә. Мәкаләнең ахырында бу фикергә кушылучы Гыйльметдин Шәрәф белән Әхмәд Урманчиевның да имзалары бар. Анда Ш. Әхмәров «Әлеге китапчыларымыз татар шәкертләреннән, мәдрәсә хәлфәләреннән булган кебек, бәхетсезлегемезгә каршы, язучыларымыз да шул татар шәкертләре илә мәдрәсә хәлфәләреннән гыйбарәт булып калды» [1] кебек сүзләр белән Г. Ибраһимовның да һәрнәрсәгә шәкерт күзе белән генә каравына ишарәли. «Вакыт» газетасында башланып киткән бәхәс, «Сабах» китап ширкәтен оештыручыларның берсе Шиһаб Әхмәров, «Матбагаи Шәрәф» китап басмаханәсен оештыручы һәм аның җитәкчесе Гыйльметдин Шәрәф,

[1] Бу имза кириллицада куелган.

«Юл» китап нәшриятының хуҗасы Әхмәт Урманчиевлар белән «Йолдыз» газетасының берничә санында дәвам итә. Газетаның 8 декабрь санында Ш. Әхмәровның «Габди әфәндегә» [2] исемле мөрәҗәгате басыла. Анда: «Әйткән сүз – аткан ук. Йөрәгеңезгә каты кадалган икән, интикам *(үч)* алыңыз, мин җавапка хазир, үземнең сүземне исбат итәрмен... Миннән фатиха, эшне бик зурга йибәреңез, Каф тавы кадәр булсын, яме!» – диелә. Бу сүзләргә җавап итеп, «Габди»: «Хәзер булсаңыз, бик яхшы, мин сезне, шул дәгъваны исбат иттерү өчен, Третейский суд «хөкемнәр хөкеменә» дәгъвәт итәм вә шуны менә хәзер игълям итәм *(белдерәм)*. Минем тарафтан «хәким» булуны әдип мөхтәрәм Фатих Әмирхан әфәнде илә зыялыларымыздан Фәхрелислам Агиев җәнапләре кабул кылдылар. Бу әфәнделәр судка рәис улмак өчен юрист Биньямин әфәнде Әхтәмов җәнапларыннан үтенүне мәгъкуль күрәләр. Менә карарым шушы. Буны игълям иттем. Үз тарафыңыздан ике «хәким» сайлап, Фатих Әмирхан әфәндегә мөрәҗәгать итеңез», – дип ачык чакыру белән чыга [6].

«Йолдыз» газетасының 769 нчы санында Шиһаб Әхмәров һәм Әхмәт Урманчиевларның «Йолдыз» идарәсенә язылган «Иҗабәт һәм дәгъвәт» [3] исемле хатлары басыла. Хат авторлары Галимҗан Ибраһимовның үзен дә Третейский судка чакырулары турында хәбәр итәләр. Бу белдерүдән соң инде бик күп мәкаләләре аша «Габди» имзасы белән укучыларга таныш булган Г. Ибраһимов «Йолдыз» газетасының 25 декабрь санында басылган «Тәхсыйс»ендә: «Могтәбәр «Йолдыз» газетасының 769 нчы номерында «Габди» сүзе кушлар эчендә (Галимҗан Ибраһимов) дип алынган. Бунын сәбәбе аңлашылмады. Мохасимнәр *(судлашучылар)*, хөкемнәр хөкеме белән судлашканнарын белеп, Габди илә Галимҗан Ибраһимов буталмаска тиешлеләр», – дигән мөрәҗәгать белән чыга.

Нәтиҗәдә, 1912 елның 11 февралендә Ибнеәмин Әхтәмов рәислегендә Мәхмүдфуад Туктаров, Фатих Әмирхан, Тимершаһ Соловьев һәм Камил Кәримовлардан җыелган Третейский суд мәҗлесе уза. Анда Галимҗан Ибраһимов (Габди)ның, Шиһаб Әхмәров һәм Әхмәт Урманчиевны матбугат аша үзенә яла яктылар, дип, һәм Ш. Әхмәров белән Ә. Урманчиевның, матбугатта безне мыскыл итте, дип, Г. Ибраһимовны гаепләүләреннән гыйбәрәт булган ике эш карала. Беренче эш буенча, Третейский суд Г. Ибраһимов һәм аның вәкиле Ф. Агиевның гаепләүләрен һәм Әхмәров белән Урманчиевның үзләренең гаепсезлекләре хакында сөйләгән сүзләрен тыңлаганнан соң, түбәндәге карарга килә: «Әхмәров һәм Урманчиевның газетада Ибраһимовны плагиат берлә ифтира кылулар *(яла ягулар)* исбат кылынмаганлыктан, Ибраһимовның мәзкүр *(әйтелеп үтелгән)* Әхмәров вә Урманчиевны миңа ифтира кылдылар дип гаепләве үз-үзеннән бетәдер» Икенче эш буенча түбәндәге

карарда: «Г. Ибраһимовның “Йолдыз”ның 761 нче санында басылган мәкаләсендә кулланылган чагыштыру һәм гыйбарәләрендә Әхмәров белән Урманчиевны мыскыл итү бар. Мондый гыйбарәләрне мабугатта куллану һич тә ярамый торган эш», – диелә [12].

Суд карарларында Г. Ибраһимовның чын исеме яңгыравы аның «Габди» белән бер үк кеше булуы турында сөйли.

Матбугаттагы мондый бәхәсләрдән соң, Г. Ибраһимов «Габди» имзасына бик сирәк мөрәҗәгать итә. Һәм бераздан бөтенләй бу имза белән язудан туктый.

Г. Ибраһимов соңрак язылган «Актык сәлам» мәкаләсендә, үзенең «Тәхсыйс»ендәге сүзләренә каршы килеп: «Башта бераз вакыт “Габди” дип имза итсәм дә, һәрвакыт бер генә төрле имза иткәнгә, газета вә журналлар арасында аның кемнеке икәне билгеле иде. Бераздан соң бер әсәрнең, бер мөхәррирнең яхшы ягымы, начар ягымы күрсәтелгән булсын, һичбер мөляхәзәмдә *(фикерләремдә)* укучылардан үз имзамны яшереп азапланмадым» [9], – ди. Үз заманы әдәбият белгечләре арасында да Г. Ибраһимов исеме белән «Габди» имзасы бергә йөргән [8].

ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ЧЫГАНАКЛАР

1. Әхмәров Ш. Сөйләү ансат, эшләү читен // Йолдыз. – 1911. –29 ноябрь.
2. Әхмәров Ш. Габди әфәндегә // Йолдыз. – 1911. – 8 декабрь.
3. Әхмәров Ш., Урманчиев Ә. Иҗабәт һәм дәгъвәт // Йолдыз. – 1911. – 19 декабрь.
4. Габди. Казан китапчылары // Вакыт. – 1911. – 1 октябрь.
5. Габди. Казан китапчыларының рәддиясе хакында // Йолдыз. – 1911. – 4 декабрь.
6. Габди. Дәгъвәт // Йолдыз. – 1911. – 15 декабрь.
7. Габди. Тәхсыйс // Йолдыз. – 1911. – 25 декабрь.
8. Гөбәй. Тәнкыйтьчеләремез арасында // Шура. – 1915. – № 1.
9. Ибраһимов Г. Актык сәлам // Йолдыз. – 1915. – 16 октябрь.
10. Нафигов Р.И. Наш Тукай: Новые страницы из жизни Поэта. – Казань: Фикер, 1998. –168.
11. Рәмиев З. Әдәбиятчы-текстолог язмалары (1990–2013 еллар). – Казан: «Ихлас». 2014. – 436 б.
12. Хөкем хөкеме // Йолдыз. – 1912. – 26 февраль.

УДК 82.091

## ПРОБЛЕМА СИМВОЛА В ТАТАРСКОМ ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИИ НАЧАЛА XX ВЕКА

***Н.М. Юсупова, Э.Ф. Гарифуллина***
*Казанский (Приволжский) федеральный университет (Казань)*

Статья посвящена изучению проблемы символа в татарском литературоведении начала XX века. На материале статей и научных трудов Г. Ибрагимова, Дж. Валиди, Самата, Ф. Сайфи-Казанлы, Г. Нигмати, Г. Сагди, Г. Рахим и др., в той или иной степени соприкасающихся с

проблемой символа, доказывается, что теоретико-литературные знания о символе начинают формироваться в татарской научной мысли в начале XX века. Хотя они не образуют стройной системы теории символа, но расширяют представление о теоретических основах и функциональных возможностях символа. В них имеют место попытки найти эквивалент символу на татарском языке. Теория символа в татарской литературоведческой мысли начинает разрабатываться в 1920-е годы XX века, о чем свидетельствуют научные труды Г. Нигмати, Г. Сагди, Г. Рахима. В их исследованиях конкретизируются функции, смысловые возможности символа и способы смыслопорождения в национальной поэтике.
**Ключевые слова:** символ, татарское литературоведение, Г. Ибрагимов, Дж. Валиди, теория балягать.

The article is devoted to the study of the problem of the symbol in the Tatar literary criticism of the first third of the 20th century. Based on the articles and scientific works of G. Ibragimov, J. Validi, Samat, F. Saifi-Kazanli, G. Nigmati, G. Sagdi, G. Rakhim, etc. that theoretical and literary knowledge about the symbol begins to form in the Tatar scientific thought at the beginning of the twentieth century. Although they do not form a coherent system of symbol theory, they expand the understanding of the theoretical foundations and functional capabilities of the symbol. They attempt to find an equivalent to the character in the Tatar language. The theory of the symbol in the Tatar literary thought began to be developed in the 1920–30s of the twentieth century, as evidenced by the scientific works of G. Nigmati, G. Sagdi, G. Rakhim. In their studies, the functions, semantic possibilities of the symbol and ways of generating meaning in national poetics are concretized.
**Key words:** symbol, Tatar literary criticism, G. Ibragimov, J. Validi, the theory of joking.

В литературоведении символ является одной из самых многогранных, многозначных и полисемантических категорий, так как «культура и литература выражают себя через мир символических форм, которые передаются от человека к человеку, от поколения к поколению» [9: 14-15]. По мнению А. Белого, «искусство XX столетия насквозь символично» [1: 340].

В силу своей активности образ-символ привлекает внимание многих ученых-литературоведов. Однако в татарском литературоведении недостаточно работ, посвященных генезису, специфике смыслового функционирования и развития образов-символов, доминируют исследования, в которых основное внимание направлено на выявление идейно-тематического содержания художественных произведений, их сюжетно-композиционных особенностей [22: 6]. Теоретическое осмысление символа в татарском литературоведении было предпринято в начале XX века.

Начало изучения символов восходит в теорию балягать. В IX веке в арабской литературе сложилось учение поэтики «ба-

лягать» – учение о тропах и поэтических фигурах, которое привело к становлению «нового», «дивного» поэтического стиля «бадиг». Первым ученым, выработавшим учение «балягать», был Ибн ал-Мутазз (861–908), автор сочинения «Китаб ал-бадиг» (887–888). Он является первым ученым, классифицирующим новые поэтические фигуры и средства поэтического языка. Ибн ал-Мутазз выделяет 13 «красот» – махисин, «украшений» и 5 фигур стиля «бадиг», среди которых отдельно выделялись «истиара», тарид (намек) и кинайа (иносказательность) и т.д. [8: 127]. Позже создаются новые термины, много новых фигур [7: 200]. После принятия ислама арабская филологическая мысль стала научной надстройкой, теоретическим руководством для тюркоязычных поэтов и ученых [4: 48]. Как показывает Р. Мусульманкулов, особое развитие получают исследования теории художественных фигур, т.е., в первую очередь техническая сторона поэзии, на протяжении последнего тысячелетия о фигурах языка были созданы десятки трудов [10: 12]. Научные трактаты как арабских, так и тюркских авторов активно распространяются и в мэдрэсе Поволжья и Приуралья, многие из терминов, поэтических фигур и определений, предложенных в трактатах по «бадиг» – игтираз, тафрик, тафсир, илтифат, ташбих, кинайа, истигара, тасик ас-сыйфат и т.д. – активно применяются в учебниках риторики и теории [21: 52].

Первооткрывателями этого процесса в татарском литературоведении можно назвать Г. Ибрагимова и Дж. Валиди, в научно-критических статьях которых началось первичное осмысление функции символа в структуре художественного текста. Так, Дж. Валиди в труде «Татар әдәбиятының барышы» («История татарской литературы», 1912), описывая суфийскую поэзию, отметил, что в тот период поэты и писатели предпочитали не художественное описание реальности, их «интересовали иносказательность, метафора, условные образы, переносный смысл» [2: 21]. При анализе конкретных текстов становится очевидным, что под «иносказательностью, переносным смыслом» подразумеваются символы.

Г. Ибрагимов в статье «Татар шагыйрьләре» («Татарские поэты», 1913), на материале поэтических произведений Дардменда, указывает на символы, называя их метафорой («тәшбиһ», «мәҗаз»). По его мнению, Дардменд часто прибегает к метафорам для констатации авторской идеи, однако в них отсутствует «описание (сыйфатланмыш), вспомогательное слово (ярдәмче сүз)» [5: 100]. Именно такие образные средства, считает Г. Ибрагимов, способствуют совершенствованию авторского стиля и наполняют произведение эстетическим и философским содержанием, изящностью и эстетической притягательностью.

Вслед за статьей Г. Ибрагимова появляется статья Дж. Валиди «Татар шагыйрьләре» («Татарские поэты», 1913), в котором особым, отличительным признаком поэзии Дардменда критик называет символизацию, а самого поэта – символистом. По мнению Дж. Валиди, в авторских символах Дардменда отчетливо проявляются «бездонность различных смысловых нюансов, трансцендентное содержание» [3]. В статье Дж. Валиди, таким образом, символ впервые определён как термин с указанием его функционального поля в рамках художественного произведения. С этого момента он закрепляется в татарском литературоведении.

Имели место попытки найти эквивалент символу на тюрко-татарском языке. Так, в книге Г. Сагди «Әдәбият мөгаллиме» («Учитель литературы», 1913) использован термин «яшерен тәкъбир, киная» («трансцендентное») [16: 12]. В целом отношение к символу было позитивным. Например, в статье Ф. Сайфи-Казанлы «Сәгыйть Сүнчәләй шигырьләре» («Стихи С. Сунчелея», 1913) символическая образность определяется как возможность достижения содержательной и формальной гармонии, «красоты изложения мыслей» [20: 14]. В статье Самата «Күк кош вә безнең көннәр» («Синяя птица, или Наши дни», 1915), написанной в форме анализа лекций приват-доцента Петроградского университета П.С. Когана, символизация названа «языком души» [15]. Сам термин утверждается в истории литературы: Г. Рахим в статье «Иран шагыйрьләре» («Иранские поэты», 1919) главной особенностью восточной поэзии Средневековья указывает символизацию, хотя в отношении символа пользуется термином «киная-аллегория» [130: 117].

В 1920-е годы интерес к символу не угасает. Так, Г. Рахим в статье «Нәләтләр шагыйре» («Поэт проклятий», 1923), посвященной художественному своеобразию творчества Х. Такташа, называет символизацию главной особенностью национальной словесности и оценивает её художественным достоинством стиля поэта [14: 68]. В своей статье «Вакытсыз һәлак булды» («Безвременно погиб», 1922), проанализировав в хронологическом порядке произведения Ш. Бабича, Г. Ибрагимов приходит к выводу, что в его творчестве персонажи и образы исламской мифологии – Җәбраил (Джабраил), җәннәт (рай), җәһәннәм (ад) – имеют статус символа (истигарә)» [6: 319]. Таким образом, в татарском литературоведении некоторые мифологические образы начинают изучаться в статусе символа.

В 1925 году, с появлением книги Г. Нигмати «Әдәбият мәйданында» («На литературной арене», 1925), символ как основное понятие символизма стал сравниваться со знаком: «Символ – это знак, но не каждый знак есть символ» [11: 44]. По мнению Г. Ниг-

мати, знак, имеющий субъективный подтекст, называется символом. Далее он детализирует, что его содержание, лежащее на поверхности, будет понятно «толпе» – массовому читателю, а подтекст адресуется определенному типу читателя. В символах, прежде всего, необходимо выявить философское содержание, именно с такой позиции ученый анализирует произведения Г. Тукая, С. Рамиева, Дардменда и Х. Такташа.

Подобная тенденция присутствует и в трудах Г. Рахима. В частности, в статье «Газиз әсәрләре» («Произведения Газиза») некоторые произведения Г. Губайдуллина он называет «символистско-философскими» [12: 219].

Дальнейшая научная разработка теории символа связана с именем Г. Сагди. В труде «Татар әдәбияты тарихы» («История татарской литературы», 1926) в контексте эволюции литературных направлений и течений он выявляет такие характерные особенности символа, как его многозначность, условность, иносказательность, метафоричность, а также философичность [17: 201–203] и называет символа «окном в Вечность». Символизацию он определяет как особенность стиля, например, именно она позволяет Дардменду достичь равнозначности «формы и содержания», «явного – скрытого», порождает музыкальность в изложении мыслей. В работе «Тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсүләре» («Язык, литература, письменность и их историческое развитие», 1926) Г. Сагди констатирует: символизация – один из «первых стилей татарской литературы» [18: 53].

В монографии Г. Сагди «Символизм турында» («О символизме», 1932) символы и символизм становятся главными объектами исследования. Автор разделяет символизм на восточный и западный типы. Считая символ своеобразным фундаментом символизма, в качестве общих признаков символов он выделяет «условность, окрашенность, идеологический монизм (концептуальность), трансцендентальность» [19: 27–28]. На примере творчества двух поэтов – Дардменда («Без», «Кораб», «Исте җилләр ил эченнән...», «Замана» и пр.), имевшего «восточный» склад мышления, и С. Рамиева («Алданган», «Мин үләм», «Минутлар», «Кеше» и пр.) – представителя «западного» склада мышления – Г. Сагди выявляет основные различия в их творчестве. Формирование символизма в татарской литературе начала XX века ученый рассматривает как результат взаимодействия двух культур – восточной и западной [19: 92–93], термин «татарский символизм» он использует для определения произведений авангардного направления. Параллельно Г. Сагди предпринимает попытку классифицировать символы (суфийские и восточно-романтические символы Востока, религиозные символы Запада), проводит четкую грань между

«романтическими» и «символическими» образами-символами, называет их особенности. Г. Сагди выдвигает тезис: в каждой национальной литературе то или иное направление или явление обладает своеобразием. Так было положено начало теоретическому осмыслению символизма в татарской литературе с учетом национальной специфики функционирования символа.

Таким образом, теория символа в татарском литературоведении начала разрабатываться довольно поздно – в начале XX века. Анализ критических и теоретических статей Дж. Валиди, Г. Ибрагимова, Самата и других показал, что в татарской научной мысли теоретико-литературные знания о символе начинают формироваться в начале XX века, но они не образуют стройной системы теории символа как в русском литературоведении. Термин «символ» прочно вошел в историю литературы, литературную критику уже в 1920-е годы. Теоретические изыскания Г. Нигмати, Г. Сагди, Г. Рахима расширяют знания и представления о теоретических основах и функциональных возможностях символа, в исследованиях этих авторов символ как термин прочно входит в историю литературы, ими выдвигается тезис о национальной специфике его функционирования.

ӘДӘБИЯТ

1. Белый А. Символизм как миропонимание. – М.: Республика, 1994. – 528 с.

2. Вәлиди Җ. Татар әдәбиятының барышы. – Оренбург, 1912. – 122 б.

3. Вәлиди Җ. Татар шагыйрьләре // Вакыт. – 1913. – 25 июль.

4. Загидуллина Д. Влияние средневековой арабской и персидской науки балягать на татарское литературоведение // Ученые записки Казанского государственного университета, Т. 150, кн. 8. – Казань, 2008. – С. 48–56.

5. Ибраһимов Г. Татар шагыйрьләре // Әсәрләр: 8 томда. Т. 5. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – Б. 74-156.

6. Ибраһимов Г. Вакытсыз һәлак булды... // Әсәрләр: 8 томда. Т. 5. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – Б. 314–329.

7. Каскель В. «Китаб ал-бадиг» и ее место в арабской поэтике и риторике // Арабская средневековая культура и литература. – М.: Наука, 1978. – С. 199–202.

8. Крачковский И.В. Избранные сочинения: в 6 т. Т. 6. / И.В. Крачковский. – М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1960. – 740 с.

9. Культурология: учеб. пособие / сост. и отв. редактор А.А. Радугин. – М.: Центр, 2003. – 243 с.

10. Мусульманкулов Р. Персидско-таджикская классическая поэтика (X–XV вв.). – М.: Наука, 1989. –240 с.

11. Нигъмәти Г. Әдәбият мәйданында. – М.: Центральное издательство народов Союза ССР, 1925. – 110 б.

12. Рәхим Г.Г. Газиз әсәрләре // Газиз Гобәйдуллин: фәнни-биографик җыентык. – Казан: Рухият, 2002. – Б. 219–222.

13. Рәхим Г.Г. Иран шагыйрьләре // Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / төз.: Раиф Мәрданов, Ирек Һадиев. – Казан: Җыен, 2008. – Б. 116–119.

14. Рәхим Г. Нәләтләр шагыйре // Безнең юл. – 1923. – № 10–11. – Б. 62–82.

15. Самат. Күк кош вә безнең көннәр // Тормыш. – 1915. – 30 октябрь.

16. Сәгъди Г. Әдәбият мөгаллиме. Рөшди мәктәп өчен дәреслек китабы. – Уфа: Хөсәенов, 1913. – 153 б.

17. Сәгъди Г. Татар әдәбияты тарихы. – Татарстан дәүләт нәшрияты басмасы, 1926. – 300 б.
18. Сәгъди Г. Тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсүләре. – Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты, 1926. – 246 б.
19. Сәгъди Г. Символизм турында. – М.: Центриздат, 1932. – 135 б.
20. Сәйфи-Казанлы Ф. Сәгыйть Сүнчәләй шигырьләре // Аң. – 1913. – № 21. – Б. 8–14.
21. Юсупов А.Ф. Атрибуция языка татарской суфийской поэзии XIX века: дисс….докт. филол. наук. – Казань, 2022. – 502 с.
22. Юсупова Н.М. Образ-символ как система номинаций в татарской поэзии первой половины XX века: дис…. д-ра филол. наук, 2018. – 399 с.

УДК 159.9

# ЦВЕТОВАЯ СИМВОЛИКА В РАССКАЗЕ Г. ИБРАГИМОВА «ДИҢГЕЗДӘ» («В МОРЕ»)

***Р.А. Яруллина-Йылдырым***
*Университет Иненю (Малатя, Турция)*

Цвета, играющие важную роль в познании предметов, вызывают большой интерес в человеческом мире с момента сотворения мира и считаются средством, помогающим воспринимать окружающую среду, дифференцировать общество и явления. Цвета, широко употребляемые в устном народном творчестве тюркских народов, использовались как символ для отражения ценности и сакральности тех или иных вещей, для определения национальных и религиозных взглядов.
Опираясь на мнения таких турецких ученых, как В. Огел, Р. Генч и Я. Чорухлу, исследовавших содержание цвета в общих для всех тюркских народов литературных наследиях, в статье сделана попытка раскрыть мироощущение главного героя произведения через цвета в рассказе Г. Ибрагимова «В море». Как видно из рассказа, художник использовал цвета в основном в двух целях – для отражения морского пейзажа и для того, чтобы эффективно передать эмоциональное движение души главного героя.
**Ключевые слова:** тюркская мифология, значение цвета, пейзаж, психология человека.

Colors, which play an important role in the cognition of objects, have been of great interest in the human world since the creation of the world and are considered a means of helping to perceive the environment, to differentiate society and phenomena. Colors, widely used in the oral folk art of the Turkic peoples, were used as a symbol to reflect the value and sacredness of certain things, to determine national and religious views.
Based on the opinions of such Turkish scientists as V. Ogel, R. Gench and Y. Choruhlu, who studied the content of color in the literary heritage common to all Turkic peoples, the article attempts to reveal the attitude of the protagonist of the work through colors in the story of G. Ibragimov «In Sea». As can be seen from the story, the artist used colors mainly for two

purposes – to reflect the seascape and in order to effectively convey the emotional movement of the protagonist's soul.
**Key words:** Turkic mythology, color meaning, landscape, human psychology.

## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ «ДИҢГЕЗДӘ» ХИКӘЯСЕНДӘ ТӨСЛӘР СИМВОЛИКАСЫ

***Р.Ә. Яруллина-Йылдырым***
*Иненю университеты (Малатя, Төркия)*

Әйберләрне танып-белүдә мөһим роль уйнаучы төсләр, галәм яратылганнан башлап кешелек дөньясында зур кызыксыну уяткан һәм тирә-юньне кабул итүдә, җәмгыятьне һәм күренешләрне төрле катлауларга аеруда ярдәм итү чарасы саналган. «Чөнки бер әйберне яки киңрәк мәгънәдә бер фикерне икенчесеннән аеру өчен кулланылган иң отышлы юллардан иң әһәмиятлесе ул – төсләр» [7: 147]. Төрки халыкларның авыз иҗатында кулланылган төсләрнең символик мәгънәсе бар, алар күренешләрнең яки предметларның кыйммәтен һәм сакраль асылын, дуаль дөньядагы урыннарын билгеләү өчен кулланылган [11: 130]. Бу борынгы төркиләрнең географик атамаларында, сакраль атрибутлардан саналган байракларга билгеле бер төсләр сайлауда, көндәлек тормышта билгеле бер төсләрнең кулланылуында күренә. Милли һәм дини карашларыбызны чагылдыруда да төс компонентының роле зур.

Алдан нигездә кешене чорнап алган предметлар дөньясында аеру чарасы булган төсләр, тора-бара тагын да тирәнрәк мәгънәдә кулланыла башлый, алар кешенең катлаулы, бай эчке дөньясын һәм хис-кичерешләрен белдерү һәм тәэсир итү чарасына әверелә [10: 72]. Йосыф Чопур төсләрнең әһәмиятен күрсәтеп, «Әдәбият һәм рәсем кебек бик күп сәнгать өлкәсендә, тарих, медицина, дин һәм халык ышанулары кебек социаль яшәүнең төрле тармакларында төсләрнең көченнән файдаланганнар. Кешенең фикер һәм рух дөньясына көчле тәэсир итүе сәбәпле, төсләр тормышның аерылмас бер өлеше санала», – дип яза [4: 197]. Билгеле бер төсләрнең кешенең күңел халәте белән тыгыз бәйләнештә булуы хәзерге белгечләр тарафыннан исбат ителгән. Кешенең эчке халәтен үзгәртү өчен төрле төсләр ярдәмендә психологик дәвалау сеанслары уздырыла. Һәр кешенең яраткан һәм якын күргән төсе бар, ул төс аның энергиясенә һәм рухи халәтенә уңай йогынты ясый, күңеленә хуш килмәгән төсләр, киресенчә, тискәре тәэсир итәргә мөмкин. Төрек психологы Давыт Ибраһимоглуның фикеренә күрә, кеше билгеле бер төсне очраклы рәвештә түгел, бәлки күңел дөньясындагы ихтыяҗына күрә сайлый. Төсләр аша дәвалауның өч ысулын күрсәтә: прожектор аша проблемалы өлешкә кирәкле төс яктырту, ул төстә берәр кием кию һәм кешенең үзе теләгән төсне эчтән уйлавы. Бу өч ысул да кешедәге чакраларны ача һәм тәндәге энергия дөрес

хәрәкәт итә башлавы нәтиҗәсендә кешенең саулыгын яхшыра, ди (www.psikoenerj..com.18.01.2005).

Төркиядә борынгы җәмгыятьнең дөньяга карашын һәм милли кыйммәтләрен халык авыз иҗаты әсәрләрендә еш кулланылган төсләр аша өйрәнү өлкәсендә киң тикшеренүләр алып барыла. Әдәбият белемендә исламга кадәр һәм ислам дине йогынтысында язылган әсәрләрдә (бигрәк тә диван әдәбияты вәкилләренең шигырьләре үрнәгендә) төсләрнең функциясен тикшерү буенча да шактый хезмәт язылган. Төсләрнең төрки халыкларның мифологиясендәге урыны Ваһаетдин Өгел, Яшар Чоруһлу, Абдулкадыйр Инан, Решат Генч һ.б. кебек төрек фольклорчыларының хезмәтләрендә махсус тикшерелгән.

Татар халык авыз иҗатында һәм матур әдәбиятында да, шул исәптән Галимҗан Ибраһимов иҗатында да, төсләргә зур игътибар бирелә. Бу мәкаләбездә уртак төрки мирасыбыз буенча төсләрнең эчтәлеген тикшергән төрек галимнәренең фикерләренә таянып, Галимҗан Ибраһимовның «Диңгездә» хикәясендә кулланылган төсләр аша әсәр героеның дөньяга карашын ачыкларга тырышабыз.

Әдипнең 1911 елда язылган «Диңгездә» хикәясендә шәһәрнең тупас тормышыннан качып, табигать кочагына – диңгезгә атылган романтик геройның катлаулы эчке дөньясы мул табигать тасвирлары аша чагылыш таба [12: 612]. Табигать күренешләре яшәү мәгънәсе турындагы уйлануларга талган, «моңарчы булган кызганыч тән яшәве белән түгел, башка бер яшәү белән, матур, изге, бөек яшәү белән яшәргә» омтылган романтик «мин»нең күңел халәте аша тасвир ителә. Дания Заһидуллина фикеренә күрә, язучы хикәядәге ике дөнья моделен «хикәяләүче «мин»нең хисси-эмоциональ дөньясын – реаль тормышка, ә диңгезнең һәм күкнең иркенлеген җир тормышына каршы куя» [1: 113]. Мондый каршылык әсәрдәге төсләр чагылышында да күзгә ташлана. Романтик геройның тормышка катлаулы мөнәсәбәтен һәм эчке халәтен биләп алган тойгыларны чагылдыруда язучының каләме берничә төскә еш мөрәҗәгать итә.

**Ак.** Мул файдаланылган төсләрдән беренчесе – *ак төс.* Төрки мифология буенча хезмәтләре белән танылган Ваһаетдин Өгел фикеренчә, *ак төс* чисталык, арулык һәм бөеклек мәгънәләрен белдерә, шулай ук хөкемдарларның гаделлек һәм көч, дәрәҗә символы булып тора. Мәсәлән, хун гаскәрләре башлыклары кигән ак төстәге кием аларның затлы нәселдән килүен һәм күңелләренең чисталыгын күрсәтә [8: 378–400]. Бик күп халыкларда *ак төс* үз эченә «яктылык, нур, кояш, һава, сафлык, чисталык, гыйффәт, гөнаһсызлык, гадилек, камиллек, изгелек, котылу, рухи өлгерү» [5: 226] кебек мәгънәләрне ала. Төрки халыклар мифологиясендә

һәм культурасында ак төснең еш куллану сәбәбен Яшар Чоруһлу бу төснең тәңре төсе булуына, ягъни дөнья яратылуын аңлаткан Алтай халыкларының легендасындагы Ак Ана рухының мөһим роль уйнавына бәйләп карый. Абакан шаманнарының догаларында да ак тәңре («Күк тәңредә күк болыт, *ак* тәңредә *ак* болыт...») төшенчәсенең урын алуы моңа дәлил буларак китерелә [5: 226–227].

Татар халык авыз иҗатында да, аеруча мәкальләрдә ак төс сафлык һәм бәхет төсе буларак кабул ителә: «*Ак* сөйгәнне хак сөйгән, хак сөйгәнне халык сөйгән», «*Ак төс* – шат төс» [3: 252]. *Акбуз ат, аксакал, аккош, ак каен* кебек төшенчәләрдә сакральлек, чисталык, гүзәллек кебек төшенчәләрне үзенә ала.

Г. Ибраһимовның «Диңгездә» хикәясенең беренче өлешендә әсәр героеның эчке кичерешләренә бәйле рәвештә табигать, аеруча диңгез тасвиры төрле якты төсләр аша яктыртыла. Шәһәрнең шау-шулы тормышыннан туеп, диңгезгә чыккан «мин», табигатьтә хөкем сөрүче матурлыктан һәм хозурдан тәэсирләнеп, якты уйларга тала. Аның өчен диңгез өсте «иртәле-кичле була торган төрле төстәге матур, шагыйранә күренешләр» булып күренә. Үзен бу гүзәллек дөньясына алып чыккан көймәне «Олы *ак канатларын* мәгърур бер сыйфатта югары каерган җилкән-көймәбез» дип күз алдына бастыра. *Ак канатлар* метафорасы, бер яктан, көймәне тасвир итсә, икенче яктан, диңгез киңлекләренә һәм җирдән күккә – башка бер дөньяга омтылган романтик геройның ак хыялларын, якты теләк-омтылышларын яктырта, аның ул мизгелдәге күңел халәтенең символы ролен үти.

Табигать күренешләрен сурәтләгәндә *ак төс* туры мәгънәдә дә кулланыла. Мәсәлән, куркыныч яшенле төн узып, табигать тынычлана төшкәч, романтик хикәяләүченең күңелендә матур хисләр уяна башлый, яңа көннең тууы аны канатландырып җибәрә. Диңгез яңа төсләрдә күренә башлый: «Диңгез өсте тын, ул, шома көзге кебек, әллә кайдан-кая ялтырап ята. Ерактарак *ак төстә* бик сыек кына томан күтәрелә» [2: 80]. Гадәттә давылдан яки яңгырдан соң барлыкка килә торган ак төстәге томан табигатьнең чистарынуы, тынычланып калуы, тормышның дәвам итүе буларак аңлашыла. Хикәянең башка урыныда *ак* сыйфатының кимлек дәрәҗәсен белдерүче *аксыл* варианты кулланылган : «...эссе кояш белән җылынган диңгез өстеннән акрын гына *аксыл* бу (пар) күтәрелә».

Язучы диңгез өстендә айның күтәрелүен «ахырдан көмеш кебек *ак нурга* әйләнә» тезмәсендә *ак нур* эпитеты аша тасвир итә. *Ак нур* сүзтезмәсе янәшә кулланылган ике синоним сүздән ясалган һәм шул рәвешле ак төснең тәэсир көчен арттыра төшкән. Яктылыкны һәм нурны белдерүче ак төснең синонимы буларак хикәядә иманлы һәм күңеле пакъ булган кешене, төгәлрәге карт хаҗины

белдерү өчен «*нурлы* йөз» метафорасы кулланылган. Белгәнебезчә, нур төрки мифологиядә тәңренең, ислам динендә Алланың чагылышы буларак кабул ителә. Аеруча борынгы төркиләрдә тәңренең төсе ак төстә булуын күз алдында тотсак, нурны да ак төснең синонимы итеп кабул итәргә мөмкин.

Яшар Чоруһлу фикеренчә, төрки халыкларда *ак төс* еш кына үлемне яки үлемнән соңгы кайгы-хәсрәтне дә белдерә. Ак төснең мондый эчтәлек алуын төрек галиме кайчандыр манихеизм динен кабул иткән уйгурларның тәэсирендә булырга мөмкин дип уйлый: «чөнки манихеизмда нурны (яки яхшылыкны) тәмсил итүе сәбәпле, иң әһәмиятле төсләрдән саналган *ак төс* бигрәк тә дин кешеләре кигән киемнәренең төсе булып санала» [5: 228]. Ак төснең үлем төсе булуы телдәге гыйбарәләрдә саклана, мәсәлән, татар халык мифларында өрәкне ак төстә гәүдәләндерү, курку яки хәлсезләнүдән *агарып калу* һ.б. Г. Ибраһимовның «Диңгездә» хикәясенең эчтәлегеннән аңлашылганча, диңгездә куркыныч җил-давыл күтәрелгәч, көймәдәгеләр арасында курку хисе уяна. Көчле давылга битараф «мин» үлем куркусыннан йөзләре үзгәргән юлчыларны тасвир иткәндә *ак төскә*, дөресрәге *ак* сүзеннән ясалган *агару* фигыленә еш мөрәҗәгать итә: «Аның *йөзе ак,* кичәге дәһшәт бөтенләй бетмәгән» [2: 75], «...тулкыннар китереп бәргән саен “аллам!” дип, “аһ-ваһ!” дип чыелдап җибәрәләр дә, озакламый һуштан яздылар, үлек кебек *агарынып* калдылар» [2: 74], «...капитанның йөзе *агара,* куллары калтырый башлый, эчендәген яшерергә теләсә дә, булдыра алмый...», «Ул каршы бер сүз әйтә алмый, *агарынып* җиргә чүгә, сүзсез, хәрәкәтсез буйсына, чөнки тәкдир шулай, язмышы шул!» [2: 74]. Көчле давыл тәэсирендә кешеләрне сарып алган үлем һәм курку хисе йөзләренең яки бөтен гәүдәләренең ак төскә керүе аша үтемле җиткерелгән.

**Кара.** Ак төстән кала, хикәядә романтик геройның күңел призмасы аша еш телгә алынган икенче төс ул – *кара*. Дөнья мифологиясендә кара төс күбрәк тискәре сыйфатларны белдерү өчен кулланыла. Яшар Чоруһлуның хезмәтеннән аңлашылганча, «Мәңгелек караңгылык, бушлык, үлем караңгылыгы, хәсрәт, сихер, начарлык яки үлем белән бәйле мифологик хикәятләрдә урын алаган тәңреләр, хаос, шайтан һ.б. бик күп әйбер *кара төс* аша җиткерелә» [5: 220]. Төрки халыкларда *кара төс* ислам дөньясына күрә төньякта яшәүче географик урын яки халык (мәсәлән, *Карабах, Кара диңгез, Каракалпак* һ.б.) атамасында да кулланыла. Шулай ук шиддәт, золым, берәр хис яки вакыйганың куелыгын көчәйтү чарасы буларак та очрый. Татар халык авыз иҗатында, мәсәлән, дастаннарда («Мешәк Алып», «Таһир-Зөһрә» һ.б.), әкиятләрдә, мәкальләрдә («*Кара* төс – караңгы төс») бозым белән бәйле йолаларда һәм халык сынамышларында да тискәре эчтәлектә ачыла.

Моның белән берлектә, кайбер әсәрләрдә һәм сынамышларда уңай мәгънәләре дә очрый. Мәсәлән, «Таһир-Зөһрә» дастанындагы баш геройга ярдәмгә килүче *кара ат* яки яңгыр яудыру өчен *кара* төстә *сыер* корбан итү кебек күренешләр кара төснең ике төрле эчтәлеккә ия булуын күрсәтә.

Галимҗан Ибраһимовның «Диңгездә» хикәясендә язучының романтик каләме диңгез пейзажы белән шәһәр тормышын тасвир иткәндә бер-беренә капма-каршы булган төсләргә мөрәҗәгать итә. Тормышта гаделлекне таба алмау сәбәпле төшенкелеккә бирелгән, үзен ялгыз хис иткән геройның эчке дөньясын тасвир иткәндә күбрәк кара төсне сайлый. Кара төс, беренчел төс булып, туры һәм күчерелмә мәгънәдә дә, шул ук вакытта *кара* сүзеннән ясалган *караңгы, караңгылык*, *карачкы* кебек сыйфат яки исем сүз төркеме буларак та кулланылган. *Карачкы, караңгылык* кебек тасвирлар романтик «мин»нең шәһәр мәдәниятенә, ирекккә сусаган шәхеснең рухын изүче җәмгыятькә мөнәсәбәтен белдерүдә кулланылган символик образ вазифасын үти. «Без алга киткән саен, артыбыздагы шәһәр, лиман, андагы карабллар, манаралар, ерактан җилбердәп торган аклы-кызыллы байраклар җиргә бата баралар; аларның өстенә чыккан *кара-күк* томан, без диңгезнең эченәрәк киткән саен, калыная, ярны, андагы *карачкы*лыкларны үзенә йота бара» [2: 65]. Әсәрдә шулай ук кара төснең *«кара-сары», «томанлы кара»* кебек төрле төсмерләре дә кулланылган.

*Кара төс* хикәядә башлыча предметны яки күренешне ачыклаучы эпитет яки метафора функциясендә килә: мәсәлән, «дөньяны каплаган *кара пәрдә*», диңгез «*авыр кара төстән* чыгып» һ.б. Диңгездәге төн вакытын тасвир иткәндә язучының каләме бу төсне мөмкин кадәр мул кулланырга тырышкан: «Һәммә нәрсә *кара, караңгы*; җәйге-көзге төннәрдә генә була торган калын, куе *караңгылык* бөтен тирә-якны йоткан; диңгез, су, бөтен дөня үзе шул гәүдәләнгән *караңгылык* төсле тоела» [2: 67]. Төнге табигатьне сарып алган караңгылыкны кабатлау юлы аша язучы романтик хикәяләүченең күңел дөньясын биләп алган караңгылыкны һәм төшенкелек хисен көчәйтә төшкән. «Дивар кебек *каты караңгылык*», «өстебезгә түшәлгән күкнең *куе караңгылыгы*» кебек үрнәкләрдә караңгылык сүзе *каты* һәм *куе* сыйфатлары аша тагын да «караңгылаштырылган», романтик «мин» өчен бетмәстөкәнмәс газап, хәсрәт һәм үлем дөньясының чагылышына әйләндерелгән.

Хикәядә *кара төс* башка функциядә дә кулланыла. Мәсәлән, «Ләкин Нурый *кара эшне, кара халыкны* яратмаганга һаман да мулла, мәдрәсә, мәчет тирәсендә берәр хезмәт эзли» [2: 71] җөмләсендә халык сөйләмендә еш кулланыла торган *кара эш, кара халык* кебек тотрыклы сүзтезмәләр булып килә.

**Кызыл, кызгылт-сары һәм сары.** Кояшның һәм бөтен сугыш тәңреләренең төсе булып саналган *кызыл* – ут, хөкемдарлык, мәхәббәт, хаз һ.б. кебек төшенчәләрне белдерүче төс буларак билгеле. Ялкын төсенә охшаш булуы сәбәпле, *кызыл төс* дәүләт байракларында еш кулланылган. Элек заманнарда каганнар утырган утарларларда кызыл байрак асылган [8: 36–37]. Төрки халыкларның культурасында, җир һәм күк тормышы белән бәйле хикәятләрдә урын алган бу төс каршылыклы эчтәлеккә ия, ягъни ул уңай да, тискәре дә була ала. Ал һәм кызыл төсләр төркиләр тарафыннан төрле чорларда бер төс булып кабул ителгән һәм берүк мәгънәдә кулланылган. Б. Өгел бу төсләрнең төрле төс булуын ассызласа да [8: 401], Решат Генч ал төсне кызыл төс итеп бәяли һәм кызыл төснең төркиләр өчен «рухи һәм милли төс» булуы турында яза [6: 1083–1084]. Төрки мифологиядә киң таралган Албасты иясе яки Ал байрак кебек төшенчәләрнең тамырындагы ал төсенең ачыкламасын бик күп төрек галимнәре (А. Инан, Р. Генч һ.б.) борынгы халыклар өчен сакраль булган ут төсенә ишарә итү сәбәпле барлыкка килүен белдерә. Я. Чоруһлу «кызылны ялкын төсе яки кызыл төскә тартым алтын төсе итеп кабул итәбез», ди [5: 223]. Бу галимнәрнең фикерләреннән аңлашылганча, кызыл төснең көче ут-ялкын төсенә охшаш булуыннан, бу да үз чиратында утны изгеләштерүдән килә. Чөнки борынгы кешеләр утны күктән – тәңре катыннан иңдерелгән чакма таш ярдәмендә чыгарганнар.

Төрек галиме Җаһит Сунар исә үзенең бер мәкаләсендә «Яктылык һәм җылылыкныкы кебек, төсләрнең дә чыганагы – нур, кояш. Нурның, кояшның төп өч төсе бар: *кызыл, сары,* зәңгәр» [9: 269] икәнен ассызыклап үтә. Бик күп мәдәнияттә кешелек дөньясы өчен яшәү чыганагы саналган ут кебек кояш та изге кабул ителгән, аңа да табынганнар. Кояшка хас булган алтын, сары, кызыл кебек төсләр сакраль төсләр саналып, дәүләт структурасында, Я. Чоруһлу язганча, Кытайда VI. гасырда империя төсе итеп кабул ителгән, хөкемдарларның һәм дин кешеләренең киемнәрендә еш кулланылган [5: 230].

Башка төрки халыклардагы кебек, татар халкының фольклор әсәрләрендә, көндәлек тормышында һәм матур әдәбиятында аеруча кызыл төснең аерым бер урыны бар. Аеруча Совет чорында идеологияне чагылдыручы символик төс (*кызыл гаскәр, кызыл байрак, кызыл әдәбият, кызыл авыз* һ.б.) буларак өстенлек алды. *Сары төс* алтын төсе дип, уңай мәгънәдә куллану белән бергә, халык арасында кайгы һәм сагыш төсе буларак киң таралган.

Г. Ибраһимовның хикәясендә *кызыл* һәм *сары* төсләр, нигездә, кояш образына бәйле рәвештә берлектә файдаланылган. «Бөтен тирә-ягын *кызыл-сары утка* күмеп су төбеннән олы кояш

чыга», «Шәфәкъ ягы *кызгылт сары төсе* белән яна». Яки «су өсте кояш баеганнан була торган *кызыл* ут төсеннән кара-*сарыга*, бара торгач, томанлы карага әйләнде» [2: 65]. Кояш бату вакытында төсләрнең бер-бер артлы үзгәреше (кызыл ут – кара-сары – томанлы-кара) язучы тарафыннан оста тотып алынган һәм тәэсирле бер картина пәйда булган. Төрки халыкларның ышанулардагы кебек, Г. Ибраһимов та кояшны олылый, кызыл һәм сары кебек төсләр аша аның әһәмиятен һәм дәрәҗәсен көчәйтә төшкән.

Айны тасвир иткәндә дә язучының төрле төсләр белән уйнавы күренә: «Ул башта *кызгылт-сары*, соңра *аксыл-сарыга*, ахырдан *көмеш кебек ак нурга* әйләнә дә, бөтен дөньяга, җәфа чиккән һәммә җаннарга сөеп, иркәләп карап, акрын гына киң күк эчендә йөзеп китә» [2: 67].

Хикәядәге бер җөмләдә эпитет вазифасындагы ут образын кызыл төснең контекстуаль синонимы итеп кабул итәргә мөмкин: «Яшеннәр өзлексез уйныйлар, җир-күкне каплаган катлаулы болытларны ярып, уңнан, сулдан *утлы сызыклар* сызгалыйлар» [2: 74]. Күктән төшерелүенә ышанылган ут, борынгы халыклар тарафыннан изге саналган, гаилә учагын саклаучы, начарлыклардан чистарту чарасы буларак кабул ителгән.

**Күк.** Диңгезне тасвир иткәндә язучы *күк* төсенең кимлек дәрәҗәсен куллана: *«күгелҗем* шома диңгез», *«күгелҗем* су өсте». Ул эпитет булып килә. Бу төс үз исемен төркиләр өчен сакраль саналган күк йөзеннән алган. Татар фольклор әсәрләрендә бу төс изгеләштерелгән, мәсәлән, «Акбүзат йолдыз, *Күкбүзат* йолдыз, Тимерказык бер ялгыз» мәкалендә моны күрәбез. Җир йөзендәге әйберләр өчен дә кулланылган *күк* яки *күгелҗем* төсләре, Күк тәңресенең җир өстендәге чагылыш итеп тә карага мөмкин. Г. Ибраһимовның хикәясендә күкнең диңгез өстенә чагылышы нәтиҗәсендә күгелҗем төсе барлыкка килгән һәм кешелек өчен әһәмиятле саналган суның да төсен изгеләштергән.

Диңгезнең һәм кешенең катлаулы психологиясенең төрле халәтен яктырткан «Диңгездә» хикәясендә, күп төрле тел-сурәтләү чаралары белән бергә, төсләрнең дә аерым функциягә ия булуы күренә. Язучы төсләрне ике максатта – диңгез пейзажын чагылдыру һәм геройның хис-кичереш хәрәкәтен тәэсирле итеп җиткерү өчен файдаланган. Романтик хикәяләүченең психологик халәтенә бәйле рәвештә, хикәядә ак һәм кара төсләргә, күк җисемнәрен тасвир иткәндә кызыл һәм сары кебек төп төсләргә мөрәҗәгать ителгән. Бу төсләрнең күбесенең нигездә асыл һәм кимлек дәрәҗәләре кулланылган. Шулай ук *ак* сыйфатыннан ясалган *агару* фигыле, *кара* сыйфатыннан – *караңгы, караңгылык, карачкы* кебек сыйфат һәм исемнәр; *кара* эш, *кара* халык кебек тотрыклы сүзтезмәләрнең урын алуын күрдек. Г. Ибраһи-

мов – төсләрне туры мәгънәдә куллану белән бергә, күчерелмә мәгънәдә дә оста файдаланган язучылардан. Гомумән, матур әдәбиятта язучы кулланган төсләрне өйрәнү аша авторның дөньяга карашын һәм әсәр героеның характерын ачыклауда кызыклы нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин.

ӘДӘБИЯТ


1. Заһидуллина Д. Галимҗан Ибраһимов // Татар әдәбияты тарихы, Сигез томда. 4 том. XX йөз башы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – Б. 108–130.

2. Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда. I том. Хикәяләр (1907–1929). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – 508 б.

3. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре: мәкальләр җыелмасы: 3 томда. I т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 566 б.

4. Çopur Y. (2021), Hulki Aktunç’un Öykülerinde Renklerin Kullanımı, Akademik dil ve edebiyat dergisi, Cilt 1, Sayı 1. – S. 195–206.

5. Çoruhlu, Y. (2012), Türk Mitolojisinin Ana Hatları, Kabalcı Yayınları, İstanbul, 271 s.

6. Genç, R. (1997), Türk İnanışları ile Milli Geleneklerinde Renkler ve Sarı Kırmızı Yeşil, Erdem dergisi, sayı 27. – S. 1075–1110. Ankara.

7. Kanat, A. (2001), Renk ve Duyu Psikolojisi, İlya Yayınları, İzmir.

8. Öğel, B. (2000), Türk Kültür Tarihine Giriş, 6 Cilt, Ankara: Kültür Bakanlığı. – 538 s.

9. Sunar, C. (2003); Tasavvuf Felsefesi veya Gerçek Felsefe, Anadolu Aydınlanma Vakfı Yayınları, İstanbul.

10. Yıldırım, A. (2006) Renk Simgeciliği ve Şeyh Gâlib’in Üç Rengi Milli Folklor. Sayı 18. – S. 129–139.

11. Yıldız, Ç. (2017), Kazan Tatar Türklerinin Mitolojisi, Yayınlanmamış Doktora Tezi, Adıyaman Üniversitesi Sosyal Bilimler Enstitüsü. – 216 s.

12. Zaripova Çetin, Ç. (2018). XX. Yüzyıl Kazan Tatar Edebiyatı, Kitap / Türk Dünyası Çağdaş Edebiyatları El Kitabı, Kesit Yayınları, İstanbul. – S. 569–815.


УДК 801.73

# ТЕМАТИЧЕСКАЯ СХОЖЕСТЬ И ОТЛИЧИЯ В ТВОРЧЕСТВЕ Г. ИБРАГИМОВА И К. БИККУЛОВА

***Ф.З. Яхин***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье проводится сравнительный литературоведческий анализ рассказов Г. Ибрагимова «Начало весны» и К. Биккулова «Облако забирает змею». В обоих рассказах главным героем является шакирд, который учился в медресе, вернулся в свою деревню и оказался в кругу невежественных ребят. Наступает гроза. Мальчики рассказывают друг-другу народные сказки и мифы о змеях, драконах, грозе. У Г. Ибрагимова от этих рассказов главный герой сильно пугается и у него от этого помешается сознание, а в рассказе К. Биккулова шакирд объясняет своим друзьям о несостоятельности легенд о змеях, драконах, грозе, излагает природным явлениям научные объяснения, показывая свою образованность.

**Ключевые слова:** рассказ, мистические представления, мифические существа, информация, информированность, просветительство, экспрессионизм.

The article presents a comparative literary analysis of the stories of G. Ibragimov «The Beginning of spring» and K. Bikkulov «The Cloud takes the snake». In both stories, the main character is Shakird, who studied at a madrasah, returned to his village and found himself in a circle of ignorant children. A thunderstorm is coming. The boys tell each other folk tales and myths about snakes, dragons, thunderstorms. G. Ibragimov from these stories the main character is very frightened and his consciousness will go crazy from this, and in K. Bikkulov's story shakird explains to his friends about the inconsistency of legends about snakes, dragons, thunderstorms, expounds scientific explanations to natural phenomena, showing his education.
**Key words:** narrative, mystical representations, mythical creatures, information, awareness, enlightenment, expressionism.

## Г. ИБРАҺИМОВ ҺӘМ К. БИККОЛОВ ИҖАТЛАРЫНДА ТЕМАТИК АВАЗДАШЛЫК ҺӘМ АЕРМАЛАР

***Ф.З. Яхин***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (Казан)*

1907 елда Казанда Касыйм Бикколовның «Гайнел-тәрәккый» («Алгарыш чыганагы») исеме белән хикәяләр, хәбәрләр, тезмәләр һәм «Казакъ мәгыйшәте» романы (40 әсәр) аерым китап-җыентык рәвешендә басылып чыга. Форматы, төзелеше белән ул «лубок китабы» төренә карый. Бу хакта аның колофонында да хәбәр бирелә. Анда «Сабйаннар[1] өчен гаять гүзәл хикәятләр, гаҗәеп хикмәтләр, гараиб[2] гыйбрәтләр, төрле шигырьләр язылмыштыр һәм ахырында «Казакъ мәгыйшәте» нам[3] руман язылмыштыр. Әсәр мулла Касыйм бине мулла Ж. Бикколов Әт-Тинчәле» диелә [1: 1].

Китап «Мәтбагаи-Кәримийә Казанда» бастырылган, «кәнде мосарифлары илә» (ягъни «үз акчалары белән») дигән хәбәре дә куелган.

Китапның башында «Китаптан элек – авыл байларына хитап[4]» [1: 2–3] тезмәсе урнаштырылып, аның барлыгы-юклыгы ахыргы сәхифәсендәге «Фәһрисат»та («Эчтәлек»тә) [1: 58] күрсәтелмәгән. Басманың эшләнешенә бәйле күзәтүләрдән берсе – кайбер ас төшермәләрнең төп текстта номерлары булып та, сәхифә астында үз урыннарында очрамаулары бу хитапның да тупланма җыелып беткәннән соң, язылып, басмага тәкъдим ителеп, ашыгыч урнашты-

[1] Сабйаннар – сабыйлар.
[2] Гараиб – сирәк, әһәмиятле.
[3] Нам – исемле.
[4] Хитап – өндәмә.

рылганын төшенергә юл ача. Аннары, аның эчтәлеге дә җыентыкка алынган әсәрләрдән гомуми эчтәлек ягыннан аерылып тора, яңача, хәтта заманча, 1905 елдан барлыкка килгән юнәлештә төзелгән.

Хитап касыйдә жанрында язылган, авыл байларына чакыру-мөрәҗәгать буларак яңгырый. Милләтнең алга китүе хәбәрдарлыгына бәйле булуына, ә хәбәрдарлык ул – мәгърифәт эше, аң-белемгә килгәндә, анысы да мәгърифәтсез калганда табылырга мөмкин түгел икәнлеге төшендерелә. Автор шуннан соң мәгариф эше мәсьәләсенә күчә, аның чыгымнар таләп итүе, шуңа да «кулдан алтыннарны чыгару» вакыты җитүе белдерелә. Җиткерергә теләгән сүзен ачык аңлатып, поэтик чаралардан, рифма-ритмны саклау белән бергә К. Бикколов шушы хитабын, төрле дәрәҗәдәге чагыштырулар ярдәмендә, мәсәл алымнарын да файдаланып, тулы канлы тезмә әсәр рәвешенә китереп иҗат иткән. Автор мәгърифәтне хәбәрдарлык буларак аңлаган, ягъни аның, мәгърифәтнең, яңа тормыш, һәртөрле җайланмалар, кораллар, инженерик корылмалар ясау һәм төзү өчен кирәклеген төшенеп фикер йөртмәгән.

Ахырда ул:

Сукыр мулла, аксак хәлфәдән ни файда –
Мәктәбе череп тәмам ауган белән, –

дигән сүзләр белән фикерен тәмамлый [1: 2].

Шушы җыентыкка кертелгән «Болытның елан алуы» [1: 25–56] хикәясе 27 номер белән бирелгән, «Казакъ мәгыйшәте» әсәре 40 сан белән урнаштырылган. К. Бикколовның «Казакъ мәгыйшәт»е романы Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы»на казах халкы тормышына бәйле булуы белән аваздаш. Аларда башка уртаклык юк. Ә менә «Болытның елан алуы» хикәясе белән Г. Ибраһимовның «Яз башы» әсәрендә уртак һәм охшашлар якларны шактый күзәтергә була.

Г. Ибраһимовның «Яз башы» хикәясе 1910 елда басылган (Казанда «Мәгариф көтепханәсе» басмасында 5 нче китап булып бастырылып чыгарылган [2: 497]. Әмма китапның үзендә басылган елы төгәл күрсәтелмәгән. Шунлыктан «1910 елда басылган» дигән ул хәбәр фәндә фарзыйлар исәбендә саналырга тиешле даталардан берсе булып кала бирә. Әдипнең Сигез томлыгының (аны, өстәп тугызынчы томы бастырылып чыгарылу сәбәпле, 9 томлы буларак та атыйлар) «Искәрмәләр һәм аңлатмалар» бүлегендә «Яз башы»-на бәйле бирелгән мәкаләдә, томга текстларны әзерләүче һәм искәрмәләр-аңлатмаларны төзүче Р.Р. Гайнанов: «Китап ахырында “Казан, июнь, 1910 нчы ел” дигән сүзләр бар» дигән мәгълүмат та бирә, әсәрнең икенче исеме «Бер шәкерттән хикәят» булуын, ә беренче исеме, ягъни «Яз башы», җәяләр эчендә генә бирелүен дә искәртә [2: 497]. Бу факт, хикәянең асыл исеме «Бер шәкерттән

хикәят» булганда, җисеменә дә туры килеп торуын аңларга ярдәм итә. Моның белән хикәянең эчтәлегеннән чыгып та килешергә кала. «Яз башы», югыйсә, әсәр исеме буларак, артыгы белән гомуми килеп чыккан, эчтәлекне дә ачып бетерә алмый. Шулай да ул әдәби яңгырашы белән матур, җәлеп итеп торучан булуы белән кызыклырак. Һич бәхәс юк, Г. Ибраһимов әсәрләренә исемнәрне оста, алардан да чын әдәби яңгырашлыларын сайлый белгән.

Бу ике әсәрдә дә төп геройлары – шәкерт, аның янында ярдәмчел каһарманнар – авыл малайлары. Г. Ибраһимовта алар балык тотарга баралар һәм давыллы яңгыр астында калалар. К. Бикколов хикәясендә дә давыл, аның ничек туфан булып күтәрелүе, бу хәлне авыл малайларының елан, юха образлары аша күзаллаулары тасвирлана. Әмма аның шәкерте һәм авыл малайлары чиләкләр тотып җиләккә китәләр.

К. Бикколовның 1907 елда ук басылган бу хикәясендә шәкерт хәбәрдар-аңлы-белемле итеп күрсәтелә. Авыл малайларына да ул һава агымнарының каршылыклар аша йөреп бөтерелүе сәбәпле «шайтан баганалары» барлыкка китерүләрен аңлатып, шушы әйләнгеч туфан баганалары эчендә бернинди дә еланны болыт алмавын, юха һәм башка мифологик күзаллаулар турындагы әкиятләрнең әбиләр тарафыннан уйлап чыгарылган булуларын төшендереп бирә. Мондый аңлы, белемле, хакыйкатьтән мәгълүматлары киң шәкерт укучыны сокландыра, билгеле. Белемле кешенең табигать стихиясе каршында куркып калмавы, тормышка аңлы карашы, белеп бәя бирүләре әсәрдә тигез агымда һәм матур ачыла.

К. Бикколов, әсәрләреннән аңлашылганча, хәбәрдарлык дәвере вәкиле, укучыга да ул танып-белү ярдәмендә алынган асыл хәбәрне әдәби әсәрләре аша сөйләп аңлатып җиткерергә тели. Менторлык аның тормыш картиналарын бирүендә дә ачык чагыла. Ул тасвирлы сәнгати сөйләмне түгел, хәбәр итү алымнарын әдәби форма рәвешендә файдалана. Укучы аны аңлыймы, әллә язганнары укучыны бары тик аптырашта гына калдыралармы – әдип шул хакта да уйланырга тиеш, билгеле. К. Бикколов авыл малайларыннан аң-белемдә шәкертенең күпкә өстен булуын күрсәтер өчен давыл баганаларының ни-нәрсәләрне җирдән күтәреп, еракка илтеп ташлавын сөйләттерү формасын файдалана, табигать күренешләренең асылын фәнни хәбәрләрне бирү ярдәмендә ача. Г. Ибраһимовның «Яз башы» хикәясендәге шәкерт исә, киресенчә, нәкъ менә шундый ук күренешләр алдында куркып калган, шушы коты алынуда аңы киткән, саташкан бала итеп тасвирлана.

Аң-белем, мәгърифәт иделлары нигезендә бәя биргәндә, Г. Ибраһимовның шәкерте мәдрәсә сыйныфын бик яхшы билгеләргә генә тәмам итеп имтияз калган бала буларак, авыл балаларыннан тормышны аңлауда өстен чыгарга тиеш иде, югыйсә.

Әмма киресе килеп чыга. Хәбәрдарлык ягыннан, табигать белемнәрен үзләштерүдә аның өстенлеге бер дә юк, белемнәре тормыштан аерылган сыман аңлашыла. Аның шәкертеннән, бик яхшы укуына да карамастан, мәдрәсәдә белем алмаган авыл малайларының күзаллаулары һәм әкиятләре өстен чыгарылалар. Бу аңбелем, мәгърифәт, хәбәрдарлык идеалларының челпәрәмә килүе түгелме соң?

Г. Ибраһимов тасвирлы яза. Экспрессионистик алымнар аның каләменә хуҗа, хисне һәм хыялны «Яз башы» хикәясендә ул шулкадәр оста, камил итеп сурәтли, укучы аларның стихиясендә кала. «Яз башы» [2: 51–62] «Болытның елан алуы»ннан әдәби мәгънәләрдә күпкә киң һәм тасвирлы, әдәби әсәр буларак ул, иң тәүдә – сәнгать әсәре дәрәҗәсенә җиткерелгән мистик-мифологик хәбәрлекләрне дә үз эченә ала, икенчедән, әдәби мәгънәләр аңарда укучыны хәбәрдарлык идеалларына ирештерү түгел, бәлки хискичерешләр стихиясенең кеше рухы белән ничек уйнарга мөмкинлеген сурәтләүдән гыйбарәт. Икесен дә укыганда аң-белемнең һәм хәбәрдарлыкның кешелек җәмгыяте өчен әһәмияте зур булуын төшен тирән төшенәсең.

К. Биккулов хикәясендәге шәкерт иптәшләренә хәбәри мәгълүматларны җиткерүе сокландыра, аның аң-белем дәрәҗәсе менторлык кысаларында сурәтләп бирелә, тирән хәбәрдарлыгы авыл малайлары каршында хәтта акыллырак та икәнлеген тануга этәрә. Г. Ибраһимов та хәбәри мәгълүматларны сәнгатьчә алымнарга күчерү ысулларын файдалана, моның өчен сәнгати чараларга мөрәҗәгать итә, мәгълүматны сурәтлелек киңлекләренә күчерү юлларын таба, вакыйгаларны әдәби иҗат итә. Аның экспрессия алымнары фикерен укучыга җиткерүдә тойгы-хис үстерүче көч ролен башкара.

Г. Ибраһимов һәм К. Бикколов икесе дә гүяки бер үк вакыйгаларны укучыга сөйләп бирергә алыналар. Әдәбилек юлы белән сурәтләнгән акыллы, белемле, тырыш һәм тәүфыйклы шәкерте хорафи хәбәрләр тәэсиренә бирелү аркасында Г. Ибраһимов хикәясендә төп герое акылыннан шаша, рух һәм аң тетрәнүен кичерә, авырып егыла. Ә К. Бикколовның шәкерте хәбәрдарлык, аң-белем чикләрендә ачыла һәм укучы алдында акыллы, яхшы зиһенле, табигать көчләрен аңлаучы һәм аңлата алучы акыллы бала сурәтендә күз алдына килеп баса.

Охшаш сюжетка корылган ике әсәрне чагыштыру бу әсәрләрнең әдәби-иҗтимагый әһәмиятләрен хатасыз күзалларга ярдәм итә. Г. Ибраһимов та, К. Бикколов та талантлы язучылар. Аермаларына килсәк, алары хезмәт иткән әдәби идеалларына бәйле, К. Бикколов хәбәрдарлык хөкемнәре кысасында иҗатка алынган, шуңа да аның әсәрләрен мәгърифәтчелек реализмы юлында язылган

дигән фикергә китерәләр. Әмма бу инде, асылда, мәгърифәтчелек реализмы гына да түгел, бәлки хәбәрдарлыкны алга чыгару, төрле юнәлешләрдәге әһәмиятле белемнәрне укучыга төшендереп һәм аңлатып бирүгә корылган менторлык әсәре. Аларда сурәт һәм тасвирлар шактый фәкыйрь, әмма аң-белемне укучыга җиткерү урыннарында әдип каләменең бар осталыгын эшкә җигә, мондый әсәрләрдә маҗаралык әйдәүче көчкә әверелә. Андый әсәрләрдә, сәяхәт маҗараларыннан бигрәк, энциклопедик белемнәр белән бәйле бер хәбәрләрдән икенчеләренә кызыклы итеп тасвирлап күчә бару маҗаралык тудыра. Укучы гүяки аң-белемдә, аның сафлыгы тәэсирендә белемнән-белемгә, аң һәм танып-белү киңлекләрендә сәяхәт итә.

Г. Ибраһимов әсәрендә дә әдәби герое тәэсирләнү, хәбәрләрне җанлы сурәтләр итеп күз алдына китерү стихиясен кичерә, бу аның аңын, тойгы-хисләрен кайнату өчен җитә кала. Әлегә оешып кына килә торган аң хис экспрессиясе эчендә кала, кайнарланып адашу кичерә. Г. Ибраһимов мифологик күзаллауны түгел, шушы күзаллауның аңга, аң аша күңелгә тәэсире көчен сурәтли алган әдип буларак әдәби биеклеккә күтәрелә.

Кайсы әдәби ысул – хәбәр бирүме, экспрессик сурәт тудырумы уңышлы, дигәндә, икесе дә дияргә тиешбез. Аларның берсе икенчесен алыштыра алмыйлар да кебек. Әмма әдәбилек ягыннан бәяләгәндә – сәнгатьче буларак Г. Ибраһимов стиле югарырак тора, К. Бикколовның каләме – гадирәк, беркатлырак. Беркатлы булуының хикмәте шунда, белемнәребез барыбер дә чагыштырмача гына хаклылар, алар тирәнәя һәм катлаулана баралар, кичәге аңлатмалар бүгенге таләпләргә туры килмәве дә бар. Фән даими үсештә һәм эзләнүләрдә яши. Сәнгать дәрәҗәсенә җиткерелгән әдәби әсәрнең хакыйкатьләрен укучы да укыганы саен яңачарак ача бара, ул алдынгы фикерләрне тудыра торудан туктамый.

ӘДӘБИЯТ

1. Бикколов К. Гайнел-тәрәккый. – Казань: Типо-литография Т-го Д-ма «Братья Каримовы», 1907. – 58 б.

2. Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 1. Хикәяләр (1907–1929). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – 510 б.

# ПРОБЛЕМЫ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА В ТРУДАХ Г. ИБРАГИМОВА И РАЗВИТИЕ ЯЗЫКОЗНАНИЯ У ТАТАР В XX–XXI вв.

УДК 811.512

## ЛЕКСИЧЕСКАЯ СИНОНИМИЯ В ПРОИЗВЕДЕНИЯХ Г. ИБРАГИМОВА

***Э.Н. Денмухаметова***
*Казанский (Приволжский) федеральный университет (Казань)*

В работе рассматривается мастерство использования Г. Ибрагимовым лексических синонимов в своих произведениях. Приводятся комментарии из работ писателя, где он объясняет те или иные лингвистические закономерности в татарском языке. Каждая цитата Г. Ибрагимова подтверждается материалом из его произведений. Это дает возможность увидеть схожести и отличия функционирования синонимичных пар в татарском литературном языке и в языке писателя, и рассмотреть тенденции развития лексики литературного языка с начала XX по начала XXI вв.
**Ключевые слова:** татарский язык, синонимы, доминанта, Г. Ибрагимов, лексика, язык автора.

The paper examines the mastery of G. Ibragimov's use of lexical synonyms in his works. Comments are given from the writer's works, where he explains certain linguistic patterns in the Tatar language. Each quote by G. Ibragimov is confirmed by material from his works. This makes it possible to see the similarities and differences in the functioning of synonymous pairs in the Tatar literary language and in the language of the writer, and to consider the trends in the development of the vocabulary of the literary language from the beginning of the 20th to the beginning of the 21st centuries.
**Key words:** Tatar language, synonyms, dominant, G. Ibragimov, vocabulary, author's language.

## Г. ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ЛЕКСИК СИНОНИМИЯНЕҢ БИРЕЛЕШЕ

***Э.Н. Денмөхәммәтова***
*Казан (Идел буе) федераль университеты (Казан)*

Г. Ибраһимов – үз халкын, телен, тарихын һәм мәдәниятен яраткан, аның үсеше өчен фидакяр көрәшкән күпкырлы шәхес.

Шунлыктан, әлеге әдип турында сүз чыкканда, һәр өлкәне өйрәнүче галимнәр аны үзләренең остазы, юл күрсәтүчесе, кыю фикер белдерү өлгесе буларак карыйлар, фикерләренә күпләп сылтамалар китерәләр, кабат-кабат аларны шәрехлиләр. Галимҗан Ибраһимовның татар халкына бай әдәби мирас калдыруы мәгълүм. «Аның егермеләп хикәясе, өч повесте, дүрт романы һәм бер пьесасы өстенә, революцион хәрәкәт тарихы, әдәбият теориясе һәм тарихы, сәнгать һәм культура буенча аерым китап булып чыккан унике фәнни хезмәте, дүрт йөз иллеләп тәнкыйть һәм публицистик мәкаләсе, тел һәм әдәбият буенча уннан артык дәреслеге һ.б.» барлыгы билгеле. Шунлыктан әдип эшчәнлеге инде берничә дистә еллар дәвамында мөхтәрәм галимнәр тарафыннан төрле күзлектән чыгып өйрәнелүенә карамастан, ул әйткән фикерләрне барлау, әдипнең эшчәнлегенә заман таләпләреннән чыгып бәя бирү, әсәрләрен яңача анализлау һәм тирән фикерләрен аңлау, барлау бүгенге көндә дә дәвам итә, аларда бүгенге көн өчен дә актуаль фикерләр, материаллар һәм ситуацияләрнең чишелеш юллары табыла.

Г. Ибраһимов үлемсез әсәрләрендә XX йөз башы татар әдәби теле чагылышын теркәп калдыра, геройлары тормышы, уй-фикерләре аша үз халкының яшәешен сурәтли. Укучы әлеге әсәрләр белән танышу вакытында андагы вакыйгалар тасвирланышын гына күзәтми, ә татар теленең стилистик мөмкинлекләре, лексик байлыгы, грамматик камиллеген дә күрә. Әдип үз теле белән горурлана һәм аның киләчәге турында борчыла, камилләштерү юлларын эзли һәм күрсәтә, бу хакта төрле дәрәҗәдәге даирәләрдә ясаган чыгышлары вакытында да, вакытлы матбугат басмаларында да, тәнкыйди мәкаләләрендә дә кабат-кабат искәртә, үткен фикерләрен тел комиссияләренә җиткерә. Соңгы елларда Г. Ибраһимов мирасын барлап бастырылган фәнни хезмәтләргә тупланган материаллар бу фикерләрне янә дәлилли [1].

Галимҗан Ибраһимовның тел мәсьәләләрен күтәргән хезмәтләре арасында имля төзәтү, татар теленең сафлыгы, аңлаешлылыгы, тел нормаларын булдыруга караган «Татар сарыфы», «Татар нәхүе», «Татар имлясы», «Татар телен ничек укытырга?», «Тел сабаклары» һ.б. кебек хезмәтләре киң җәмәгатьчелеккә яхшы таныш. Аның татар терминологиясен үстерү турында әйткән фикерләре бүгенге көн күзлегеннән караганда да актуаль. Әдипнең тел белеменең таррак тармакларына карата фикерләрен яктыртып язылган махсус хезмәтләре булмаса да, контекстта һәр тармакка карата белдерелгән фикерен табарга мөмкин, чөнки тел берәмлекләре бер-берсе белән бәйләнештә генә тулы, камил сөйләм тудыра алалар. Г. Ибраһимов исә туган телен нәкъ шундый итеп күрергә тели. Ул «Татар телен җиңеләйтү мәсьәләсен чишәргә кирәк» исемле

мәкаләсендә «...Бездә ничә төрле тел, аталма, тәрҗемә комиссияләре, коллективлары булса, шул кадәрле юл, агым күренә. Боларның күбесе үзләренең тәрҗемәләрендә шул чаклы гарәбизмга чумалар ки, тик мәдрәсә шәкертләре генә аңлаячак, эшче-крестиәннәр һичбер төшенмәячәкләр. <...> Бу чуалчык хәлдән чыгарга кирәк. Матбугатның һәммәсен – гәзитен, журналын, китабын, декрет-карарларның барлыгын җиңел бер телгә салырга кирәк», дигән фикер белдерә [2: 259]. Шулай ук 1925нче елда язган «Татар телен җиңеләйтү турында тезислар»ында «...Татар әдәби теленең иң төп нигез материалы үзебезнең ана телебездән алынырга тиешле. Татарчада сүзләр була торып, болар урынына башка һичбер телдән һичбер сүз кертелмәсен. Татарчадан сүзләр табылмаган урынларда мәгънәнең теләве, ана теленең сөреше буенча: 1) татар тамырларындан яңа ясалма сүзләр төзелерләр (монда гыйльми дөрестлек һәм халыкка аңлаешлы булу ягына аеруча тукталырга кирәк); 2) борынгы онытылган сүзләрдән яки Русиядәге төрки кабиләләрнең безгә җиңел аңланырлык сүзләрендән алыныр» [2: 262], дип, әдип телдәге алынма сүзләрне куллануга үз фикерен, таләбен белдерә.

Шул ук вакытта катгый пурист дәрәҗәсенә дә төшми, чөнки шул ук мәкаләсендә чит телләрдән кергән (нигездә, гарәп һәм фарсы телләреннән кергән) берәмлекләргә карата искәрмәләрне күрсәтә: «... 1) Гарәпчәдән кереп тә, халык эчендә үз теле кебек үзләшкән сүзләр элеккедәй үз урыннарын саклыйлар (каләм, китап, дөнья кебек). 2) Әдәбиятыбызда киң рәвештә таралып, гражданлык алып, үз сүзләребез дәрәҗәсендә үзләшкән аталмалар, сүзләр, гарәпчәдән булсалар да, һаман да матбугатыбызда кулланылырлар (әсәр, шигырь, әдәбият...). 3) Исламның үзендә генә булып, татарча һәм башка телләрдә дә булмаган мәгънәләрнең аталмалары шул гарәпчә яки фарсыча рәвешендә йөртелер. 4) Мәдәни милләтләр эчендә уртак йөргән сүзләр, аталмалар урынына гарәптән яки фарсыдан алынмас, болар шул көенчә әдәбиятыбызда кулланырга тиешле (буржуазия, пролетариат, интернационал, техника кебек). 5) Югары урынларында сүзләр табылмаса, халык эченә кереп үзләшкән, үз теле кебек җиңел аңланып бара торган русча сүзләр, аталмалар әдәбиятыбызда кулланылырлар» дип яза [2: 262–263]. Шул рәвешле Галимҗан Ибраһимов татар телендәге чит тел сүзләрен куллану тәртибен күрсәтә. Бу үсә телдә мәгънәдәш сүзләрне файдалану кагыйдәсен булдыруга да китерә, чөнки автор үз әсәрләре мисалында шундый сөйләм үрнәкләре тудыра.

Г. Ибраһимов әсәрләрендә абсолют синонимнар (ягъни тулы синонимнар, яисә дублетлар) шактык очрый. Шунысын искәртеп үтәргә кирәк: мондый берәмлекләр, нигездә, авторның башлангыч

чор иҗатында урын алган хикәяләрендә урын ала. Мәсәлән, бәян итү – сөйләү; кояш – шамс; йөз – бит, чәһрә, чырай; Илаһ – Аллаһ, Алла, Ходай; гыйлем – белем, тел – лөгать; кадер – хөрмәт; яхуд – яки; мәдәни – культуралы – культурный һ.б. кебек берәмлекләрне «Яз башы», «Диңгездә», «Сөю – сәгадәт», «Уты сүнгән җәһәннәм» кебек әсәрләрендә очратырга мөмкин. Авторның сүзләрне болай файдалануын бертөрлелектән котылу чарасы итеп тә, шул чор сөйләм теленә якын булырга тырышуы буларак та аңларга мөмкин.

Бу хикәяләрдәге мәгънәдәш сүзләрнең семантикасы һәм стилистикасы, нигездә, субъект һәм объектларны белдерү белән аңлатыла. Әлеге берәмлекләр теге яки бу төшенчәгә бәя бирү, билгенең дәрәҗәсен күрсәтү вазифасын үтиләр, шул рәвешле әдәби тасвирлау тудыралар. Автор бәхет лексемасы урынына сәгадәт берәмлеген кулланып, яки сандугач урынына былбыл дип белдереп, ниндидер бөеклек, югары дәрәҗә турында белдерә. Бу очракта мәгънә үзгәрми, ләкин югары стиль, шигъри аһәң барлыкка килә. Мәсәлән, *«Бу вакытның хыялыңда да аерым бер тәм, бөтенләй башка булган бер ямь була; моны хис кыйлмаган адәмнәр зур бер* ***сәгадәттән*** *мәхрүмнәрдер дип уйлыйсың, аларны кызганасың»* («Уты сүнгән җәһәннәм», б. 122) яки *«Гүя ул безне, безнең күңелдәге ялкынны белә дә, адәм гомерендә бер генә килеп кичә торган мәсәлсез* ***бәхет*** *белән безне тәбрик кыйла, шуны бөтен дөньяга чәчә кеби хис кыйлына»* («Сөю – сәгадәт», б. 116); *«Тирә-яктагы барлык нәрсәләр, тәңренең* ***бәхетле*** *колы –* ***сандугачның*** *музыкасы тәэсиренә чумып, үлем тынлыгына бата һәм тыннарын эчтән алалар»* («Сөю – сәгадәт», б. 116). *«Беләмсең, ни ди* ***былбыл****?»* («Сөю – сәгадәт», б. 116) һ.б.

Г. Ибраһимов, алда әйтелгән мәкаләсендәгечә, үз әсәрләрендә рус теленнән кергән берәмлекләрне дә, интернациональ берәмлекләрне дә төрки-татар берәмлекләре белән матур чиратлаштыра белә. Рус берәмлекләрен актив файдалануын шулай ук чор модасы, тасвирлана торган күренешләрне белдерү чарасы итеп карасак, аларны татарча аңлатып бирүен авторның гади халыкка якын булырга теләве белән аңлатырга мөмкиндер. Мәсәлән, *«Син әле безнең яңа* ***фатирны*** *белмисеңдер; үзебезнең иске өйдә: капкадан керерсең дә, таш баскыч белән мнеп, сул кулга беренче ишеккә кагарсың»* һәм *«Шулай эченнән әрни-әрни, Вәли Хәсәнов* ***квартирына*** *кереп килсә, анда Мәрьямбикә балаларын мәктәпкә озаткан да, самоварын яңадан гөрләтеп, кайнатып, өстәлгә утырткан»* («Тирән тамырлар», б. 114); *«Шул мәшәкатьләр соңында, үзебезнең туган илгә бер ай* ***отпускага*** *кайтып киткән көннәрдә, Агыйделнең киң болыннарында чалгы тавышлары ишетелә башлаган...»* («Кызыл чәчәкләр», б. 474), *«Авылда бер ай тыныч кына хәл җыйсам,* ***чираттагы ял*** *вакытында камил тазарып җитәр-*

*мен дә, яңадан шул канлы көрәш өермәләре мине үз эчләренә тартып алырлар дип, Идел ярына басар-басмас, үз алдыма уйлап куйган идем»* («Кызыл чәчәкләр», б. 474) һ.б.

Әмма Галимҗан Ибраһимов әсәрләренең тел бизәге булып, һичшиксез, татар теленең үз берәмлекләреннән торган синонимнар тора. Автор аларны бер җөмлә эчендә дә, янәшә җөмләләрдә дә, бер абзац эчендә дә бик уңышлы һәм оста файдалана. Мәсәлән, *«Каты көрәш дулкыннары арасында минем җаным* ***рәхәтләнә,*** *йөрәгем үзенә* ***көч*** *ала,* ***гайрәт*** *ала»* («Кызыл чәчәкләр», б. 474)*»*; *«Бая гына каты* ***чәкәләшеп алган*** *Шәяхмәтнең бу* ***талашка җаны әрнеде****. Рәгыя җиңгәсенә дә, кылый күз картка да аның* ***күңеле рәнҗеде»*** («Тирән тамырлар», б. 16), *«Ләкин бик* ***нык****, бик* ***каты*** *китте»* («Яз башы», б. 57), *«Мин яшьтән үк* ***ямь*** *вә* ***матурлык*** *гашыйкы»* («Сөю – сәгадәт», б. 108) һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, әдипнең җор теле фикерне тирәнәйтү һәм вакыйгалар үстерелешен тасвирлауда мәгънәдәш берәмлекләрне уңышлы сайлавы белән кабат раслана.

Язучының синонимнарны куллануда тагын бер үзенчәлеге һәр укучының игътибарын җәлеп итәдер. Бу – парлы мәгънәдәш берәмлекләрне куллану. Автор аларны телдән әзер килеш тә ала, яңа вариантларны да ясый, һәм шул рәвешле сөйләмгә экспрессив төсмер кертә. Мәсәлән, *«****Аһ-зар****, фөрьяд куба, тәүбәләр, догалар, авыр ыңгырашулы күз яше бөтен корабны каплый.»* (*«*Диңгездә», б. 78); *«Әле дә* ***җил-давылдан****,* ***шау-шудан*** *әсәр юк»* («Диңгездә», б. 68); *«...Җигүле ат керсә, дугасы-ние белән югалыр, башы дисәң, тагы буеннан да хәйран, әйтерсең үз авырлыгын күтәрә алмый,* ***бөгелә-сыгыла*** *утырган зур чуклар, – шулай булып салынышып утыралар»* («Тирән тамырлар», б. 191) һ.б. Парлы синоним берәмлекләр хасил итүдә автор вә яки һәм теркәгечләрен дә еш файдалана, яңа төрләр тудыра.

*«Шулар белән* ***борчылып****,* ***җаныңны кая куярга аптыравың*** *җитмәгән кебек, тагы бөтен нәрсәсе белән сиңа каршы төшә!»* (*«Карт ялчы*», б. 148); *«Яшьлекнең бер дәверендә күп нәрсәгә ышанасың: алла диләр,* ***гадәләт****,* ***хакыйкать*** *диләр, һәммә кешеләрнең* ***сәгадәте*** *хакында сөйлиләр, мәгълүм бер шартлар буенча тезеленсә,* ***хәятта бәхет*** *булуын өмит итәләр – яшь һәрберсен саф җәүһәр дип кабул итә, һәм шуның белән аның* ***тормышы*** *мәгълүм бер дәвердә мәгънәле дә,матур да була»* («Мәрхүмнең дәфтәреннән», б. 206) җөмләләреннән күренгәнчә, Г. Ибраһимов бер җөмлә эчендә берничә синонимик берәмлекне, укучыны ялыктыру дәрәҗәсенә җиткермичә, уңышлы берләштерә ала: борчылып – аптырап; гадәләт – хакыйкать; сәгадәт – бәхет, хаят – тормыш. Әлеге мисаллар хәзерге әдипләребезгә үрнәк, күркәм өлге булып тора.

*«Бераздан соң теге калын урманлы, зур куәтле мөтәкәббир тау артыннан тулган ай күтәрелә башлый. Дөнья вә табигатькә яңа күрек, яңа матурлык арта. Айның бу нуры һәр нәрсәгә хыялый, мөзссир, ләкин бик мөлаем, гүзәл, шигъри һәм серри төс бирә»* («Сөю – сәгадәт», б. 116). Әлеге җөмләдәге куәтле һәм мөтәкәббир; күрек һәм матурлык; мөлаем һәм гүзәл лексемаларын көчле, зур, матурлык кебек уртак төшенчәләр берләштерә. Әмма автор тасвирында бирелгән сүзләр стилистик төсмерләре белән аерылып торалар: мөтәкәббир – иң зур дигәнне белдерә, күләмнең артыклык дәрәҗәсенә ишарә ясый; куәтле – көчле буларак аңлашыла, шулай ук югары дәрәҗәне күрсәтә; ә күрек сүзе сөйләм телендәге матур сыйфатын белдерә; мөлаем лексемасы йөз матурлыгын – чибәрлекне аңлатса, гүзәл – һәрьяктан матур, килешле булуны белдерә. Шулай итеп, Г. Ибраһимов тасвирлау объектын төрле яклап бизәп бирүгә ирешә.

Бер үк төшенчәне мәгънә уртаклыгы булган берәмлекләр аша тасвирлау ягыннан да Г. Ибраһимов чын осталык күрсәтә. Ул турыдан-туры хәбәр итмичә, кинаяле сурәт аша максатына ирешә: *«Мин дә, хәят күгеннән югалып, үлемнең караңгы кичәсе артына батармын, югалырмын»* («Сөю – сәгадәт», б. 106); *«Бу садә тормыш фәкать бу авылда гына булмыйча, бөтен тирә-якта гайн шул хәл хөкем сөргәнгә, төрле үзгәрүләргә вә чит якларга чыгып йөрергә иҗбар итәрлек эшләр булмаганга, алар күптән шулай яшәп киләләр, сату-алу, кәсеп вә һөнәргә кул сузмыйлар иде, чөнки мәҗбүрият юк иде»* («Йөз ел элек», б. 88) һ.б. Авторның сүзләр җыелмасын шул рәвешле оештырып бирә белүе, татар теленең камиллеген, ә әдипнең чын сүз остасы булуын кабат дәлилли.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: Галимҗан Ибраһимовның мәгънәдәш сүзләрне файдалану осталыгы, татар теленең камил, югары мөмкинлекләрен күрсәтте һәм бүгенге көндә дә сөйләм берәмлекләрен уңышлы куллану эталоны була ала.

ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһимов Г.Г. Милләт. Тел. Әдәбият: Сайланма хезмәтләр. – Казан: Мәгариф, 2007. – 239 б.

2. Ибраһимов, Г.Г. Әсәрләр: 15 томда .– 8 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1918–1933) . – Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – 431 б.

3. Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда. – Т. 1. Хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – 510 б.

4. Хасанов М.Х. Галимджан Ибрагимов: монография. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1977. – 432 с.

УДК 811.512.145

# КОЛОРАТИВНАЯ ЛЕКСИКА В ПРОИЗВЕДЕНИЯХ Г. ИБРАГИМОВА

***Г.Р. Мугтасимова***
*Казанский (Приволжский) федеральный университет (Казань)*

В произведениях Г. Ибрагимова колоративная лексика прежде всего выступает в прямом значении. При этом они обозначают цвет разнообразных предметов быта, окружающей среды, явлений природы. Помимо прямого значения цвета большую роль в творчестве Г. Ибрагимова играет переносное и символическое значения цветообозначений. Цветообозначения помогают создавать автору яркие красочные образы и картины.
**Ключевые слова:** татарский язык, колоративная лексика, художественный текст, идиостиль, Г. Ибрагимов.

In the works of G. Ibragimov, the colorative vocabulary primarily appears in the direct meaning. At the same time, they denote the color of various household items, the environment, and natural phenomena. In addition to the direct meaning of color, figurative and symbolic meanings of color meanings play an important role in G. Ibragimov's work. Color designations help the author to create bright colorful images and paintings..
**Key words:** Tatar language, colorative vocabulary, artistic text, idiostyle, G.Ibragimov.

# Г. ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ КОЛОРАТИВ ЛЕКСИКА

***Г.Р. Мөгътәсимова***
*Казан (Идел буе) федераль университеты (Казан)*

Классик әдип һәм журналист, күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, галим һәм укытучы, татар телендәге дәреслекләр авторы, тел белгече, тарихчы һәм сәясәтче, татар прозасында аерым бер урын алып торучы зур талант иясе Галимҗан Ибраһимов – әдәбиятыбызга үзенең хикәяләре белән килеп кереп, шактый зур әдәби мирас калдырган язучыларыбызның берсе. Язучының әдәби мирасы гаять зур әһәмияткә ия. Аның романтик һәм реалистик әсәрләре аша яңа буыннар татар халкы тарихындагы сәхифәләрне өйрәнә. Шулай ук Г. Ибраһимов әсәрләренең колоратив лексикасы тикшеренүләр өчен бай чыганак булып тора, димәк, мәсьәләнең актуальлеге бәхәссез. Бу мәкаләдә Г. Ибраһимовның 1913 елда дөнья күргән, роман жанрында беренче тәҗрибәсе булган «Яшь йөрәкләр» әсәрендә урын алган төс атамаларын тикшерү максат итеп куелды. Әлеге романга бәя биреп, галим Д. Заһидуллина, «…XX йөз башында иҗат ителгән олы эпик жанр үрнәкләре арасында фәлсәфи характеры белән аерылып тора» [1: 8] дип

билгеләп үтә. Романтик рухта язылган бу әсәрдә кулланылган колоратив лексика геройларның чынбарлык белән мөнәсәбәтен тирән психологизм белән тасвирларга ярдәм итүе бәхәссез.

Төсләрне кеше бу дөньяга килгән вакыттан ук күрә башлый. Һәр көнне, һәр мизгелдә төсләр белән очрашырга туры килә. Төс, һичшиксез, яшәү шатлыгын һәм канәгатьлек хисен арттыра. Ул психик һәм физик халәткә тәэсир ясый. Бу әдәби әсәрләрдә дә чагылыш таба. Матур әдәбият әсәрләрендә колоратив лексика авторның фикере чагылышын белдерә. Ул сүзнең мәгънәсенә генә түгел, ә язучы психологиясенә дә үтеп керергә мөмкинлек бирә, әсәрне язу вакытында язучының эмоциональ халәтен аңларга ярдәм итә. Төс атамалары символларга, чагыштыруларга, метафораларга әверелә, алар авторның тасвирлана торган предметка яки күренешкә мөнәсәбәтен күрсәтә. Һәр колоризм матур әдәбият әсәренең төсләр картинасында үз урынын биләп тора. Төс атамаларын куллану үзенчәлеге автор стилен билгели. Теге яки бу төс атамасының сайлануына билгеле бер тематика, проблематика һәм авторның тәэсирлелеккә ирешү юлы сәбәпче була.

Чыннан да, төс аталамалары тел системасында (бигрәк тә әдәби текстларда) шактый зур урын били. Төсләр, төс эпитетлары әдәби әсәрләрдә мәгълүмат тапшыру өчен кулланыла. Шул рәвешле, текст ул – әдәби бөтен, ә төс аның элементларының берсе булып тора. Төсне тикшерү төс тәкъдим ителгән барлык сәнгать чараларын анализлауны күздә тота. Төс атамалары тикшеренүчеләр тарафыннан төрле аспектларда өйрәнелгән. Колоратив лексиканың составы, аның семантик структурасы тасвирланган. Этнолингвистик, чагыштырмача-тарихи һәм психолингвистик аспектларда үткәрелгән тикшеренүләрнең дә булуын искәртеп үтәргә кирәк.

Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романында колоратив лексиканың кулланылышын тикшергәндә, әлеге берәмлекләрнең сүз төркемнәре ягыннан бирелеше дә кызыксындырды. Төс мәгънәсенә ия булган берәмлекләр арасында сыйфатлар (*кызыл, кара, соры, ак, ала, караңгы* һ.б.), исемнәр (*каралык, караңгылык, яшеллек*) һәм фигыльләр (*кызарырга, агарырга, каралларга, чобарларга* һ.б.) булуы ачыкланды. Әлбәттә, иң күпсанлы төркемне сыйфатлар тәшкил итә. *Шәмәхә, чуар, ала, кола, коба* сыйфатлары исә романда чагылыш тапмаган.

Кызыл һәм аның төсмерләре – «Яшь йөрәкләр» романында иң киң кулланылган төс атамаларының берсе: *кып-кызыл, кызыл, кара-кызыл, кызыллы-сарылы.* Романда кулланылган кызыл төснең функциональ билгеләнеше түбәндәгечә:

1) персонажның портреты: <...> *хәзер мулланың төсе үзгәрә, **йөзе ачудан кара-кызылга** бүртеп, угылларына кул селкә дә үз*

*һөнәрен чәчәргә тотына; <...>* ***кызыл вә симез йөзле***, *зур буйлы, җуан корсаклы бер старшина да бар иде.*

2) кием-салым: *<...> бүрекне кырын салып, җыртык бишмәтнең кесәсеннән* ***кызыл яулыкның*** *очын тышка салындырып йөри торган көяз вә мөтәкәллиф егетләр <...>; Әнә иннек, кершән белән* ***кызыл читле шәлдән*** *башканы кайгырта белмәс шикелле тоелган кызлар; Җылтыр кара бишмәтнең бер кесәсеннән* ***кызыл өстенә*** *ак дебет белән эшләнгән, <...> ике кульяулыкның салынып торуы егеткә тагы бер аерым көязлек бирә; <...> мулланың янына* ***кызыл яулык*** *җәеп куйды.*

3) табигать, әйләнә-тирә дөнья күренешләре: *Шунлыктан тирә-якта моны «кызыл өй» дип йөртәләр; <...> бик киң һәм иң соңгы мода белән эшләнгән зур* ***кызыл сөлгеләр*** *асылып, өйнең <...> аерым бер тулылык бирә.*

4) табигать стихияләре: ***Кара кызыл ут*** *белән ялкынланган шәфәкъ тә сүнеп бара.*

Романда кызыл сыйфаты туры һәм күчерелмә мәгънәдә метафора составында киң кулланыла: *<...> мин, бу* ***кызыл авызлардан*** *ерак качыйм дип, тиз генә сыздым» <...>; Ул бер вакытлар,* ***кызылларга катышып***, *халык эше белән дз йөрде.* Шул рәвешле, метафора составындагы кызыл төс һәм аның төсмерләре көрәшне, шул чор татар мохитен сурәтләргә ярдәм итә.

Роман метафорик мәгънәгә ия кара һәм караңгы төсләргә бик бай. Автор *кара, караңгы, караңгылык, каралык*, *чем-кара, том-кара, карасу* берәмлекләрен бик оста файдалана. Әлеге сүзләр түбәндәге очракларда кулланыла:

1) персонажның тышкы кыяфәтен тасвирлаганда: *<...>* ***кара күзле*** *бер башкорт малае килеп кушылды <...>; <...>* ***кара һәм караңгырак***, *өстәвенә катырак та йөзле бер адәм;*

2) табигатьне тасвирлаганда: *Җир өстендә тупрак та, таш вә* ***каралык*** *та юк <...>; <...> Хәйриләрнең зур* ***кара этенең*** *өстемә өреп килгәнен күреп, куркып уяндым; ... зур* ***кара урманнар*** *белән чолганган булган; <...>* ***том-кара ат*** *<...>; <...>* ***төсе чем-кара*** *<...>; Күк йөзе әллә нинди* ***карасу <...> болытлар*** *белән капланып, дөнья тарайды; <...> калын катлаулы* ***кара болыт*** *артына кача; Кичә күк* ***кара, караңгы*** *һәм <...> карлы-бозлы яңгыр ява иде.*

3) кием-салымны тасвирлаганда: *<...> башында <...>* ***кара түбәле фуражка*** *<...>; <...>* ***кара чикмәннәр*** *кидермәкче; <...> кыска,* ***кара киемле***, *ялтыр итекле, озын чәчле бер егет; <...> өстенә утырма якалы зур* ***кара толып***, *<...> кигән; Җылтыр* ***кара бишмәтнең*** *бер кесәсеннән <...> салынып торуы егеткә тагы бер аерым көязлек бирә; Баштанаяк* ***кара сарык йонына*** *уранган, <...>бәндәләргә карасаң, тагы башка бер халык күргәнеңне сизәсең* һ.б.

4) әйләнә-тирә дөнья күренешләрен тасвирлаганда: <...> *бөтен тирә-як* ***кара пәрдә*** *илә чолганып, чәчәкләр* ***кара көйде; кара кан*** *кебек каты ясап куфи эчәргә тотынды;* ***кара корымдай*** *бер сыйфатка керде* <...>; <...> ***караңгы төннәр****, зур* ***кара көймәгә*** *җигелгән зур* ***кара атлар****, Сабирнын, аның гакыллы угылы Сабирнын, шул көймәгә курыкмыйча утырып, әллә нинди* ***караңгы****, билгесез дөньяга кереп китеп югалулары берәм-берәм күз алдына килә.*

Язучы кара сыйфатын метафоралар составында да бик оста файдалана: <...> *ачы шималь җиле һәм зәһәр* ***кара суыкның*** *куәте җилекләреңә үтә китә; Без* ***кара кеше****.* Әсәрдә караңгылык бөтен тереклекне йота, билгесезлек, өметсезлек, үлем белән яный: ***Дөньяның караңгылыгы*** *куәтләнә, куркыныч арта бара шикелле;* <...> *бер минутта бөтен кяинат ниһаясе булмаган юклык* ***караңгылыгы диңгезенә*** *әверелер кеби тоела* һ.б.

Яшел романның стилистик программасында әһәмиятле роль уйнамый һәм локаль контекстта теге яки бу объектның төсен күрсәтү өчен генә хезмәт итә. Мәсәлән, әсәр дәвамында яшел төс, нигездә, көнкүреш предметларының төсен белдерү өчен кулланыла: *Йа Ходай, күрсәң исең китәр: залның түрендә өсте* ***яшел постау*** *белән ябылган бик озын өстәл тора; Хозыр Ильяс диярсең: ап-ак сакал,* ***яшел чапан****,* ***яшел читек****, кулда бик озын* ***яшел таяк****, башта саргылт чалма, аның да түбәсеннән очлаеп,* ***яшел тышлы бүрек*** *күренеп тора.*

Г. Ибраһимов яшел сыйфатын табигать күренешләрен тасвирлаганда файдалана: *Шунда көймәләр күренә; башка җирләре исә асыл агачлар,* ***яшел үләннәр****, матур чәчәкләр белән түшәлгән;* <...> ***җәйнең матур яшеллегеннән*** *соң, каралып, корып, тәмуг идәне төсенә әйләнгән кара, пычрак җир йөзе яңа яуган кырпак кар белән ак җәфәккә чолгангандай матур сыйфат алган;* <...> *табигатьнең* ***яшел келәме*** *өстендә утырамыз.*

Әсәр телендә ак төсен белдергән берәмлекләр аз кулланылган: *аксыл-алсу, ак, ап-ак*. «Яшь йөрәкләр» романында ак һәм аның төсмерләре түбәндәгеләрне тасвирларга ярдәм итә:

1) персонажның портретын: ... ***аксыл-алсу*** *йөзе һәрвакыт һәркемгә йомшаклык вә якынлык теләгән кебек күренә...; Хозыр Ильяс диярсең:* ***ап-ак сакал****,* <...>

2) көнкүреш предметлары, табигать, әйләнә-тирә дөнья, көнкүрешне: ... ләкин зур ала күзле, зур авызлы **акбүз бия**.

«Яшь йөрәкләр» романында өстәмә, аңлаешсыз мәгънәләр күздә тотылмаган объектларның төсен турыдан-туры атый торган берәмлекләр арасында *зәңгәр* дә бар: *Тирә-ягында әллә нинди* ***зәңгәрле****, сорылы* ***киемнәр*** *киенеп, медальле күкрәкләрен киереп, сары төймәле, кайсылары кылычлы, бик мәһабәт тугыз адәм утыра;*

*Аның өсте **зәңгәр постау** белән ябылган да, шунда әллә нинди кәгазьләр, каралар, каләмнәр ята.*

Сары төс кулланылган мисаллар да әсәрне тулаем кабул итүгә нигездә җитди тәэсир итмиләр: *<...> зур мәйданга җыелган халыкның шул дәрәҗәдә күплеге һәм аның, **сарылы**, аклы вә каралы төстә булып <...>; <...> аягына **сары бурка** белән резинка калуш кигән; <...> икенчесеннән көрән өстенә **сары белән чигелгән ике кулъяулыкның** салынып торуы егеткә тагы бер аерым көязлек бирә; <...> **сары төймәле**, кайсылары кылычлы, бик мәһабәт тугыз адәм утыра* һ.б.

*<...> тик йөземне каплаган үлем аклыгы катыш хәятсыз **сарылык пәрдәсе** калынаеп, яңакларым суырылган <...>* җөмләсендә сары төсе әсәр геройлары тормышында очрый торган чарасызлыкны чагылдырырга ярдәм итә.

Романда соры төс тә очрый: *Аның **күксу-соры күзләре** һәрвакыт һәрнәрсәгә югарыдан һәм мәртәбә белән карарга яраталар; Тирә-ягында <...> **сорылы киемнәр** киенеп, <...> тугыз адәм утыра; Күк йөзе <...> **соры болытлар** белән капланып, дөнья тарайды; <...> өстендә **соры шинель** <...>*. Әлеге сыйфат автор тарафыннан әйләнә-тирә чынбарлыкны тасвирлау өчен кулланылган.

Автор көрән, карасу көрән төсне белдерә торган *коңгыр* лексемасына бары тик бер җөмләдә генә никрутларның тышкы кыяфәтен тасвирлау өчен мөрәҗәгать иткән: *Нечкә **коңгыр кашлары** астыңдагы зур күзләр эчкәрәк батканнар.*

Ә менә *көрән* төсне Г. Ибраһимов дүрт урында – атның төсен һәм кулъяклыкны сурәтләгәндә файдаланган: *<...> икенчесеннән **көрән өстенә** сары белән **чигелгән ике кулъяулыкның** салынып торуы егеткә тагы бер аерым көязлек бирә; **Көрәнем** тегеләрне күз күреме җир калдырып килде...*

Төрле төсле мәгънәсенә ия булган чуар лексемасының диалекталь варианты чобар да роман текстында күзәтелде: *Урам кызыллы, **чобарлы** һәм туктаусыз хәрәкәт итеп торган **халык** белән тула; Зыя шул **чобар дөньяны** тамаша итеп йөридер иде. Абыстай чигеп эшләнгән зур **чобар намазлыкны** алып бирде.*

Ачык зәңгәр, зәңгәрсу соры төсләрне белдерә торган күк [3] Г. Ибраһимов яратып куллана торган төсләрнең берсе түгел: *<...> агач арасыннан әллә нинди **күк шинельле**, сары төймәле, кылычлы бер адәм килеп чыкты <...>; **күк төсле болан перчатканы** сул кулына алды.*

Кызгылт сары төс атамасы *җирән* дә «Яшь йөрәкләр» романында атның төсен белдерү өчен генә файдаланылган: *Малайга әйт, минем атны тугарып, зур **җирәнне җиксен** <...>.*

Роман текстында төс белдерә торган фигыльләр аз кулланылган: *кызарырга, акларга, чобарланырга*: *Зөләйха абыстай исә*

*мулласының шундый килешмәгән эше өчен кеше алдында* ***кызарып*** *җаны чыга...; ...теге егет хәзрәт өчен бәгъзан колакларынача* ***кызаргалый*** *иде; ... йөзе, әүвәлгедән дә* ***агарып****, бераз озынайган...; Шул тап аны* ***каралый****, <...>; <...> шуның алды* ***чобарлап*** *эшләнгән бик зур һәм яңа чаршау илә бүленгән <...>; <...> шома Идел өсте төрле төстәге көймәләр белән* ***чобарланды****.*

Шулай итеп, колоратив лексика 1905–1907 еллар революциясе йогынтысында халыкта – яшьләрдә – милли аң уянуын күрсәткән эчтәлекле әсәрнең сәнгать дөньясын аерым төскә буйый, геройларның образын, аларның рухи халәтен укучыларга тулы күләмдә тапшырырга ярдәм итә. Төс атамалары романда традицион тасвирлау, сурәтләү функциясен үти, бу бигрәк тә пейзаж һәм көнкүреш сурәтләрендә ачык чагыла. Г. Ибраһимов төс атамаларын бик уңышлы куллана, алар сурәт тәэсирен көчәйтү, сурәтләү катламыннан тыш символик, психологик, хисси катламнарга да үтеп керәләр.

ӘДӘБИЯТ

1. Заһидуллина Д. Язучы, галим, җәмәгать эшлеклесе // Мәгариф. – 2012. – № 2.– Б. 6–9.

2. Ибраһимов Г. Яшь йөрәкләр // https://vk.com/doc139424798_621137330?hash=1a331e7c5ca3e01be9&dl=f9f6251168af5f637a

3. Электронный фонд словарей // http://suzlek.antat.ru/wordsR.php?txtW=%D0%BA%D2%AF%D0%BA&submit

УДК 811.512.145

## ЭТНОКУЛЬТУРНАЯ ЛЕКСИКА В РОМАНЕ ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА «ДОЧЬ СТЕПИ»

***И.С. Насипов, А.Р. Рамазанова***

*Башкирский государственный педагогический университет им. М. Акмуллы» (Уфа)*

Статья посвящена рассмотрению языковых особенностей одного из лучших произведений Галимджана Ибрагимова «Дочь степи». Для раскрытия основной проблемы в работе представлена краткая информация о романе. Для анализа языковых особенностей был выбран лексический состав социальных терминов, раскрыта их роль в художественном произведении. Особо обращается внимание на ономастикон, при этом детально проанализированы антропонимы и топонимы, определена их роль в описании быта и жизнедеятельности казахского народа.

**Ключевые слова:** Татарская литература, Галимджан Ибрагимов, язык произведения, этнокультурная лексика, социальная терминология, ономастикон.

The article is devoted to the consideration of the linguistic features of one of the best works of Galimjan Ibragimov «Daughter of the Steppe». To reveal

the main problem, the paper provides brief information about the story. To analyze the linguistic features, the lexical composition of social terms was chosen, their role in the work of fiction was revealed. Special attention is paid to the onomasticon, while anthroponyms and toponyms are analyzed in detail, their role in describing the life and vital activity of the Kazakh people is determined.
**Key words:** Tatar literature, Galimjan Ibragimov, the language of the work, ethnocultural vocabulary, social terminology, onomasticon.

## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ «КАЗАКЪ КЫЗЫ» РОМАНЫНДА ЭТНОМӘДӘНИ ЛЕКСИКА

***И.С. Насипов, А.Р. Рамазанова***
*М. Акмулла исем. Башкорт дәүләт педагогия университеты (Уфа)*

Галимҗан Ибраһимовның эшчәнлеге күпкырлы: язучы, публицист, Шәрык галиме, тел һәм әдәбият белгече, мөхәррир, педагог, татар мәктәпләре өчен күпсанлы дәреслекләр төзүче, революцион хәрәкәт тарихын өйрәнүче шәхес, иҗтимагый һәм дәүләт эшлеклесе. Кайвакыт аның нинди өлкәдә эшчәнлегенә өстенлек бирергә икәнлеген хәл итү дә авыр була. Патриотлык хисе югары булу, халыкка кайнар мәхәббәт, аңа мөмкин кадәр күбрәк файда китерү теләге Ибраһимовны төрле эшләргә алынырга дәртләндергән, эшендә аны фидакарьлеккә, батырлыкка һәм үз-үзен аямыйча эшләүгә рухландырган [3; 9].

Соңгы елларда фәндә халыкның үткәне, тормышы, мәдәни байлыгы, көнкүреше, туган теле белән кызыксынуы арта. Фикеренең үзгәрүе нәтиҗәсендә, моңа кадәр күренми яткан тел катламнарының ачылуы тарихи вакыйгаларны, тел күренешләрен, әдәби әсәрнең эчтәлеген өйрәнүгә яңача карарга мөмкинлек бирә. Татар әдәби-эстетик һәм иҗтимагый фикерендәге яңа юнәлешләр һәм яңарыш идеяләре әдәби әсәрне башкачарак тикшерү критерийләренә юл ачты. Гомумән алганда, мәдәни, әдәби-эстетик фикер үсешен, тел үзенчәлекләрен өйрәнү халык тарихын аңлау өчен дә бик мөһим. Һәм без бу кечкенә мәкаләдә Галимҗан Ибраһимовның «Казакъ кызы» романы мисалында әсәрдә казах халкының тормышын сурәтләүдә авторның осталыгына игътибар юнәлтергә булдык.

Галимҗан Ибраһимов гаҗәеп бай әдәби һәм фәнни мирас калдырган шәхесләрнең берсе. Аның «Казакъ кызы» романы – татар прозасының иң яхшы үрнәкләреннән берсе. Әсәрнең язмышы да әдипнең язмышы белән үрелеп, катлаулы бер үремне хасил итә. «Казакъ кызы» романы – 1920 елларда татар әдәбияты өчен гаять зур күләмле әсәр була. Бу әсәр 1923 елның көзендә төгәлләнгән булса да, языла башлау тарихы әле революциягә кадәрге чорга ук карый. Г. Ибраһимов аны 1909 елның җәендә Уралда Миас заводы поселогында яшәгән чагында яза башлап, 1911 елда Казанда

тәмамлый. Ләкин роман шул ук елда Оренбургтагы «Вакыт» нәшрияты тарафыннан басарга кабул ителсә дә, дөньяга чыга алмый кала. Кульязма типографиягә бирелгәч, тентүләр вакытында жандармерия тарафыннан конфискацияләнә. 1912–1913 елларда Г. Ибраһимов аны кулында калган караламасы буенча яңадан язып чыга, ләкин әсәр тагы бәлагә тарый: шул ук елның язында Киевта язучы кулга алынган чакта, китаплары һәм барлык кульязмалары белән бергә ул яңадан охранкага эләгә. Бу әсәрне әдипкә бастырып чыгару бары тик 1917 елдан соң гына насыйп була − 1924 елда гына дөнья күрә. Нәшриятка бирер алдыннан әдип аны, табигый, яңадан карап, төзәтеп чыга.

«Казакъ кызы» романында XIX йөз ахыры − XX йөз башы казакъ халкы тормышы чынбарлыкта чагыла. Ул язучының татар теле ярдәмендә башка халыклар тормышына да үтеп керә алуын дәлилли торган әсәре. Романда язучы казакъ даласының гүзәллеген, кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне, көнкүреш һәм мәхәббәт күренешләрен зәвыклы һәм бай тел белән ачып бирә.

Әсәр сәяси-иҗтимагый, әхлакый каршылыкларын үз эченә алган үзенчәлекле образ-характерларга бай. Анда вакыйгалар ике сюжет сызыгы буенча бара. Берсе Карлыгач-Арысланбай мәхәббәтенә бәйле, икенчесе ыруглар арасындагы власть өчен көрәшне чагылдыра. Г. Ибраһимов «Казакъ кызы» әсәрендә казакъ кызы язмышы мисалында инкыйлабларга кадәрге гадәти казакъ тормышын реаль детальләр нигезендә сурәтләүне максат итеп куя. Анда сурәтләнгән вакыйгалар, китерелгән кайбер тарихи мәгълүматлардан аңлашылганча, узган гасыр башларындагы чорга карыйлар. Ул вакытта инде Казахстанны Россиягә буйсындыру тәмамланган була. Дала тормышына капиталистик мөнәсәбәтләр дә үтеп керә башлый. Киң далада җир өчен, власть өчен ыруглар арасында тарткалаш китә. Чөнки җир казакъ халкы өчен иң кирәк нәрсә, иң зур байлык булып санала [1: 11]. Шушы изге җир аларның малларын тукландыра, җир юмарт булганда гына казакъ үз тормышының иминлеге, муллыгы өчен борчылмый.

Әсәрдә казах кызының язмышы социаль-сәяси үзгәрешләргә тыгыз бәйләнештә сурәтләнгән. Әдип тугандаш төрки халыкның мөһим бер иҗтимагый үсеш баскычындагы катлаулы тормыш күренешен тудыра. Ул татар укучысын төрки кардәшләребезнең 100 ел элек ничек яшәве, тормышы үзенчәлекләре һәм нинди хисләр дөньясында кайнавы белән гаҗәеп оста таныштыра. Язучы кош кебек хөр табигатьле горур Карлыгач-Сылу образында казах кызларының барысында да, хәтта бер аларда гына түгел, гомумән, мөселмән хатын-кызы табигатендә тирән яшеренгән рухи азатлыкка омтылыш хисләрен чагылдыра.

Әсәр дөньясы үзенчәлекләре аның лексик төзелешен билгеләгән. Аеруча идея-сәнгать вазифаларын романда теркәлгән һәм мөһим әһәмияткә ия булган этномәдәни лексика үти. Чөнки тел системасының мөһим дәрәҗәсе буларак лексика буыннан буынга милли дөнья үзенчәлекләре турында булган мәгълүматны саклый һәм күчерә. Тел һәр халыкның тарихын, мәдәниятен, әдәбиятын, гореф-гадәтләрен, дөньяга карашын һәм көнкүрешен тулысынча чагылдыра. Шуңа күрә халыкларның рухи тормышы һәм бүтән өлкәләре төрле лексик системаларда тәкъдим ителгән [7: 240–242].

Әсәрнең лексик берәмлекләрен анализлау, анда төрле өлкәгә карган терминологик лексиканың да үзенчәлекләрен ачып салырга мөмкинлек бирә. Әдәби сөйләмдә терминнарны өйрәнү түбәндәге нәтиҗәләргә килергә мөмкинлек бирә: әдәби сөйләмдә терминологик сүзләр номинатив һәм сәнгати функцияләр башкара, шуның нәтиҗәсендә әдәби әсәрдә терминнарның функциональ-семантик синонимнары киң кулланыла; аларны куллану экстралингвистик һәм психолингвистик факторларга нигезләнә. Терминологик лексиканы сәнгати-образлы функциядә куллану сәнгати сөйләмгә даими һәм образлы тәэсир итә торган ихтыяҗ нәтиҗәсе буларак бәяләргә кирәк.

Халык тормышын типик вакыйгалар җирлегендә сурәтләгәнлектән, бу әсәрдә социаль терминнар гаять оста кулланылган. «Казакъ кызы» романында без шундый лексик берәмлекләрне социаль өлкәгә мөнәсәбәтле итеп карар идек: *хәерче, ялчы, салым, калымлык (әйттерелгән кыз бала), кодалык, мосафир, чыгым, мал, куйчы вәзир-мәзир, сәүдә белән алыш-биреш булган, байгыш, җылкычылар, угрылык, кукыл, кара чикмән, малла, шәкерт, ишан, суфи, бәдәлче, дәверче, фидияче, ала солтаннар, авылнайлар, биләр, булыслар, комалакчы, киез басучы хатыннар, җеп-аркан ишү, кул эше, печән, иген эше, ага, адәм, ана, әкә, байбичә, баласы, бүз балалар, җегет, ир-җегет, кунак җегет, әбдән мыктый җегет (бөтенләй таза егет), тәвер җегет, илче, картлар, карчык (ак чәчле, керле күлмәкле, җимерек борынлы карчык), килен, киленчәк, кода, кыз, кыз бала, молда, өлкәннәр, сабый, сылулар, тамыр, хатыннар, чичә, яшь сылулар, кардәш, ата, данабикә, утагасы, согыну, согынучы* һ.б.

Әдәби әсәрләрдә термин номинатив-тасвирлау һәм сәнгать-образ функциясендә кулланыла – җитештерү колоритын билгеләү, персонажларның хезмәт эшчәнлеген торгызу өчен, геройларның сөйләм характеристикасын булдыру максатыннан файдаланылган. Мәсәлән, *печән, иген эше, кул эше, җеп-аркан ишү* сүзләренә күз салсак, алар хезмәт, шөгыль, һөнәр төрләрен, геройның һөнәри мөнәсәбәтен күрсәтәләр: *Шуңа күрә печән, иген эше башланганчы яңа урынга күчәргә тиешләр иде* [2: 91].

Шулай ук әсәрдә, мәсәлән, *хәерче, бай* сүзләрен куллану аша геройның матди һәм социаль хәле тамгалана: *Ара-тирә байның кымызын эчәм, итен ашыйм икән – казакъ йорты үзенең бу нигъмәтләрен далада каңгырып йөргән бичара нугай хәерчегә дә бирә түгелме?!* [2: 134].

Гаилә, кан-кардәшлек терминнарына караган сүзләрне дә билгеләп була, мәсәлән, *ана, ата, ага, бала, әкә, килен, кодалык: Бәхетсез киленчәк кунак дусы Сылу кыздан аерылмады* [2: 65]. Алар казах халкының тарихи традицияләрен күрергә мөмкинлек бирә, геройлар арасындагы мөнәсәбәтләрне чагылдыра.

Әйтергә кирәк, әсәрнең социаль лексикасы авторның җәмгыятьнең гадәти булмаган төзелешен һәм бәләкәй социумын төзүен ачыклый. Социаль терминологияне сәнгатьчә-образлы куллану экспрессивлык һәм эмоциональлек булдыруга хезмәт итә, авторның төрле вакыйгаларга булган үз мөнәсәбәтен билгели, тасвирлау объектының ниндидер аермалы бер үзлекләрен яки сыйфатларын бирү теләге белән бәйле була. Социаль лексика халыкның эстетик күзаллауларын, әйләнә-тирә дөньяны танып-белү үзенчәлекләрен чагылдыра.

Г. Ибраһимов романындагы казах халкының тормышын, көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, табигатен билгеләүче этномәдәни лексика – милләтнең тарихы һәм үсеше турындагы мәгълүмат чыганагы. Сәнгать әсәрләрендә кулланыла торган этноатамалар милли колоритны һәм этник үзенчәлекләрне күрсәтә. Көнкүреш предметларын атаган этнолексика казахларның тормышын һәм көнкүрешен характерлый. Мәсәлән (калын шрифт белән бирелгән сүзләр көнкүреш этнолексикасына карый):

*Колыннар белән эшләрен бетереп **тирмәләргә** килгәндә, тукал **самавыр** куя, берсе сөт белән, берсе **киез** басар өчен су белән тулы ике зур **казанның** астына **тизәк** салып, янмаганга өреп азаплана, ялчы хатын Каләмпер, уң яктагы **кара өйдән** капчык-капчык **куй җоннары** чыгарып, шуларны җирдәге **камыш чыпта** өстенә аударып азаплана иде* [1].

*Арада хаклары икедән утыз сумгача торган төрле төстә байтак **чапаннар**, берничә кыйммәтле **палас** дүртәр аршиннан биш кисәк кара **постау** бар иде* [1].

*Өстендә буй-буй сырып тегелгән яңа **көпе**, башында бәрхет тышлы, кызыл төлке эчле, чите **камалы очлы бүрек**, билендә кара алтын белән бизәлгән көмеш **кәмәр**, кулында **камчы*** [1].

*Зиннәтле зур бай **тирмәсенең** ишеге төбендәге **сабадагы** кымызны **пешкәк** белән шапырып тора иде* [1].

*Бикә кечкенә **турсыкка кымыз** салдырды, кечкенә бер **казылык** белән майлы **ял** алды да авыруның хәлен белергә, авыл читендәге **тирмәгә** таба китте* [1].

Китерелгән мисаллар аша гына да казахларның тормыш-көнкүрешен, эшчәнлек төрләрен, азык-ризыкларын күз алдына китерергә мөмкин. Алар көнкүрештә кулланыла торган күп кенә традицион предметларны терлек йонынннан, кыргый җәнлекләрдән, кош каурыйларыннан әзерләгәннәр, шулай ук төрле үсемлекләрдән файдаланганнар.

«Казак кызы» романында казак халкының тормышын ачып салучы тел чарасы булып шулай ук әсәрнең ономастиконы хезмәт итә, чөнки кеше типик вакыйгалар җирлегендә сурәтләгәнлектән, бу әсәрдә ялгызлык сүзләр гаять оста кулланылган. Әсәрдә автор сурәтләнгән вакыйгаларны бирүдә чорның реаль ономастик берәмлекләреннән файдалана. Чөнки кеше, гомумән халык тормышын типик вакыйгалар җирлегендә сурәтләгәнлектән, бу әсәрдә ялгызлык сүзләр гаять оста кулланылган. Ә ялгызлык атамалары әсәрдәге вакыйгалар җирлеген, тыгызлыгын, киренкеле күчешен тәэмин итә, казах тормышының, халыкның милли үзенчәлекләрен ачыкларга ярдәм итә. Ономастика телнең лексик системасының специфик өлкәсе буларак күптөрле һәм кыйммәтле лингвистик, этнографик һәм тарихи-географик мәгълүмат бирә. Э.М. Мурзаев, үзенең бар гомерен топонимнарны һәм халык телендәге географик терминнарны өйрәнүгә багышлаган галим, болай язган: «Географик атамалар галимнәрнең, беренче чиратта, телчеләрнең, тарихчыларның, географларның гына түгел, ә барлык кызыксынучан кешеләрнең дә ныклы игътибарын үзенә тартып тора. Географик атамалар гомумилеге, яисә топонимия – гасырлар, ә кайчак меңәр еллар дәвамында туплана торган халык иҗаты. Ясалма китаби исемнәр процент ягынан бик аз» [4: 322].

Бу әсәрдә 100 якын ялгызлык исемнәр кулланылган, алар арасында ономастиканың төрле тармакларына караган сүзләрне аерып күрсәтеп була. Әйткәндәй, алар арасында түбәндәгеләрне билгеләргә кирәк:

– ***антропонимнар*** *(кеше исемнәре): Абай акын, Сары-Арканың өлкән акыны, Абай Кунанбаев, Азым әкә, Айбала (киленчәк: Сарсынбайның килене), Ак патша, Алтынчәч (бикә: Карлыгач-Сылуның әнисе), Арыслан, Арысланбай (танабуга иленең Магҗан хаҗи баласы), Биремҗан аксакал, Бүребай (Әбелхаернең кардәше), Мостафа (кәрван башы), Габдулла Әлказаный (татар шәкерте – Яңгырбайның мулласы), Гөлканыс (Арсланбайның җитү чибәр кызы), Гөлфаныс (Яңгырбайның кызы), Гөлсем бикә (Арсланбайның мәрхәм анасы), Гөлчәчәк (Сарсынбайның сабый кызы), Дәрвисал, Җолкынбай (Сарсынбай байның ялчысы), Йолдызбай хаҗи, Ирҗан (танабуга ыруг илнең бае), Карлыгач-Сылу (Найман иленең Сарсынбайның кызы), Кашакрбай, Көтибар (Есет Көтибаров), Күчәр (аксак карт куйчы), Тынычбай һ.б.;*

Кеше исеме – аерым бер кешене башкалардан аера һәм индивидуальләштереп күрсәтә торган атама. Мәсәлән, *Карлыгач* исеменең мәгънәсенә күз салсак, казах телендә ул кош исемен – «ласточка» мәгънәсен бирә. Казахлар өчен *карлыгач* борынгыдан ук яхшы хәбәрләрнең чыганагы булган, бу җитез кошчыкның очып килүе яз килүен һәм кар эрүен белдергән, матурлык һәм зыйфалык билгесе саналган. Әсәрдәге *Карлыгач* та яхшы энергетикага ия, матурлыкны тоя, азатлык өчен көрәшә белгән герой. Ир-ат исеме *Арслан* хәзерге телләргә борынгы төрки халыклардан килгән һәм «арыслан», «кыргый җәнлек» дигәнне аңлата. Ул Көнчыгышта киң таралган исем. Ул элек-электән батырлык, горурлык, бәйсезлек символы. Гомумән алган, әсәрдәге кеше исемнәренең барсы да казах антропонимнары.

*– **топонимнар** (географик атамалар) үзләре ваграк төркемчәләргә бүленә: Алтын-Күл, Арал диңгезе, Балукаш диңгезе, Коргак-Күл, Диңгез-Күле, Пешпәк чүле, Мафышлак чүле, Тургай чүле –* гидронимнар; *Актүбә, Атбасар, Әхмәт авылы, Җылкы-Баткан (Сарсымбай авылы), Зарафшан буйлары, Грече йөз, Күкчәтау, Кустанай, Кызыл-Ком, Кызылъяр, Олы йөз, Өмбер, Петрбург, Яман-Кала–* ойконимнар һ.б.

Казакъстан топонимиясенә урынның үзенчәлекләрен һәм билгеләрен төгәл тапшыру хас [8]. Бу үзенчәлек казахларның меңнәрчә еллар буена далада шартларында терлекчелек белән шөгыльләнүенә бәйле. Далада һава торышының кырыслыгы, рельефның – тауларның, үзәнлекләрнең, чокырларның, үткелләрнең терлекләрне үрчетүгә йогынтысы, җәйләүләрне һәм көтүлекләрне җентекләп сайлау – барсы да алдан уйлап башкарылырга тиешлеген, озак тупланган тәҗрибәгә таянып хуҗалык итүне таләп итә. Шуңа күрә Казакъстан топонимиясендә еш кына *күл, тау, сай, олы, сылу* компонентлары очрый.

Романда шулай ук без тереклек атамаларына (зоонимнар), бигрәк тә этнонимнарга игътибар бирергә тиешбез:

*– **зоонимнар** (хайваннар, кош-кортлар һ.б. атамалары, кушаматы): Байчобар (ат), Толпар.*

Табигатьтәге тереклек кешелек эволюциясендә мөһим урында торган. Кеше элек-электән үзен табигать аерып карамаган, аның бер аерылгысыз өлеше итеп кабул иткән. Һәм моны шул исәптән аның гомер юлдашы һәм көндәлек ярдәмчесе, катлаулы тормыш шартларында ашамлык төрләре белән тәэмин итеп, яшәешен булдыручы ролен үтәгән йорт хайваннарына, кош-кортларына мөнәсәбәттә белдергән. Болар барысы да телдә дә чагылыш алган. Дала халкы тормышында бигрәк тә ат-йылкы малы зур әһәмияткә ия булган. Төркиләрдә гомумән ат изгеләтерелгән хайван. Югарыда бирелгән атамалар да моның ачык дәлиле.

– ***этнонимнар*** *(кабилә, халык, милләт атамалары): Дүрткара ыруг, Алтын ыруг, Кара-айгырлар, Кызылкорт, Найман, Сарманнар, Танабуга ыруг, Кыпчаклар.*

Бу этнонимнар әсәрдә казах тормышының милли колоритын тагында бер югарылыкка күтәрә. Бу этнонимнар чынлап та казах халкының тарихында булган этник бермәлекләр. Алар казахның тарихында гына эз калдырган этник төркемнәр түгел, ә бүген дә аның менталь үзенчәлекләрен билгеләүче, милли бердәйлекнең күрсәткече булып торалар. Ә әдәби әсәр текстында бу этнонимнар реаль тарихи чынбарлыкны беркетүче сурәтләү чаралары ролен башкаралар, вакыйгалар агышын чынлыкта теркәү вазифасын үтиләр.

Югарыда бирелгән ономастик берәмлекләр барсы да укучыга казах тормышының үзенчәлекләре турында сөйли. Географик атамалар, кеше исемнәре, нәсел-ыру атамалары тулысынча казах тормышын, кешеләрнең эчке һәм тышкы кыяфәтен чагылдыра. Мәсәлән, антропонимик сүзләргә игътибар итсәк, әсәрдә билгеле бер геройга бирелгән характеристика аның исеменә туры килгән кебек, мәсәлән, Карлыгач-Сылу: *«...Якты йолдыздай сылулыгың бар»* [2: 63]. Шулай ук этнонимнар да ыругларның характер ягыннан нинди икәнлекләрен, башка кабиләләр белән нинди мөнәсәбәттә булуларын сүрәтли. Ләкин әсәр татар укучысын күз уңында тотып язылганлыктан, ул чор өчен хас булган татар әдәби теле лексик катламы гомумтөрки сүзләр белән аралаштырып кулланылуына да игътибар итәргә кирәк.

Топонимнар хикәяләүдә сюжет ситуацияләренә һәм геройларның җирлекне күзаллауларына төгәллек, тапкырлык һәм дөреслекне кертә. Мәсәлән, «*Кәрван башы Мостафа дигәнгә яллаңып, Кызылъяр, Күкчәтәү, Сими, Ташкент, Троицк араларында кәрван йөртте*» [2: 132].

Әйтергә кирәк, кеше исемнәре, географик атамалар тарихи вакыйгаларның бердән-бер шаһитлары һәм бердәнбер тарихи информация чыганаклары. Димәк, югарыда бирелгән «Казак кызы» романының ономастиконы ярдәмендә Г. Ибраһимов үз әсәрен тагын да тулыландыра, геройларын индивидуальләштерә, сурәтләгән җирлекләрне конкрентлаштыра һәм җанландыра. Шулай итеп, ялгызлык атамалары әсәрнең эчтәлегенә керешеп, аның гомуми идеясен яктыртуга хезмәт итә [5: 37–39].

Географик атамалар, кеше исемнәре, нәсел-ыру атамалары тулысынча казах тормышын, герой-персонажларның эчке һәм тышкы сыйфатын чагылдыра. Ә гомумән алганда, этномәдәни лексика халыкның эстетик күзаллауларын, әйләнә-тирә дөньяны танып-белү үзенчәлекләрен чагылдыра. Этнолексика миллилекне белдерүче тел чарасы булып санала.

ӘДӘБИЯТ


1. Ибрагимов Г. Г. Казакъ кызы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 191 б.

2. Ибраһимов Г. Казакъ кызы: хикәяләр, роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – 384 б.

3. Муканов С. Большой талант // Литературная газета. – 1962. – 13 марта.

4. Мурзаев Э.М. Словарь народных географических терминов. – М.: Мысль, 1984. – 653 б.

5. Насипов И.С., Рамазанова А.Р. Ономастика в романе Г. Ибрагимова «Дочь степи» // Актуальные проблемы тюркологии: Россия и тюрко-мусульманский мир: X Международная тюркологическая конференция (г. Елабуга, 25 декабря 2020 г.) / Отв. ред. А.З. Нигамаев. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2021. – С. 37–39.

6. Рамазанова А.Р. Этнолексика в романе Г. Ибрагимова «Дочь степи» // Тюркская лингвокультурология: проблемы и перспективы: материалы XI Международной научно-практической конференции учащихся, студентов и аспирантов (Казань, 20-21 февраля 2020 г.) / сост.: З.Н. Кириллова, Р.Р. Салахова. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2020. – С. 244–246.

7. Рамазанова А.Р. Г. Ибраһимовның «Казак кызы» романында казах халкының тормышын сурәтләү // Тюркская лингвокультурология: проблемы и перспективы: материалы XII Международной научно-практической конференции учащихся, студентов и аспирантов (Казань, 19 февраля 2021 года) / сост. Р.С. Нурмухаметова. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2021. – С. 240–242.

8. Садыков Т.С., Жумекенова Д.Е. К вопросу об особенностях происхождения топонимов в истории Казахстана // Молодой ученый. – 2017. – № 11 (145). – С. 396–398. – URL: https://moluch.ru/archive/145/40773/ (Дата обращения: 14.02.2021).

9. Хасанов М.Х. Галимджан Ибрагимов: монография. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1977. – 432 с.


УДК 81.42+811.512.145

# АССОЦИАТИВНО-СМЫСЛОВОЕ СОДЕРЖАНИЕ МЕНТАЛЬНЫХ ОБРАЗОВАНИЙ *ХӘЯТ* (ЖИЗНЬ) И *ҮЛЕМ* (СМЕРТЬ) В ХУДОЖЕСТВЕННОМ ТЕКСТЕ Г. ИБРАГИМОВА

## (На материале рассказа «Сөю – сәгадәт»)


***Ф.К. Сагдеева, Г.А. Хуснутдинова***

*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*



Художественный текст представляет собой индивидуально-авторское видение содержания концепта, которое дополняется многочисленными смыслами. Предметом рассмотрения в данной статье является ассоциативно-смысловое содержание концептов *хәят* и *үлем,* воссоздаваемое на основе лексической экспликации в художественном тексте Г. Ибрагимова. В качестве объекта исследования послужило прозаическое произведение – рассказ «Сөю – сәгадәт». Главным фактором, повлиявшим на выбор объекта исследования является то, что в рассказе «Сөю – сәгадәт» Г. Ибрагимова широко представлен материал для выявления указанных концептов как фрагментов авторской картины мира.

**Ключевые слова:** концет *хәят*, концепт *үлем*, ассоциативно-смысловое содержание, художественный текст.

The literary text is an individual author's vision of the content of the concept, which is complemented by numerous meanings. The subject of this article is the associative and semantic content of the concepts *hayat* and *ulem*, recreated on the basis of lexical explication in the literary text of G. Ibragimov. The object of the study was a prose work – the story « Love and happiness» «Soyu – səgadət». The main factor that influenced the choice of the object of study is that in the story «Love and happiness» «Soyu – segadat» by G. Ibragimov, material is widely presented to identify these concepts as fragments of the author's picture of the world.
**Key words:** concept *hayat*, concept *ulem*, associative and semantic content, literary text.

В рамках когнитивной лингвистики особый интерес у исследователей вызывает проблема интерпретации отдельных ключевых концептов культуры. В работах данного направления рассматриваются различные проблемы, связанные с формированием концепта, его структурой, решаются вопросы соотношения концепта и слова. Суть когнитивного подхода к языковым явлениям состоит в том, что языковые средства являются отражением когнитивных структур. Комплексный подход к изучению семантики слова и его понятийного основания с позиции когнитологии позволяет реконструировать концепт через его языковое выражение.

Художественный текст, построенный на основе концептуальных авторских ассоциативных полей, которые с точки зрения структуры представляют собой отношения между ключевым словом и его употреблениями, актуализирующими те или иные компоненты исходного слова. Системные компоненты лексического значения и скрытые смыслы семантики слова актуализируют ассоциативно-семантические поля. Писатели могут обогатить содержание концепта своими индивидуальными приращениями как содержательного, так и прагматического характера. То есть, художественный текст представляет индивидуально-авторское видение содержание концепта, которое дополняется многочисленными смыслами, вносимыми читателями в процессе восприятия и интерпретации текста. Ассоциации, возникающие в процессе чтения художественного текста, способствуют постижению художественного мира автора.

Концепты *хәят* (жизнь) и *үлем* (смерть) в рассказе Г. Ибрагимова являются базовыми. В свою очередь концептуальные смыслы и представления о жизни и смерти непосредственно реализуются в языке художественного текста – в конкретных языковых формах.

Осмысление героем мечтаний, впечатлений, думы о прошлой жизни исходит из предпосылки *мин булдым* (*Мин үзем дә, дим, шулай булдым*) и репрезентируется следующими лексическими единицами и сочетаниями слов: *хыл, хыялга батам, хыялларым тирән, мин дә мөтәәссирмен, минем тәэсирем, уйлары авыр һәм борчулы и мн.др.*

В рассказе семантическая структура ключевых слов концептов *хәят* и *үлем* представлена синонимическим рядом – *хәят* (26 словоупотреблений и синтагм, ассоциативно сопряженных с данным словом), *гомер* (23), *тормыш* (5), *үлем* (8) Эти слова в своих основных значения имеют одинаковую референциальную соотнесенность: Анализируя концепт *хәят*, мы исходим из представления о ней как о некоим сюжете, где можно выделить несколько этапов, которые последовательно взаимосвязаны между собой: рождение – собственно существование – склонение к концу.

Закономерность жизни заключается в цикличности бытия, которое живет по строгому закону рождения и смерти, смены времен года, дня и ночи, радости и печали, обретения и потери.

Рассмотрим эти основные модусы бытия. Герой рассказа предстает в образе созерцателя своей прошлой жизни, который уже осознал, что жизнь коротка: *Мин яшь чагымда «Кигән кием ничек туза, яшь гомер шулай уза» дигән җырны бик ярата, ирексез үк шуны авызымнан салмый йөри идем. Шул җырның чын мәгънәсе менә хәзер беленде. Вакыйган, «кигән кием ничек тузса, яшь гомер дә шулай уза» икән. Буны хәзер ачык сизенәм.*

Языковые средства организации пространства появляются уже в первых строках рассказа. Их функция заключается в том, что они принимают участие в пространственно-временой характеристике сюжета – мечтания старого поэта о прошлой жизни: *өй, бакча, күл* и др.: *Мин, өебезнең бакчага караган тәрәзәсе аркылы зур күл артына батып барган олуг кояшка карап, хыялга батам.*

Начальный этап – рождение, знаменующий, появления героя на свет основывается на метафоризации. Рождение воспринимается как вступление ногой в этот мир: *Дөньяга аяк баскан көнемнән башлап…*

Следующей фазой после появления на свет является фаза собственно бытия, существования (жизни), которая объективируется следующими языковыми средствами выражения: *хәятым, хәяттан ала алган, гөмер дәвере, гәмернең җил-давыллы чагы, үткән гөмер, гөмер юлында, тормыш, хәзерге тормышында, тәҗрибәле томышның* и мн.др.

В рассказе образ солнца символизирует жизнь. Попутно отметим, что в тюрко-татарской литературе архетипический образ солнца является одним из древнейших символов.

Символические употребления слова *кояш* актуализируют следующие кванты смысла:1. источник света и тепла (*Ниһаять, ул үзенең күз теккән ноктасына барып ирешә дә, аннан мөтәкәббиранә бер сыйфат белән дөньяга карап, бөтен табигатьне утына, яктысына күмә – яндыра, көйдерә һәм нурландыра*); 2. источник и основа жизни (*Җир вә анда булган һәммә нәрсә үзенең хәятын аннан ала. Җирдәге һәммә алмашынулар – һәрбер табигый эшләр тик аның тәэсирена генә табигъ*); 3. источник силы и красоты (*Үткән һәрбер минут аның урынын югарылата, куәт вә матурлыгын арттыра бара).* Движение солнца по небосклону олицетворяется следующим образом: солнце встает (*кояш чыга*); медленно (*акрын)*, беспрерывно( *туктаусыз*), гордо *(мөтәкәббиранә)* начинает двигаться к своей высшей точки нахождения на небе (*…ул акрын, әмма туктаусыз рәвештә ерак вә югары күккә карап юл тота – ниһаясез фәзаның иң гали ноктасына, төшлеккә туры текәп, мөтәкәббиранә бара башлый*). Характер производимого действия: солнце палит (*яндыра, көйдерә)*, озаряет, освещает (*нурландыра*). Такое состояние не длится вечно. Солнце снижается, заходит, исчезает (*түбәнгә таба йөз тота, бата, югала*). В данном случае показательные образные реализации солнца следующие. Образ солнца символичен и амбивалентен. С одной стороны, солнце воплощает идеалы красоты и силы, является источником жизни, тепла и света, а с другой, заход солнца означает конец жизни. Герой отождествляет свою жизнь с движением солнца по небу: *Минем хәятым да, дим, шулай.* Вербализация процессов осмысления приближения конца жизни синтагматической значимостью ключевых осуществляется следующим образом: *хәяттан еллар буенча алган нәрсәләремне акрынлап бирә, сүтелә башладым; гомернең кыйммәтле дәвереннән авыша башлаган, төшлегемнән түбәнгә, кара төн эченә таба баерга юл тоткан чагым*; *үлемгә таба агып барам* и др.

Жизнь как форма существования материи оказывается привязанным к категории времени. Время в рассказе измеряется единицами – минутами, часами, месяцами, годами и т.д. Эти единицы имеют характеристики краткости, длительности, значимости. Взаимоотношения между единицами времени, основываются на принципе включенности. Минуты складываются в часы, часы – в дни, дни – в месяцы, месяцы – в годы и т.д

Так, прошлая жизнь – *үткән гөмер (...хисем белән үткән гомердә булган күренешләр...),* членясь на временные отрезки: часы: *үткән һәрбер минут, аның белән очрашкан сәгатьтән и др.,* дни – *үткән көннәр (Шул кайгы минем үткән көннәрем эчендә күмелгән матур чакларны, үчеккән кеби, күз алдыма китерә);* месяцы – *май* и др, годы – *елларым (Ул елларым гомеремнең шул халәткә охшаш бер дәвере иде)*, *замананың соң елларындамын, еллар кичә* и др.; она

оказывается линейно направленной и представляет собой некоторый отрезок бытия героя: *хәятнең төрле кисәкләре (Шул сөальгә җавап улып, хыялымда кичкән хәятның төрле кисәкләре, төрле минутлар килә)*. Прошлая жизнь была долгой: *озын гомер (Шул озын гомердә ахырдан сагынырлык нәрсә эшләнгән?)*. Хотя в этом случае не идет речь о каких-то определенных единицах измерения этого периода: *дәвер (Гомернең җил-давыллы һәм туктаусыз тулкынлы чагы үтеп, акрын, гел бертөсле һәм тынычлык сөяр дәвере кереп килә).*

Отсюда и возникшая синонимия*: гомер дәвере – хәят, тормыш. Гомеремнең җанлы, өмидле дәвере кичкән. Хәяттан ала алган нәрсә вә нигъмәтләр алынып, инде артык эш көтәргә җай калмаган. Инде тормыштан яңа байлык, яңа куәт алырга түгел, буңарчы алганнарны бирә башларга, әкренләп тузарга, сүтелергә вакыт килгән.*

Период молодости осмысляется как самое ценное время: *Яшьлекнең бу дәверен адәмнең хәятында иң гали вә иң кыйммәт бер заманы дип хисаплыйлар*. Здесҗ лексемы *дәвер* и *заман* в значении *определенный период жизни* являются синонимами.

Молодость отождествляется с сумашедшей силой, геройством, состоянием, когда хочется кругом все рушить, поднимать тяжести, когда душа не вмещается в тело: *Адәм кайбер вакыт үзенең кулларында һәм тәнендә шундый бер куәт сизә ки, бер нәрсәне ватасы, җимерәсе, әллә нинди авыр әйберләр күтәрәсе, яки куәтле бер батыр белән биртенгәнче сугышасы килә – ничек тә булса үзеңдәге куәтнең тилергән бер чагы була.*

Осознание смысла жизни выражается следующим образом: *Гүя дөнья вә табигатьнең тирән вә нечкә серләре эченә куелган хәятның зур мәгънәсе, бөек әһәмияте, ниһаясез матурлыгы миңа яңа гына ачыла да, мин аның һәрбер кисәгеннән аерым бер хозур, киң бер сәгадәт күзләп...*

Пора молодости представляется как путь по дороге жизни, которая ведет вперед и вверх: *... гомер юлында шатлана-шатлана алга һәм югарыга атлыйм*. В основе символического представления о жизни как пути, дороги лежит метафорическая модель, построенная по схеме «перемещение в пространстве», «перемещение по этапам, периодам жизни» (рост, развитие в течение всей жизни).

Следует отметить, что метафорический образ мышления является характерной чертой речемыслительной деятельности Г. Ибрагимова, использование концептуальной метафоры носит системный характер.

Ожидание желаемого, благоприятного, соединенное с уверенностью в возможности осуществления находят свое воплощение в слове *өмид* (надежда): *Мин хәзер, яшь йөрәкнең өмидкә ни дәрәҗәдә бай булганлыгын күреп, шашып калам*. В данном случае

в эмоциональной жизни героя молодое сердце предстает в качестве органа-хранилища надежды.

Молодость ассоциируется с надеждой, «количество», которой бесконечно: *ниһаясе булмаган өмид* . Надежды наполнены красотой и светом: *ниһаясез матурлык вә нур белән тулган өмидләр*. Позже приходит осознание того, что эти надежды, основанные на ветру *(Шул өмидләр һәммәсе җилгә корылган)* и поэтому породили на жизненном пути очень много ошибок: *Шуңар күрә үзләре хәят юлында бик күп яңлышлыклар тудырганнар.* Смысл надежды рушатся, исчезают реализуется с помощью глаголов*: җимерелә, юкка чыга*.

Широко представлены все виды контекста, репрезентирующие содержание авторского концепта. У писателя особенно развернут прагматический аспект, позволяющий герою рассказа выразить свои чувства. Само чувство *(хис)* описывается витальными признаками – метафорами живого существа. Как живому существу, чувству свойственны фазы жизни: оно рождается (*Бу хәл миңа зур бер кәшеф кеби булып, үзе аерым ләззәт бирә, хәятны мөстәкыйлә үз кулыңа алган кеби бер хисне тудыра иде*); у чувства выделяются признаки возраста, в данном случае период взросления – период, когда следует жить только своими чувствами *(...үзеңнән зурларга ияреп эш кылына торган балалык чагыннан чыгып, һәр тугрыда үз уем, үз хисем белән генә яшәргә...).*

Пора влюбленности – еще одна сюжетная линия в жизни героя. Чувство любви имеет положительную эмоциональную окраску. К примеру, встреча героя со своей любовью по-новому обогатила его жизнь красотой, заполнила пустоту: *Х. белән очрашу минем хәятымны берьюлы баетып җибәреп, анда яңа ләтафәт, яңа матурлык арттырды. Гүя теге бушлык берьюлы тулып китте*. Объект любви предстает в образе сверхъестественного существа – *фәрештә* (ангел): *Менә шул чакта язмыш, хәятымны артыграк бизәү өчен булса кирәк, минем гомер юлыма Х. атлы бер фәрештәне чыгарып куя.* Возлюбленная героя, которая стала центром его жизни (*хәятымның мәркәзе*), уподобляется божественному, отдельному произведению искусства природы, прекрасному цветку и объективируется в тексте следующим образом: *...ул иляһи; ул – табигатьнең аерым бер сәнгате; ул – хозур язның бөтен күркен, бөтен ләтафәтен җыйнаган бердәнбер асыл чәчәк*.

*Хәят* (жизнь) и *үлем* (смерть) являются антиномичными концептами. В этой бинарной оппозиции сознание первый компонент вычленяет как положительный. Поэтому ассоциативный фонд концепта *үлем* намного уже, чем концепта *хәят*.

Слонение к концу обусловлено временем (возрастом). И все же, временнные границы существования героя неопределимы.

Его портретная характеристика, представленная семантическими аспектами: *Маңгайда эре-эре җыерчыклар бар. Күздә яшь заманга хас булган ялкын вә куәттән әсәр дә калмаган. Сакалга чал кереп, буемның төзлеге дә югала башлаган...* может быть чисто субъективным взглядом.

В данном случае признак *карт (мин картаям)*, связанный с понятием старость, можно признать неким состоянием, приближающим к концу – конечная шкала жизни – это смерть: *Алдыңда үлем тора*. Старый поэт знает о конечности жизни, о неизбежности смерти, которая вытекает из природы самого биологического существования: *Син, табигать канунының куәтенә буйсынып, шуның акрын гына килүен вә бер вакыт килеп җитеп, тын вә караңгы үлемгә алып китүен көтеп торырга мәҗбүрсең*.

Смерть представляется как исчезновение из небосклона жизни и погружение в темную ночь: *Мин дә, хәят күгеннән югалып, үлемнең караңгы кичәсе артына батырмын, югалырмын*. Смерть – кануть в вечность, чтобы никогда обратно не возвратиться: *... мин үлем артына мәңгегә, кабаттан хәят күгенә һичбер килмәскә батам.* Смысл *конец существования* объективируется с помощью глаголов *бетәбез*, *кайтмыйбыз (...әмма без бетәбез дә мәңге кайтмыйбыз...)*. Смерть ассоциируется с исчезнованием в тумане, темноте: *... үлемнең шул томаны, шул караңгылыгы эчендә югалып,* а также,с забвениеми др.: *онытылып калабыз* и др.

И все же, умереть можно не только от старости, но и от счастья и любви. Личные переживания, наполненность чувством любви, счастья реализуются с помощью глагола *үләм* и образных выражений, например: … *үләм... үләм... бәхет вә сәгадәтемне күтәрә алмаудан, күңелемнең ниһаясез куәт беләң ашкынуыннан үләм...*, где лейтмотивный характер имеет смысл *сөюдә генә чын сәгадәт!*

ЛИТЕРАТУРА

1. Ибраһимов Г. Сөю – сәгадәт // Әсәрләр: 15 томда. 1 т.: хикәяләр, роман. – Академик басма. – Казан: Татар.кит. нәшр., 2018. – Б. 186–199.

УДК 811.512

## ЭТНОКОНФЕССИОНАЛЬНАЯ ЛЕКСИКА В РОМАНЕ Г. ИБРАГИМОВА «МОЛОДЫЕ СЕРДЦА»

***Ф.И. Тагирова, И.И. Сабитова, Р.М. Камалов***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

Язык произведений Г. Ибрагимова представляет богатый материал для лингвистических исследований. Языковеды не раз обращались к этому

материалу для рассмотрения самых различных проблем современной лингвистики. В данной статье исследуется этноконфессиональная лексика. Роман «Молодые сердца» особенно богат на лексику данной тематики. Материал рассматривается в тематическом, лексико-семантическом и этнокультурном аспектах. Исследование, предпринятое нами в данной статье и в более ранних работах, позволяет прийти к выводу, что тексты произведений Г. Ибрагимова обладают не только высокой художественной ценностью, но и универсальны с точки зрения языка.
**Ключевые слова:** Г. Ибрагимов, роман «Молодые сердца», этноконфессиональная лексика, тематическая классификация.

The language of G. Ibragimov's works is a rich material for linguistic research. Linguists have repeatedly turned to this material to consider a variety of problems of modern linguistics. This article examines the ethno-confessional vocabulary. The novel «Young Hearts» is especially rich in the vocabulary of this topic. The material is considered in semantic, lexico-semantic and ethno-cultural aspects. The research undertaken by us in this article and in earlier works allows us to come to the conclusion that the texts of G. Ibragimov's works have not only high artistic value, but are also universal from the point of view of language.
**Key words:** G. Ibragimov, novel «Young Hearts», ethno-confessional vocabulary, thematic classification.

Творчество Г. Ибрагимова на протяжении многих десятилетий неизменно остается в круге наиболее привлекательных объектов исследования для ученых. Литературный гений писателя до сих пор остается непревзойденным, служит мерилом мастерства для нынешних авторов и предметом исследования литературоведов. Языковой аспект его произведений является не менее исследуемой сферой. При этом сквозь призму языка и стиля произведений Г. Ибрагимова рассматривается весь спектр проблем современной лингвистики, что еще раз доказывает высокую художественную ценность и универсальность текстов автора [4: 193–255; 6 и др.]. Значительное количество работ лингвистической направленности посвящено лексике, к которой не раз обращались и мы [8: 232–233; 9: 242–244; 10: 272–275 и др.]. В данной работе предметом исследования является лексика этноконфессиональной тематики в романе «Яшь йөрәкләр» («Молодые сердца»).

Роман Г. Ибрагимова «Яшь йөрәкләр» («Молодые сердца») уже с момента его появления вызвал бурный интерес читателя и привлек внимание ученых. Так, Г. Гобәйдуллин, Ф. Сәйфи, Г. Зәбиров, З. Валиди и другие современники сразу отметили неординарность произведения [1: 64–67]. Современные исследователи продолжают высоко оценивать роман. «Романтическое произведение – роман “Молодые сердца” (1912) – перл в творчестве

Г. Ибрагимова, отличается своим философским характером среди образцов большого эпического жанра, созданных в начале XX века», пишет Д.Ф. Загидуллина (здесь и далее перевод наш) [6: 11; см. также 11: 11–122 и др.].

Этноконфессиональная лексика в романе «Молодые сердца» не просто присутствует, а присутствует в значительном количестве. В произведении романтического характера с сильной любовной линией сюжета такое обилие лексико-фразеологических средств данной тематики могло бы вызвать вопрос об уместности. Однако не в данном случае. Г. Ибрагимов, будучи выходцем из семьи с глубокими религиозными и просветительскими традициями, уже с раннего детства начал обучение в семье. В дальнейшем образование, полученное в медресе, углубило его развитие. К тому же этот роман – одно из ранних произведений писателя, написан им практически вслед за статьями, посвященными обучению в медресе, жизни шакирдов, истории ислама и т.п. Таким образом, у писателя был большой опыт непосредственного живого использования лексики данной тематики. Не удивительно, что языковая личность автора, в течение долгого времени формировавшаяся именно в духовно-религиозном направлении, и его индивидуальное этноконфессиональное сознание отразились в стилистике и языке его произведений.

«Индивидуальное этноконфессиональное сознание – это область души, в которой на основе исповедания определенной религии упорядочивается опыт человека, получаемый при усвоении общего культурно-исторического опыта народа, к которому он принадлежит, на основе идеального образа складывается эмоционально-оценочное отношение к “своему” и “чужому”, формируются мотивы и цели для принятия решений по созданию и поддержанию своей этноконфессиональной идентичности» определяет И.М. Шеина [12: 9]. А если принять во внимание, что «изучение языковых единиц во всей полноте их смысловой нагрузки – это практически единственный путь к постижению коллективной картины мира народа и его коллективного сознания» [12: 81], можно уверенно заключить, что исследование этноконфессиональной лексики чрезвычайно важно не только в лингвистическом аспекте, но и в плане понимания этнического самосознания.

Представленная в романе «Молодые сердца» этноконфессиональная лексика не только многочисленна, но и разнообразна. Если рассматривать ее в морфологическом аспекте, автором в равной мере используются как именные части речи: существительные: *хөтбә, җомга, пәйгамбәр, оҗмах, хәлфә, садака* и т.д.; прилагательные: *имансыз, гөнаһлы, гөнаһсыз, фатихалы, намаз-*

*чыл, догалы, фатихалы, бисмилласыз* и т.д.; так и глагольные: *вәгазьләү, каһәрләү, ниятләү, ышану, ялвару* и т.п.

В структурном отношении выделяются простые, к которым можно отнести приведенные выше примеры, и сложные единицы. Среди них, в свою очередь, можно выделить именные: *гамәл дәфтәре, гүр сәдакасы, иман нуры, мулла-мөәззин* и т.п.; и предикативные конструкции типа: *азан әйтү, дога кылу, тәүбә итү, сәҗдәгә китү, тәсбих тарту, руза тоту, ясин чыгу, вәгазь иттерү* и т.д.

С точки зрения семантики, в романе находим примеры использования конкретных имен существительных: *манара, мөнбәр, михраб, намазлык, тәсбих, чалма* и др.; и абстрактных имен существительных: *мәрхәмәт, миһербан, гөнаһ, җан, рух, иман, инабәт, ышаныч, игътикад, нияз, истиһза, кодсият* и др.

